**2020 ЕЛДА**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА**
**БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ**
**ЭШЧӘНЛЕГЕ НӘТИҖӘЛӘРЕ ҺӘМ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА**
**БАЛА ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ АНЫҢ ЗАКОНЛЫ**
**МӘНФӘГАТЬЛӘРЕН ҮТӘҮ ТУРЫНДА**

# Д О К Л А Д

**КАЗАН – 2021**

# Содержание

КЕРЕШ ........ 5

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ ҺӘМ АНЫҢ АППАРАТЫНЫҢ 2020 ЕЛДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ**

1.1. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшчәнлеге ........ 8

1.2. 2020 елда гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау нигезендә Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләрнең гомуми мониторингы ........ 11

1.3. Хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, балалар өчен оешмалар тарафыннан балаларның хокукларын һәм аларның законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру, үтәү һәм яклау механизмнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген мониторинглау һәм анализлау ........ 21

1.4. Ведомство координация органнары эшчәнлеге ........ 25

1.5. Аналитик эшчәнлек ........ 28

1.6. Эш визитлары ........ 30

1.7. Нормалар чыгару эшчәнлегендә катнашу ........ 34

1.8. Балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашу ........ 43

1.9. Балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерү эшчәнлеге ........ 45

1.10. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең проект эшчәнлеге ........ 53

**2020 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛАЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕ ҮТӘЛЕШЕНЕҢ ГОМУМИ МОНИТОРИНГЫ**

2.1. 2020 елда Татарстан Республикасында төп демографик тенденцияләр ........ 62

2.2. 2020 елда Татарстан Республикасында бала хокукларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән төп гамәлләр һәм чаралар ........ 65

2.3. 2020 елда федераль һәм республика законнарында бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре өлкәсендәге яңалыкларга күзәтү ........ 72

**2020 ЕЛДА ТӨП ТОРМЫШ ЭШЧӘНЛЕГЕ ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ БАЛА ХОКУКЛАРЫН ҮТӘҮ**

3.1. Баланың белем алу өлкәсендә хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү ........ 82

*3.1.1. Мәктәпкәчә белем* ........ 82

*3.1.2. Гомуми белем бирү* ........ 86

*3.1.3. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга белем бирү* ....97
3.2. Баланың яшәү һәм гаиләдә тәрбияләнү хокукын үтәү ....106
*3.2.1. Гаиләдә иминлек булмау проблемалары* ....106
*3.2.2. Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру* ....115
*3.2.3. Баланың гаиләгә хокукын гамәлгә ашыру проблемалары һәм, гаиләдә конфликтлар булганда, гаилә эчендәге бәйләнешләр* ....121
3.3. Социаль тәэмин итү хокукын үтәү ....127
3.4. Баланың торак, башка мөлкәти хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү ....132
*3.4.1. Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын үтәү* ....133
*3.4.2. Күпбалалы гаиләләрнең торак хокукларын үтәү* ....136
*3.4.3. Инвалид балалары булган гаиләләрнең торак хокукларын үтәү* ....137
*3.4.4. Балигъ булмаганнарның башка мөлкәти хокукларын яклау* ....139
3.5. Баланың сәламәтлеген саклауга һәм сәламәт үсешкә хокукын үтәү ....141
*3.5.1. Балалар сәламәтлеге торышына гомуми анализ* ....141
*3.5.2. Балаларның сәламәтлеккә хокукларын тәэмин итүнең проблемалы аерым мәсьәләләре* ....149
*3.5.3. Балаларның ялы һәм аларны савыктыру* ....158
3.6. Баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклануга һәм иминлеккә хокукын тәэмин итү ....162
*3.6.1. Балаларның тышкы сәбәпләрдән үлүен анализлау* ....162
*3.6.2. Рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклану хокукын тәэмин итү* ....178
3.7. Балалар закон белән конфликтта ....181

ЙОМГАКЛАУ ....188

# КЕРЕШ

***«Илебез Президенты Владимир Владимирович Путинның илкүләм максатлар турындагы Указын гамәлгә ашыру кысаларында безгә үзебезнең үсеш программаларына төзәтмәләр кертергә кирәк булачак. Шул ук вакытта безнең төп бурыч – кешеләрнең керемен арттыру һәм тормыш сыйфатын яхшырту. Барлык дәрәҗәдәге хакимиятнең һәм тармакларның эшчәнлеге нәкъ менә шуңа юнәлдерелергә тиеш. Тормыш дәрәҗәсеннән халыкның канәгать булуы – безнең эшне бәяләүдә төп критерий».***

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2020 елның 24 сентябрендәге Юлламасыннан

Балачакны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү максатларында, 2012–2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең илкүләм стратегиясен (алга таба – Илкүләм стратегия) тормышка ашыру барышында ирешелгән нәтиҗәләрне исәпкә алып, Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2018–2027 еллар Балачак унъеллыгы дип игълан ителде. Илкүләм стратегияне кабул итү XXI гасырда балалар хокукларын яклау өлкәсендә заманча дәүләт сәясәтенең яңа этабын башлап җибәрү булды. Имин һәм якланган балачакны тәэмин итү Россиянең төп илкүләм өстенлекләренең берсе һәм дәүләт белән җәмгыятьнең уртак тырышлыгы нәтиҗәсе ул.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында 2020 ел йомгаклары буенча еллык доклад Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (алга таба – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил) тарафыннан «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – Закон) 13 статьясы нигезендә әзерләнде.

Доклад, гадәттәгечә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан, федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнарыннан, республика муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарыннан Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан соратып алынган рәсми дәүләт статистикасы белешмәләрен, мәгълүмати-аналитика материалларны, гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен, республиканың төрле балалар учреждениеләрендә үткәрелгән тикшерүләр һәм аларда булып кайтулар нәтиҗәләрен, балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашында аерым мәсьәләләр каралган төрле координацион һәм киңәшмә органнары эше барышында, киңәшмәләрдә, очрашуларда, конференцияләрдә, «түгәрәк өстәлләр»дә катнашканда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил алган мәгълүматларны өйрәнүгә, анализлауга һәм гомумиләштерүгә нигезләнә.

Доклад Законның 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә җибәрелә.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ ҺӘМ АНЫҢ АППАРАТЫНЫҢ 2020 ЕЛДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ

1


БҮЛЕК

## 1.1. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшчәнлеге

2020 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 1 787 мөрәҗәгать керде, шулар кысаларында 2000ләп проблема билгеләнде. Бу 2019 елдагыга караганда 183 мөрәҗәгатькә (9,2%ка) азрак.

*1 нче диаграмма*

***2016-2020 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр динамикасы***





Барлык мөрәҗәгатьләрнең 61,5%ы (1 098) язма мөрәҗәгатьләр иде.

2020 ел дәвамында гражданнарның мөрәҗәгатьләре ***динамикасын*** анализлаудан күренгәнчә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каравына гражданнардан ай саен уртача 147 мөрәҗәгать кергән (2019 елда – 164).

*2 нче диаграмма*

***2020 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнар мөрәҗәгатьләре динамикасы***




2020 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хезмәте тарафыннан **84 гражданны шәхсән кабул итү оештырылды**, шуннан 59ы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан кабул ителде, 26сы – Аппарат хезмәткәрләре тарафыннан.

Шәхсән кабул итүләр кысаларында барлыгы 341 граждан кабул ителде: 281 граждан (82%) Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итте, тагын 60 граждан (18%) Аппарат белгечләреннән ярдәм һәм консультацияләр алды.

2020 елда республиканың муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында **гражданнарны күчмә кабул итү** практикасы дәвам итте. Күчмә кабул итүләр ел саен раслана торган график нигезендә план буенча башкарылды.



2020 елда Татарстан Республикасы районнарына чыгып, 7 күчмә кабул итү уздырылды, болар: Югары Ослан, Алабуга, Кукмара, Мамадыш, Нурлат, Теләче, Балык Бистәсе муниципаль районнары.

Бер күчмә кабул итү Россиянең Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Удмуртия Республикасы буенча Ижевск тәрбия колониясе Федераль казна учреждениесендә оештырылды.

2020 елда федераль һәм республика дәүләт хакимияте органнары, иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре һәм вәкилләре белән берлектә 14 **уртак кабул итү** уздырылды:





Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ларионова Т.П. белән Алабуга муниципаль районында (03.03.20);

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе җитәкчесенең беренче урынбасары Олейник П.М. белән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында (01.12.2020);

Татарстан Республикасы Прокуроры И.С. Нәфыйков белән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында (21.07.2020, 19.11.20);

Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары Дәминов О.А. белән Мамадыш муниципаль районында (26.06.2020);

Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары Долгов М.Ш. белән Алабуга муниципаль районында (03.03.20);

Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары Наумова Ю.И. белән Нурлат муниципаль районында (26.02.2020);

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары Әсәдуллина А. М. белән Алабуга муниципаль районында (03.03.20);

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе җитәкчесе Закиров А.Ф. белән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында (08.09.2020, 24.11.2020);

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе җитәкчесе урынбасары Михайлов А.В. белән Балык Бистәсе муниципаль районында (10.12.2020);

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре Гарифуллина И.Х. белән Югары Ослан (30.10.2020), Алабуга (03.03.2020), Кукмара (16.11.2020), Теләче (03.11.2020), Балык Бистәсе (10.12.2020), Мамадыш (26.06.2020), Нурлат (27.02.2020) муниципаль районнарында;

«Хокук зонасы» хокукый яклау оешмасы координаторы Булат Мөхәммәтҗанов белән «Игелекле эшләр» хәйрия фонды тарафыннан төзелгән хатын-кызлар өчен кризис үзәкләренең берсендә (28.07.2020).





Шулай ук гражданнарны кабул итү дә оештырылды:

“Бердәм Россия” партиясе рәисенең иҗтимагый кабул итү бүлегендә (07.12.20);

Россия Федерациясе Президентының иҗтимагый кабул итү бүлмәсендә (14.05.2020, 15.09.2020).

Яңа короновирус инфекциясе буенча эпидемиологик вәзгыятькә, республика территориясендә урнаштырылган махсус эпидемиологик режимга бәйле ел үзенчәлекләрен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил тарафыннан гражданнарны телефон аша кабул итү практикага кертелде. Мондый кабул итүләр, шәхсән кабул итүләрдән тыш, барлыгы 11 мәртәбә үткәрелде, алар кысаларында 36 гражданга консультацияләр бирелде.





Уртак кабул итүләрнең күп өлеше (14 кешенең 8е) республиканың муниципаль районнарына һәм шәһәр округларына чыгып үткәрелде. 2020 елда гражданнарны уртак кабул итүләрдә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә 122 кеше мөрәҗәгать итте.

Авыр тормыш хәлендә калган балалар мәнфәгатьләрендә берничә мәртәбә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән гражданнарны кабул итү оештырылды. Мондый вәзгыятьләр аерым игътибарда булды һәм алар балалар мәнфәгатьләрендә хәл ителгәнчегә кадәр контрольдә торды.

2020 елда тукландыруны оештыру мәсьәләләре буенча **«кайнар линия» телефоны** эше оештырылды, аңа гомуми белем бирү оешмаларында балаларны тукландыруны оештыруга бәйле 27 мөрәҗәгать керде. Тикшерү үткәрүне таләп иткән гражданнар мөрәҗәгатьләре Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы Идарәсенә җибәрелде. Санитария законнарының таләпләре бозылу мәсьәләләре буенча тиешле эш башкарылды: 15 гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре адресына санитария законнарын бозуларны бетерү буенча кичекмәстән чаралар күрү турында хатлар җибәрелде, күрелгән чаралар турында Россия кулланучылар күзәтчелегенең (Роспотребнадзорның) Татарстан Республикасы Идарәсенә хәбәр итү соралды.



**Психологик ярдәм күрсәтү көннәре** ихтыяҗга әверелде. Психологик ярдәм күрсәтү өчен «Балалар авыллары-SOS» Россия комитетының, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Татарстан Республикасында «Ориентир» психологик хезмәтләр эшчәнлеген координацияләү буенча ресурс үзәгенең гаиләне ныгыту программасы буенча педагог-психологлары, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының балаларга һәм яшьләргә социаль хезмәт күрсәтү «Ышаныч» комплексы үзәге белгечләре, “Татарстан Республикасы мәктәп психологлары ассоциациясе”нең “Параллель” коммерциячел булмаган партнерлыгы җитәкчесе, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе Э.Х. Башлай җәлеп ителде.





Әлеге чара кысаларында өлкәннәр һәм балалар үзләрен борчыган темаларга, шул исәптән балалар-ата-аналар мөнәсәбәтләре, яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләр, яшүсмерләр арасында конфликтлар һәм психологик пландагы башка «балалар» мәсьәләләре (проблемалары) буенча һөнәри психологлар белән конфиденциаль аралаша, һөнәри консультацияләр һәм киңәшләр ала алдылар. Барлыгы 33 гаиләгә консультация бирелде. Консультация нәтиҗәләре буенча 7 гаилә күзәтү астына алынды һәм алга таба уртак эш алып бару оештырылды.

## 1.2. 2020 елда гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау нигезендә Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләрнең гомуми мониторингы

2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына проблемалы мәсьәләләр буенча 1 787 мөрәҗәгать керде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау нигезендә балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү өлкәсендә проблемалы мәсьәләләрнең түбәндәге **тематикасы** төзелә.

*3 нче диаграмма*


***2020 елда Вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы***




2020 елда мөрәҗәгатьләрнең беренче өчлеген баланың белем алуга, гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә һәм социаль тәэмин ителешкә хокукларын тормышка ашыру мәсьәләләре булды.

*4 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда Вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр тематикасының структурасы***




*1 нче таблица*

***2019 – 2020 елларда Вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр тематикасы***

| **Мөрәҗәгатьләр тематикасы** | **Барысы** | | **Үзгәрешләр динамикасы (%)** |
|---|---|---|---|
| | **2019 ел** | **2020 ел** | |
| **Барысы** | **2069** | **1787** | -13,6% |
| Белемгә хокук | **601** | **406** | -32,4% |
| Гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә хокук | **547** | **389** | -28,9% |
| Социаль тәэмин ителешкә хокук | **213** | **371** | +74,2% |
| Торакка хокук | **335** | **282** | -15,8% |
| Яшәүгә һәм сәламәтлек саклау хезмәтләренә хокук | **157** | **88** | -43,9% |
| Лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокук | **124** | **159** | +28,2% |
| Көч кулланудан яклануга хокук | **54** | **53** | -1,9% |
| Гражданлыкка хокук | **16** | **12** | -25,0% |
| Башка мөрәҗәгатьләр | **22** | **27** | +22,8% |

2020 елда мөрәҗәгатьләр саны буенча беренче урында **балаларның белем алуга хокукын** гамәлгә ашыру мәсьәләләре булды.

Әлеге тематика буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 406 мөрәҗәгать керде, бу мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 23% тәшкил итә, ә 2019 ел белән чагыштырганда 32%ка кимрәк.

*5 нче диаграмма*

***2020 елда белемгә хокукны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасының структурасы***




*2 нче таблица*

***2019 – 2020 елларда белемгә хокукны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасының динамикасы***

| Мөрәҗәгатьләр тематикасы | Барысы | | Үзгәрешләр динамикасы |
|---|---|---|---|
| | 2019 ел | 2020 ел | |
| **Барысы** | **689** | **406** | -41,1% |
| Мәктәпкәчә учреждениеләрдә урыннар бирү | **142** | **158** | +11,3% |
| Мәгариф учреждениеләрендә конфликтлар | **132** | **107** | -19% |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны укыту | **70** | **44** | -37,1% |
| Укучыларны белем бирү оешмаларына алу йә күчерү | **211** | **37** | -82,5% |
| Белем бирү оешмаларында туклануны оештыру | **38** | **24** | -36,8% |
| Укыту-тәрбия процессын оештыру, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты | **79** | **22** | -72% |
| Белем бирү оешмаларын бетерү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау һәм яңа мәктәпләр төзү | **7** | **3** | -57,1% |
| Укучыларга һәм тәрбияләнүчеләргә транспорт хезмәте күрсәтү | **7** | **5** | -28,6% |

Мәгариф мәсьәләләренә бәйле мөрәҗәгатьләр саны 2020 елда 41%ка ким булды.

Әлеге тематикага караган сорауларның күпчелеге (158 яки 39%) балаларның мәктәпкәчә белем алуга булган хокукларын тормышка ашыру мәсьәләләренә багышланган иде. Мондый мөрәҗәгатьләр саны 2019 ел белән чагыштырганда 11,3 %ка артыграк булды.

Мәктәпкәчә белем алуга хокукны гамәлгә ашыру турында гражданнар мөрәҗәгатьләре арасында:

48% (76 мөрәҗәгать) – өч яшькә кадәрге балаларга балалар бакчасында урын бирүгә ярдәм итү мәсьәләләре;

47% (74 мөрәҗәгать) – 3 яшьтән зуррак балаларга балалар бакчасында урын бирүгә ярдәм итү мәсьәләләре;

5% (8 мөрәҗәгать) – сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга балалар бакчаларында урыннар бирү.

Мәгариф өлкәсендәге мөрәҗәгатьләр саны буенча белем бирү процессында катнашучылар арасындагы конфликтларга бәйле мәсьәләләр икенче урында тора. Мондый мөрәҗәгатьләр 2020 елда 19%ка ким булды һәм 107% тәшкил итте.

2020 елда укучыларны гомуми белем бирү оешмаларына алуга йә күчерүгә (82,5%ка) һәм белем бирү оешмаларында укыту-тәрбия процессын оештыруга, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатына (76%ка) бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьләрнең шактый кимүе күзәтелә.

Шулай ук сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балаларны укытуны оештыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр саны өчтән бергә кимеде. 2019 елда мондый мөрәҗәгатьләр 70 булса, 2020 елда – 44.

2020 елда мөрәҗәгатьләр саны буенча икенче урынга балаларның **гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә** хокукларын яклау мәсьәләләре чыкты. Шул ук вакытта 2020 елда әлеге тематика буенча мөрәҗәгатьләрнең кимүе күзәтелә, аларның саны 2019 ел белән чагыштырганда 29%ка ким булды. Әлеге тематика буенча 389 мөрәҗәгать каралды, бу мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынннан 28% тәшкил итә.

*6 нчы диаграмма*

***2020 елда гаилә мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематиксының структурасы***




*3 нче таблица*

***2019-2020 елларда гаилә мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр динамикасы***

| Мөрәҗәгатьләр тематикасы | Барысы | | Үзгәрешләр динамикасы (%) |
|---|---|---|---|
| | 2019 ел | 2020 ел | |
| **Барысы** | **556** | **389** | -30% |
| Ата-аналары аерылганнан соң, аларның берәрсе вафат булганнан соң балаларны тәрбияләү мәсьәләләре | **233** | **154** | -34% |
| Гаиләдәге хәтәрлекләр турында хәбәр итү | **116** | **103** | -11,2% |
| Опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеге, балаларны опекага (попечительлеккә) тапшыру, уллыкка алу мәсьәләләре | **145** | **73** | -49,7% |
| Ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү мәсьәләсен күтәреп чыгу | **31** | **39** | +25,8% |
| Балаларны законсыз рәвештә алып китү һәм җибәрмичә тоту | **18** | **12** | -33,3% |
| Ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән ата-аналарның балаларын кире кайтару теләге | **6** | **8** | 33,3% |

Бала хокукларын яклау һәм гаилә элемтәләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасында беренче урында (тематика буенча мөрәҗәгатьләрнең 40%ы), гадәттәгечә, ата-анасы аерылышканнан соң баланың яшәү урынын ачыклауга, аның аерым яшәүче атасы яисә анасы белән, башка туганнары белән аралашу тәртибен билгеләүгә, бала белән аралашуга каршылыкларны бетерү кебек бәхәсле хәлләргә бәйле шикаятьләр тора. Гаилә эчендәге мондый бәхәсле мәсьәләләрне хәл итүдә булышуны сорап, 2020 елда 154 мөрәҗәгать керде, бу 2019 ел белән чагыштырганда 34%ка күбрәк.

2020 елда гаиләләрнең социаль яктан имин булмавы, гражданнарның үзләренең ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәмәүләре, шул исәптән балаларга карата мәрхәмәтсезлек күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьләр саны 11,2%ка кимеде һәм шундый темага 103 мөрәҗәгать керде. Әмма гаилә мәсьәләләре буенча гомуми мөрәҗәгатьләр арасында әлеге категория мөрәҗәгатьләр өлеше артты, ул 26% тәшкил итте (2019 елда – 116 мөрәҗәгать, 21%).

Опека һәм попечительлек органнары эшчәнлегенә, балаларны опекага (попечительлеккә) тапшыру, уллыкка алуга бәйле рәвештә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр саны ике мәртәбә кимеде. 2019 елда шундый 145 мөрәҗәгать каралган булса, 2020 елда 73 булды, бу әлеге категориядәге мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 19% тәшкил итә.

2017 елдан башлап, чит гражданнар тарафыннан балаларны законсыз рәвештә гаиләдән алуга яисә аларны гаиләдән алу нияте булуга, шулай ук аларны кайтармыйча тотуга карата Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнар шикаятьләре белән мөрәҗәгать итүләр кимүгә бара. 2020 елда мондый очраклар 2019 елга караганда өчтән бер өлешкә кимеде (2019 елда – 18, 2020 елда – 12).

2020 елда ата-аналарны ата-ана хокукыннан мәхрүм итүдә ярдәм күрсәтү мәсьәләсе буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре саны 25,8%ка артты. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына шундый 39 мөрәҗәгать керде (2019 елда – 31).

Ата-ана хокуклары чикләнгән яисә алардан мәхрүм ителгән гражданнардан аларга балаларын тәрбияләү өчен кире кайтару үтенече белән кергән берничә мөрәҗәгать бар, аларның саны – 8.

Мөрәҗәгатьләр саны буенча өченче урында балаларны **социаль тәэмин итү** мәсьәләләре тора. 2020 елда мондый мөрәҗәгатьләр 74%ка артты һәм аларның саны 371 булды, ягъни Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына кергән мөрәҗәгатьләрнең 21%ын тәшкил итте (2019 елда – 213).

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны 11,5%ка кимегәндә, 2020 елда социаль тәэмин итү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр саны 74%ка артты һәм 2019 елдагы мөрәҗәгатьләр проблемасы рейтингында бишенче позициядән 2020 елда өченче урынга күтәрелде.

Бу тематика буенча мөрәҗәгатьләр санының артуы 2018-2020 елларда гамәлгә ашырыла башлаган, шул исәптән яңа короновирус инфекциясе буенча эпидемиологик вәзгыять аркасында республика территориясендә кертелгән махсус эпидемиологик режимга бәйле яңа социаль ярдәм чаралары билгеләнү белән дә аңлатыла, 2020 елда төрле социаль түләүләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр саны артты. Әлеге мәсьәләләр буенча 210 мөрәҗәгать булды, бу 2019 ел белән чагыштырганда ике тапкырга диярлек күбрәк (2019 елда – 114). 70 мөрәҗәгать арасында балалы гаиләләргә дәүләт ярдәме чаралары кысаларында федераль, төбәк һәм муниципаль бюджетлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган социаль түләүләрне вакытында алу (күчерү) буенча гражданнар хокукларын тормышка ашыруга бәйле иде, шулардан:

32 мөрәҗәгать түләүләрнең тәртибе һәм кагыйдәләре турында аңлатмалар таләп итүгә бәйле;

6 мөрәҗәгать балаларыннан аерым яшәүче ата-аналар тарафыннан пособиеләр алуга һәм аларны балалар мәнфәгатьләрендә тотмауга бәйле;

11 мөрәҗәгать балалы гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү өчен балаларның яшь категориясен 16 яшьтән 18 яшькә кадәр күтәрү мәсьәләсенә кагылышлы иде;

21 мөрәҗәгать, мөрәҗәгать итүчеләр фикеренчә, социаль яклау органнары тарафыннан пособиеләр түләүдән баш тартуның законсыз булуына бәйле.

Инвалид балаларны техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча 6 мөрәҗәгать керде, шифаханә-курортта дәвалануны тәэмин итү буенча – 4 мөрәҗәгать, болар каралучы тематика буенча гомуми мөрәҗәгатьләрнең 13%ын тәшкил итте (2019 елда – 16%).

Мөрәҗәгатьләр саны буенча дүртенче урында **балаларның торак хокукларын** тормышка ашыру мәсьәләләре тора. 2020 елда мондый мөрәҗәгатьләрнең кимүе күзәтелде. 2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына әлеге темага 282 мөрәҗәгать керде, бу барлык мөрәҗәгатьләрнең 16%ын тәшкил итә (2019 елда – 335 мөрәҗәгать, 17%).

*7 нче диаграмма*

***2020 елда балаларның торак хокукларын яклау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы***




*4 нче таблица*

***2019 – 2020 елларда балаларның торак хокукларын яклау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр динамикасы***

| Мөрәҗәгатьләр тематикасы | Барысы | | Үзгәрешләр динамикасы (%) |
|---|---|---|---|
| | 2019 ел | 2020 ел | |
| **Барысы** | **339** | **282** | **-16,8%** |
| Гаиләнең торак шартларын яхшырту мәсьәләләре | **97** | **109** | **+12,4%** |
| Торак мәсьәләләрен суд тәртибендә хәл итү | **69** | **64** | **-7,2%** |
| Күпбалалы гаиләләрне һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү | **44** | **31** | **-29,5%** |
| Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү | **37** | **25** | **-32,4%** |
| Ата-анасы аерылышуга бәйле рәвештә баланы теркәүдән төшерү, торактан чыгару | **28** | **14** | **-50%** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Гаиләләрне авария хәлендәге торактан чыгару мәсьәләләре | **20** | **5** | **-75%** |
| Кредит йөкләмәләре буенча бурыч булуга бәйле рәвештә балаларны торактан чыгару, теркәүдән төшерү | **22** | **15** | **-31,8%** |
| Бу тематика буенча башка мөрәҗәгатьләр (шул исәптән торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү, торак төзү өчен җир бүлеп бирү мәсьәләләре буенча) | **22** | **19** | **-13,6%** |

Гаиләнең торак шартларын яхшырту мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле 109 мөрәҗәгать керде, бу 2019 ел күрсәткеченнән 12,4%ка күбрәк.

Торак мәсьәләләрен суд тәртибендә хәл итүгә бәйле мөрәҗәгатьләр саны 2019 ел дәрәҗәсендә диярлек калды (2019 елда – 69, 2020 елда – 64).

Күпбалалы гаиләләрнең һәм инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләрнең торак шартларын яхшырту мәсьәләләре буенча 31 мөрәҗәгать керде, аларның саны 2019 ел белән чагыштырганда өчтән бер өлешкә кимеде.

2020 елда шулай ук ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча шикаятьләр саны да өчтән бер өлешкә кимеде.

Ата-аналарының кредит йөкләмәләре буенча бурычлары булу аркасында балаларны торактан чыгару, теркәүдән төшерү мәсьәләләре буенча 22 мөрәҗәгать итүче булды.

Мөрәҗәгатьләр саны буенча бишенче урынны балаларның **лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокуклары бозылуга** бәйле мәсьәләләр алып тора – 159 мөрәҗәгать (9%). Мондый мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны узган ел белән чагыштырганда 28,2%ка артты. Гадәттәгечә, болар – ата-аналарның балаларны карау буенча үз бурычларын тиешенчә үтәмәве, шул исәптән алимент йөкләмәләренең үтәлмәве, милек мәсьәләләрен хәл итү, ата-аналары вафат булганнан соң балаларның мирас мәсьәләләре турындагы шикаятьләр. 2020 елда гражданнардан алиментлар түләүдән читләшүче ата-аналарына һәм суд приставлары-үтәтүчеләргә карата 95 шикаять килде (бу тема буенча кергән мөрәҗәгатьләр санынннан 60% тәшкил итә). Шул ук вакытта бу 2019 елга караганда 20%ка кимрәк (2019 елда – 118 мөрәҗәгать).

Балаларның **сыйфатлы медицина хезмәтләреннән файдалану хокукын яклау** мәсьәләләре алтынчы урында тора, шундый 88 мөрәҗәгать керде (мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 5%), бу 2019 елдагыдан ике тапкыр кимрәк (2019 елда – 157 мөрәҗәгать яисә 8%). Әлеге категория мөрәҗәгатьләр медицина учреждениеләрендә балаларга медицина хезмәте күрсәтүнең тиешле сыйфатта булмавына, табибларның үз функциональ бурычларын тиешенчә үтәмәвенә, балаларны дарулар белән тәэмин итүгә, инвалид балаларны савыктыру продуктлары белән тәэмин итүгә, сөт кухнясы продуктларын ташламалы алуга бәйле мәсьәләләрне хәл итүне сорап язылган иде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләренең саны буенча җиденче урынны б***алаларны аларга карата барлык төр көч кулланудан һәм рәхимсезлектән*** яклау буенча мөрәҗәгатьләр алып тора. Әлеге тематика буенча мөрәҗәгатьләр саны 2018 елдан бирле бер дәрәҗәдә кала: 2020 елда – 53 мөрәҗәгать, бу тема буенча мөрәҗәгатьләр өлеше 3% тәшкил итте (2019 елда – 3% яисә 54 мөрәҗәгать, 2018 елда – 55 мөрәҗәгать яисә 3%). Элеккеге кебек үк, гражданнар мөрәҗәгатьләре өчен, гариза бирүче фикеренчә, җинаять эшләрен кузгатудан нигезсез баш тартулар, хокук саклау органнары эшчәнлегенә, аларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр белдерү, гаиләдә балаларга карата ата-аналары (туганнары, өйдәшләре) тарафыннан көч куллану, рәхимсезлек күрсәтү мәсьәләләре сәбәп булып тора.

Мөрәҗәгатьләр саны буенча соңгы паспорт алганда, теркәү исәбенә басканда, гражданлыкны билгеләгәндә ***балигъ булмаганнарның гражданлык хокуклары бозылу*** турындагы мөрәҗәгатьләр тора. 2020 елда мондый мөрәҗәгатьләр 12 булды, 2019 елда – 18.

Яңа короновирус инфекциясе буенча эпидемиологик вәзгыять, республика территориясендә махсус эпидемиологик режим гамәлләре чорында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге, социаль челтәрләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары мониторингы, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау барышында балаларның һәм авыр тормыш хәлендә калган балалы гаиләләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга бәйле мәсьәләләр ачыклана.

Сорауларны түбәндәге төркемнәргә бүләргә мөмкин:

Балаларга белем бирүне, шул исәптән мәктәпкәчә белем бирүне оештыру;

балалы гаиләләргә азык-төлек җыелмалары белән ярдәм итү;

балаларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру;

мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең эше;

балигъ булмаганнарның ата-аналары яки башка законлы вәкилләре тарафыннан балигъ булмаган балаларны карау һәм тәрбияләү бурычларын үтәмәүгә бәйле мәсьәләләр;

аерым яшәүче ата-аналар белән аралашу тәртибе;

эшләмәүче дәүләт органнары аркасында документлар, шул исәптән опека буенча документларны рәсмиләштерүдә барлыкка килә торган мәсьәләләр.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында булган барлык мәсьәләләр профильле министрлыклар, җирле үзидарә органнары белән бергәләп каралды һәм балалар мәнфәгатьләрендә хәл ителде.

**Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре буенча** гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлаудан күренгәнчә, мөрәҗәгатьләрнең күбесе, гадәттәгечә, балигъ булмаганнарның ата-аналарыннан килә, аларның саны – 1 399 яки 70% (2019 елда – 1371 яки 79,2% иде).

*5 нче таблица*

***2019 – 2020 елларда Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән гражданнар категорияләре***

| Гражданнар категорияләре | 2019 ел | 2020 ел | |
|---|---|---|---|
| | | саны | гомуми саннан % |
| Ата-аналар | 1371 | 1399 | 79,2% |
| Башка туганнар | 253 | 147 | 8,3% |
| Башка затлар (чит гражданнар, күршеләр һ.б.лар) | 110 | 77 | 4,4% |
| Опекуннар һәм попечительләр | 83 | 58 | 3,3% |
| Балигъ булмаганнар | 34 | 18 | 1,0% |
| Иҗтимагый оешмалар вәкилләре | 39 | 31 | 1,8% |
| Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар | 35 | 18 | 1,0% |
| Балалар учреждениеләре җитәкчеләре, хезмәткәрләре | 33 | 19 | 1,1% |

2020 елда турыдан-туры балаларның үзләреннән 18 мөрәҗәгать керде, бу мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 1% тәшкил итте (2019 елда – 34 мөрәҗәгать).

Балигъ булмаган балалар мөрәҗәгатьләренең тематикасы түбәндәгечә иде:

яңа короновирус инфекциясе буенча эпидемиологик вәзгыять чорында гаиләгә матди ярдәм күрсәтү, республика территориясендә махсус эпидемиологик режимның гамәлдә булуы мәсьәләләре (1 мөрәҗәгать);

ата-аналарны ата-ана хокукыннан мәхрүм итү (3 мөрәҗәгать, 1 гариза бирүче);

балалар һәм аларның ата-аналары тарафыннан гражданлык алу мәсьәләләре (4 мөрәҗәгать);

ата-аналар гамәлләре белән килешмәү, телефонда ата-аналар контроле урнаштырылган булу мәсьәләләре (1 гариза бирүче);

баланы хосусыйлаштыруга кертмичә фатирны хосусыйлаштыру мәсьәләсе (1 мөрәҗәгать);

җинаятьләр тикшерүгә бәйләнешле тикшерү чаралары уздыруга бәйле мәсьәләләр (2 мөрәҗәгать);

мәктәптә туклануны оештыру (6 мөрәҗәгать).


Гражданнар мөрәҗәгатьләрен аларның **географиясе** өлешендә анализлаудан күренгәнчә, 2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итүчеләрнең 1 567е (89%) – Татарстан Республикасында яшәүчеләр, 42 мөрәҗәгать итүче (2,4%) – башка илләрдә һәм Россия Федерациясе субъектларында яшәүчеләр, 158 мөрәҗәгать итүче (8,6%) үзләре турында шәхси белешмәләр күрсәтмәгән яисә аларны хәбәр итүдән баш тарткан.

2020 ел дәвамында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Россиянең башка төбәкләрендә яшәүчеләрдән турыдан-туры яисә төбәкләрдәге бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр аша: Свердловск өлкәсеннән, Башкортостан Республикасыннан, Киров өлкәсеннән, Мәскәү өлкәсеннән, Хакасия Республикасыннан, Удмуртия Республикасыннан, Ленинград өлкәсеннән, Ульяновск өлкәсеннән, Төмән өлкәсеннән, Краснодар краеннан, Кострома өлкәсеннән, Тула өлкәсеннән, Самара өлкәсеннән, Рязань өлкәсеннән 42 мөрәҗәгать (гомуми мөрәҗәгатьләр санынннан 2,4%) килде, шулар арасында 8 мөрәҗәгать – чит ил гражданнарыннан (Төркия, Япония, Украина, Болгария, Кыргызстан, Үзбәкстан, Казахстан, Таҗикстаннан).

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 1007се шикаятьләр. 2020 елда мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынннан шикаятьләр өлеше 57% тәшкил итте. Калган 760 мөрәҗәгать – башка төрле мөрәҗәгатьләр (мәгълүмат, аңлатмалар, консультацияләр бирү, ярдәм күрсәтү турында үтенечнамәләр).

*8 нче диаграмма*


***2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрне төрләре буенча бүлү***




2020 елда, 2019 ел белән чагыштырганда, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына кергән шикаятьләр саны 5,6%ка кимегән, мәгълүмат, аңлатмалар, консультацияләр бирүгә, ярдәм күрсәтүгә бәйле мөрәҗәгатьләр саны 11%ка арткан (46%тан 57%ка кадәр).

*9 нчы диаграмма*


***2016 – 2020 елларда шикаятьләр һәм башка мөрәҗәгатьләр өлешләренә чагыштырма анализ***




***Шикаятьләр бирү субъектлары*** буенча шикаятьләрне түбәндәгечә структуралалаштырырга мөмкин.

*10 нчы диаграмма*

***2020 елда шикаятьләрне шикаять бирелү субъектлары буенча бүлү***




2020 елда елда шикаять бирелү субъектларына барлык дәрәҗәдәге гавами хакимият органнары (федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары), суд органнары, төрле оешмаларның җитәкчеләре һәм гражданнар керә.

2020 ел нәтиҗәләре буенча иң күп шикаять (27%) җирле үзидарә органнарына карата керде.

Икенче урында – гражданнарның гамәлләренә шикаятьләр (24%).

Шикаять бирелү субъектлары арасында өченче урында – төрле оешмаларның җитәкчеләре һәм вазыйфаи затлары (22%).

Мөрәҗәгатьләрнең 11%ында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына карата шикаятьләр иде.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары гамәлләренә һәм карарларына карата канәгатьсезлек белдерелгән шикаятьләр 10% тәшкил итте.

Мөрәҗәгатьләрнең 8%ында суд органнары карарларына канәгатьсезлек белдерелгән.

Гомумән алганда, 2020 елда гражданнарның шикаятьләрен карау нәтиҗәләре буенча 49,7% очракта квалификацияле консультацияләр һәм бала хокукларын яклау ысуллары һәм чаралары турында аңлатмалар бирелде. 506 мөрәҗәгать контрольгә алынды, аларның

278 очрагында ел дәвамында мәсьәләнең уңай хәл ителүенә ирешелде, калган очракларда бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызуда ярдәм күрсәтелде,

Тикшерү нәтиҗәләре буенча гражданнарның шикаятьләре буенча тиешле органнар һәм вазыйфаи затлар адресына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 40 бәяләмәсе әзерләнде һәм җибәрелде.

## 1.3. Хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, балалар өчен оешмалар тарафыннан балаларның хокукларын һәм аларның законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру, үтәү һәм яклау механизмнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген мониторинглау һәм анализлау

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләре нигезендә мөстәкыйль рәвештә яисә Татарстан Республикасының компетентлы дәүләт органнары һәм вазыйфаи затлар белән берлектә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының, белем бирү һәм медицина оешмаларының, балаларга һәм балалы гаиләләргә социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның, аларның вазыйфаи затларының эшчәнлеген, шулай ук бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозу фактлары турындагы хәбәрләрне дә тикшерә.

2020 елда ***гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча*** 655 шикаять тикшерелде. Гражданнарның шикаятьләрен карау нәтиҗәләре буенча 49,7% очракта бала хокукларын яклау ысуллары һәм чаралары турында квалификацияле консультацияләр һәм аңлатмалар бирелде. 506 мөрәҗәгать контрольгә алынды, аларның 278 очрагында ел дәвамында мәсьәләнең уңай хәл ителүенә ирешелде, калган очракларда бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызуда ярдәм күрсәтелде; Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Аппарат хезмәткәрләре катнашында 28 күчмә тикшерү оештырылды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча гражданнарның шикаятьләре буенча тиешле органнар һәм вазыйфаи затлар адресына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 40 бәяләмәсе әзерләнде һәм җибәрелде, шул исәптән түбәндәгеләргә:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына (3);

Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлегенә (2);

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына (1);

«Метроэлектротранс» МУПка (1)

республиканың түбәндәге муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары адресына (32):

Әгерже муниципаль районы (1);

Әлмәт муниципаль районы (2);

Биектау муниципаль районы (1);

Бөгелмә муниципаль районы (3);

Югары Ослан муниципаль районы (1);

Кама Тамагы муниципаль районы (1)

Лениногорск муниципаль районы (2);

Түбән Кама муниципаль районы (1);

Зәй муниципаль районы (1);

Менделеевск муниципаль районы (1);

Чаллы шәһәр округы (5);

Казан шәһәре шәһәр округа (15).

Яңа короновирус инфекциясе буенча эпидемиологик вәзгыять чорында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге, социаль челтәрләрне һәм массакүләм мәгълүмат чараларын мониторинглау, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына килүче гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау барышында республика территориясендә аерым эпидемиологик режим кертелүгә бәйле рәвештә авыр тормыш хәлендә калган балаларның һәм балалы гаиләләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга кагылышлы аерым мәсьәләләр ачыкланды.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына республиканың муниципаль районнарыннан килгән мәгълүматларга караганда, 16 муниципаль районның 45 торак пунктында интернет булмау аркасында укучылар дистанцион укуларны оештыруда кыенлыклар кичергән. Шул уңайдан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры А.Р. Хәйруллинга мөрәҗәгать юлланды. Мәсьәлә оператив рәвештә эшкә алынды.



2020 елда бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу фактлары турында, шул исәптән иҗтимагый резонанс алган очраклар буенча массакүләм мәгълүмат чараларында чыккан ***35 хәбәр һәм мәгълүмат та*** Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибар үзәгендә булды.

Уздырылган тикшерү чаралары йомгаклары буенча күрсәтелгән фактлар буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Балигъ булмаганнарның хокуклары бозылу һәм аларга карата тиешле чаралар күрелергә тиешлеге турында 8 бәяләмә җибәрде, шул исәптән түбәндәгеләргә дә:

Актаныш муниципаль районы башлыгына (1);

Әлмәт муниципаль районы башлыгына (1);

Бөгелмә муниципаль районы башлыгына (3);

Казан шәһәренең Киров һәм Мәскәү районнары администрацияләре башлыгына (1);

Түбән Кама муниципаль районы башлыгына (1);

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (1).



2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ***үз инициативасы белән*** Балигъ булмаганнар өчен республиканың төрле төрдәге һәм ведомстводагы 31 учреждениесенә күчмә тикшерүләр үткәрде.

2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Алабуга, Зеленодольск, Лаеш, Нурлат муниципаль районнарындагы ятим балалар учреждениеләрендә (ятимнәр өчен балалар йортларында, сабыйлар йортында, интернат-мәктәпләрдә), социаль приютларда тәрбияләнүче балаларны тоту, тәрбияләү, дәвалау, тернәкләндерү, укыту, һөнәргә өйрәтү, аларның ялын оештыру, хокукларын тәэмин итү шартларын үзе чыгып тикшерде.



Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен «Нурлат балалар йорты» дәүләт бюджет учреждениесен барып тикшерү йомгаклары буенча ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тагын да яхшырак тәэмин итү максатында, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен «Нурлат балалар йорты» дәүләт бюджет учреждениесен капиталь ремонтлау программасына кертү, әлеге балалар йортын җиһазлар, кирәкле җайланмалар белән тәэмин итү, шулай ук аның территориясен төзекләндерү буенча эшләр башкару зарурлыгы турында таләпнамә җибәрелде.

Балалар лагерьларының балаларны кабул итүгә әзерлеген анализлау, куркынычсызлык таләпләрен үтәү максатларында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Нармонка» балаларны савыктыру лагеренда **(алга таба – БСЛ),** «Татарстан пионериясе» БСЛда, Лаеш районы территориясендә урнашкан “Ял” “Балаларны һәм яшьләрне савыктыруны, ял иттерүне, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча шәһәр үзәге”ндә булды. Әлеге тикшерү барышында лагерь эшен оештырганда балаларны ял иттерү һәм савыктыру буенча стационар оешмаларны көйләүгә, тотуга һәм аларның эшен оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләрне бозу очраклары ачыкланды, шуңа бәйле рәвештә, гамәлгә куючы (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты) адресына хокук бозулар һәм аларны бетерү буенча чаралар күрү турында бәяләмә җибәрелде. Җитешсезлекләр бетерелде.

***Балалар өчен ябык типтагы махсус учреждениеләрдә*** торучы, закон белән конфликтка кергән балигъ булмаган балаларны тоту шартлары, укыту процессын оештыру, медицина ярдәме күрсәтү күзәтчелек итүнең төп предметы булып кала.

2020 ел дәвамында түбәндәгеләр тикшерелде:

“Россиянең Җәзалар үтәү буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 1 нче тикшерү изоляторы” федераль казна учреждениесе”;

Девиант холыклы балалар һәм яшүсмерләр өчен “1 нче Раифа махсус һөнәри училищесы” ябык типтагы федераль дәүләт бюджет махсус укыту-тәрбияләү учреждениесе;

“Россиянең Җәзалар үтәү буенча федераль хезмәтенең Удмуртия Республикасы буенча идарәсенең Ижевск тәрбияләү колониясе” федераль казна учреждениесе (алга таба – Ижевск тәрбияләү колониясе).

Ижевск тәрбияләү колониясендә тәрбияләнүчеләрне шәхсән кабул итү, тәрбиячеләр белән аралашу барышында учреждениедә уңайлы социаль-психологик климат булдыруга, җинаять юлына баскан яшүсмерләрне төзәтү, укыту һәм тәрбияләүдәге катлаулы эштә уңай нәтиҗәләргә ирешүгә ярдәм итә торган реабилитация киңлеген, спорт-савыктыру инфраструктурасын үстерү буенча теләкләр әйтелде.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов адресына әлеге учреждениедә тәрбияләнүче балалар өчен уңайлы шартлар тудыруга ярдәм итү һәм алар өчен кирәкле урам спорт җайланмалары һәм җиһазлары алу үтенече белән мөрәҗәгать итте. Мәсьәлә уңай хәл ителде.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2020 елдагы күзәтчелек эшчәнлегендә ***Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеген тикшерү дәвам итте***.

Республика районнарына һәм шәһәрләренә эш сәфәре кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасының 7 муниципаль районында бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы

муниципаль хезмәтләрнең (балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең, мәгариф идарәсе органнарының, опека һәм попечительлек, сәламәтлек саклау, социаль яклау органнарының һ.б.) эшчәнлегенә анализ ясады.

Күрсәтелгән эшчәнлекне өйрәнү нәтиҗәләре буенча ачыкланган хокук бозулар һәм эштәге җитешсезлекләр турында түбәндәге 7 муниципаль район (шәһәр округлары) башлыкларына эшчәнлекне камилләштерү буенча күрсәтмәләр белән 7 бәяләмә җибәрелде:

Югары Ослан муниципаль районы;

Алабуга муниципаль районы;

Мамадыш муниципаль районы;

Нурлат муниципаль районы;

Теләче муниципаль районы;

Балык Бистәсе муниципаль районы;

Кукмара муниципаль районы.

Нәтиҗәләрне карау нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлекләрдә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча адекват чаралар күрелде.

2016 елдан башлап Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты белгечләре ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларның «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларның эшчәнлеге һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны аларда урнаштыру турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 24 маендагы 481 номерлы карары таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләү буенча эксперт төркеме эшендә катнашалар.

2020 елда әлеге эксперт төркеме эше кысаларында ятим балалар өчен түбәндәге 3 оешма тикшерелде:

“Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен 11 нче Казан интернат-мәктәбе” ДБМУ;

“Акылга зәгыйфь балалар өчен Югары Утар балалар интернат-йорты” дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;

“Республика махсуслаштырылган сабыйлар йорты” сәламәтлек саклауның дәүләт казна учреждениесе.

Учреждениеләрнең түбәндәге эш юнәлешләре игътибар үзәгендә булды:

балаларны гаилә тәрбиясе принцибы буенча яшәүне оештыру (шул исәптән: тәрбия төркемнәрендә ризык әзерләү һәм туклану өчен бүлмәләр булу; социаль адаптация өчен шартлар булу; индивидуаль урыннар булдыру, шәхси әйберләрдән киртәләрсез файдалану мөмкинлеге булу, “гаилә” традицияләрен булдыру буенча чаралар оештыру; туган көннәрне бәйрәм итү);

ятим балаларны оешмага кабул итү (шул исәптән ятим балалар өчен оешмада баланы вакытлыча тору өчен шартлар тудыру);

тәрбияләнүчеләрнең хокукларын яклау (шул исәптән: үсеш һәм тормыш шартларын яхшырту буенча индивидуаль планнар төзү; ятим балалар өчен оешмалар администрациясенең һәм хезмәткәрләренең гамәлләре (гамәл кылмау) нәтиҗәсендә балаларның хокуклары бозылу; САНПИН үтәлеше турында Роспотребнадзор акты булу; чит затларның оешмага килеп йөрүләрен теркәү системасы булу; тәрбияләнүчеләр башбаштакланып китеп барган очракта, оешма хезмәткәрләренең эш регламентлары булу; барлык персоналны балага карата рәхимсезлек күрсәтү яки көч куллану фактларын танып белүгә өйрәтү турында мәгълүмат; көч куллануны яки рәхимсезлекне кичергән балалар белән тернәкләндерү эшен оештыру турында мәгълүмат);

балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыруда ярдәм итү;

ата-аналары гаризасы буенча оешмага урнаштырылган тәрбияләнүчеләр белән эшләү;

оешмада тәрбияләнүчеләргә белем бирү;

хезмәткәрләрнең һәм волонтерларның квалификациясен күтәрү;

оешмада тәрбияләнүчеләрнең ялын оештыру;

инвалид балаларны һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны тәрбияләү һәм карау үзенчәлекләре;

оешманың ачыклыгы һәм аннан һәркемнең файдалана алу мөмкинлеге.

Тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча хокук бозулар ачыкланмады.

***Тикшерү эшчәнлеге*** нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 2020 елда бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозу һәм аларны бетерү һәм алга таба булдырмау буенча чаралар күрү турында 52 нәтиҗә чыгарды.

Балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне анализлау һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итүгә бәйле ***мәсьәләләрне системалы хәл итү өчен*** Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан түбәндәге адресларга мөрәҗәгатьләр җибәрелде:

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановка (5 мөрәҗәгать);

Россия Федерациясе мәгариф министры С.С. Кравцовка (1 мөрәҗәгать);

Татарстан Республикасы Прокуроры И.С. Нәфыйкова (4 мөрәҗәгать);

Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисе И.И. Гыйләҗевка (1 мөрәҗәгать);

Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошинга (1 мөрәҗәгать);

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р. Фазлыевага (1 мөрәҗәгать);

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры И.Г. Һадиуллинга (2 мөрәҗәгать);

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры М.Н. Садыйковка (3 мөрәҗәгать);

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры М.М. Айзатуллинга (1 мөрәҗәгать);

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты рәисе А.В. Тыгинга (1 мөрәҗәгать);

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр комитеты рәисе С.М. Захаровага (1 мөрәҗәгать);

Татарстан Республикасы Автотранспорт предприятиеләре ассоциациясе рәисе С.Ю. Темляковка (1 мөрәҗәгать);

“ПАТП № 2” МУП җитәкчесе А.А. Мөхәммәтшинга (1 мөрәҗәгать);

“ПАТП № 4” МУП җитәкчесе А. Х. Исхаковка (1 мөрәҗәгать).

Тулырак мәгълүмат “Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар мәнфәгатьләрендә законнарны камилләштерүдә катнашуы” 1.5 бүлегендә һәм “Эшчәнлекнең төп өлкәләрендә хокукларны үтәү” 3 бүлегендә урнаштырылган.

## 1.4. Ведомство координация органнары эшчәнлеге

Республиканың балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәүне тәэмин итү буенча нәтиҗәле эшчәнлекне гамәлгә ашыру Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының конструктив хезмәттәшлегеннән башка мөмкин түгел.

2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бик яхшы үтәү һәм яклау мәсьәләләрен хәл иткәндә ведомствоара бәйләнешне һәм башкарма хакимиятнең кызыксынучы органнарының, контроль-күзәтчелек органнарының үзара килешеп эшләвен тәэмин итүгә юнәлдерелгән түбәндәге консультатив-киңәшмә органнары эшләде:

***Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координация комитеты*** (алга таба – Координация комитеты);

***Балигъ булмаганнарны гаиләдән аерып алу практикасын анализлау буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Эш төркеме*** (алга таба – Эш төркеме).

2020 елда Координация комитеты составына Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләре керде. Барлык мәсьәләләрне карау Татарстан Республикасы Прокуратурасы вәкилләре катнашында башкарыла.

2020 ел дәвамында Координация комитеты утырышларында балигъ булмаган балаларның тормыш шартларын яхшыртуга һәм балалар хокукларын бозуның аерым очраклары буенча, шул исәптән Кама Тамагы муниципаль районында (2 утырыш) һәм Зеленодольск муниципаль районында (2 утырыш), Казан шәһәренең Киров районында (1 күчмә утырыш) карарлар кабул итүгә бәйле проблемалы мәсьәләләр каралды.

***Мисал***. *Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә паспорт алуда ярдәм итү мәсьәләсе буенча 2004 елның 26 августында туган, балигъ булмаган Р. мөрәҗәгать итте.*

*Тикшерү барышында гариза бирүченең өч яшеннән 13 ел дәвамында Татарстан Республикасы Кама Тамагы районының Олы Бортас авылында яшәүче пенсионер хатын тәрбиясендә торуы, законлы вәкил тарафыннан тиешенчә карау һәм тәрбия булмавы ачыкланды.*



*Балигъ булмаган бала Р.ның әтисе Үзбәкстан гражданы, баланы тәрбияләүдә һәм аның тормышын җайга салуда катнашмаган. Баланы Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Олы Бортас авылында яшәүче 1953 елгы пенсионер Н. карамагына калдырып киткән. Баланың анасы Үзбәкстан Республикасында яши дип фаразлана. Балигъ булмаган Р. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10 сыйныф укучысы.*

*Бары тик 2019 елда гына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының ведомствоара муниципаль социаль-тернәкләндерү консилиумының 2019 елның 20 ноябрендәге 21 номерлы утырышы беркетмәсе белән Татарстан Республикасы Кама Тамагы районының опека һәм попечительлек органына балигъ булмаган Р.ның тормышын җайга салу эшен оештыру йөкләнде. .*

*Балигъ булмаган Р. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткәнчегә кадәр балигъ булмаган кыз баланың тормышын җайга салу мәсьәләсе белем бирү учреждениесе тарафыннан да, опека һәм попечительлек бүлеге тарафыннан хәл ителмәгән, балигъ булмаган баланың хокукларын яклау буенча чаралар күрелмәгән, опека оештырылмаган, балигъ булмаган балага социаль ярдәм чаралары күрелмәгән.*

*2020 елның 1 декабрендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координация комитеты утырышында Татарстан Республикасы Прокуратурасы,*



*Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Эчке эшләр идарәсе катнашында Р.Р.Рәхимҗановага һәм аның әтисенә Россия Федерациясе Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт бирү һәм алга таба Россия Федерациясе гражданлыгын бирү буенча килешүгә ирешелде һәм гамәлләр планы билгеләнде.*

*Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы адресына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан закон бозу һәм аларны бетерү буенча чаралар күрү турында бәяләмә җибәрелде.*

Балигъ булмаган бала хокукларын яклау буенча оператив ведомствоара эш нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2020 елның 29 декабрендәге № 39-О боерыгы белән дәүләт яклавы гарантияләрен тәэмин итүгә һәм баланың бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызуга булышлык күрсәткәннәре һәм дәүләт яклавы гарантияләрен тәэмин иткән өчен түбәндәгеләр Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Рәхмәт хаты белән бүләкләнделәр:

Сабиров И.М., “Чит ил гражданнарын медицина таныклавы буенча республика үзәге” ЖЧҖ җитәкчесе;

Мөхәммәтрәхимов Х.Г., Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр Министрлыгының Миграция мәсьәләләре буенча идарәсенең вакытлыча һәм даими яшәүгә документлар рәсмиләштерү бүлеге башлыгы;

Йосыпов У.Ю., шәхси эшкуар.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы әлеге эшче орган эшчәнлеге Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау механизмы буларак аның нәтиҗәлелеген практикада раслый.

2017 елдан Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2017 елның 30 гыйнварындагы 4606-МР номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында Балигъ булмаганнарны гаиләдән аерып алу практикасын анализлау буенча эшче төркем төзелде (алга таба – Эшче төркем), ул ведомствоара орган булды һәм аның эшчәнлегенең максаты – кулланыла торган чараларның артык булу яки гаиләгә законсыз тыкшыну күзлегеннән чыгып, балигъ булмаганнарны гаиләдән алу практикасына төрле яклап анализ ясау.

Эшче төркемнең бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

балаларны гаиләләрдән законсыз аерып алу очракларына мониторинг үткәрү;

балаларны гаиләләрдән аерып алу буенча чараларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар эшчәнлеген анализлау;

балаларны гаиләләрдән законсыз аерып алу очраклары буенча үткәрелгән чараларга экспертиза ясау;

балаларны гаиләләрдән аерып алу очракларын булдырмау буенча тәкъдимнәр эшләү.

2020 ел дәвамында гаиләләрдән балаларны аерып алу буенча тулаем республика буенча вәзгыятьне системалы рәвештә анализлаудан тыш, Эшче төркем гаиләләрдән балаларны тартып алу буенча гражданнардан кергән шикаятьләр буенча конкрет вәзгыятьләрне өйрәнде, анализлады, кирәк чакта, тиешле тәэсир итү чаралары күрде. Шулай итеп, ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Әлмәт, Югары Ослан, Алабуга, Зеленодольск, Зәй, Питрәч, Нурлат муниципаль районнарында, Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә балаларны гаиләләреннән аерып алу фактлары буенча граж-



даннардан 13 мөрәҗәгать керде. Балаларны аерып алу фактлары турында һәр хәбәр Эшче төркем әгъзалары тарафыннан тикшерелде.

Нәтиҗәдә, мөрәҗәгать итүчеләрнең мондый карарның законсызлыгы турындагы дәлилләре расланмады, балаларны гаиләдән аерып алу буенча күрелгән чаралар законлы һәм алар балаларны яклау мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашырылган дип табылды.

Балаларны гаиләдән аерып алу очракларын анализлау буенча эш республиканың муниципаль районнары дәрәҗәсендә системалы нигездә дәвам итте. Әлеге мониторинг 7 муниципаль берәмлектә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эш визиты кысаларында үткәрелде.

Мониторинг барышында муниципаль районда (шәһәр округында) балаларны гаиләдән аерып алу практикасын мониторинглау буенча опека һәм попечительлек органнарының координацияләү роленә, бала өчен үз гаиләсен саклау буенча профилактика субъектлары тарафыннан үз вакытында чаралар күрү, учреждениеләр хезмәткәрләре тарафыннан баланы тиз арада гаиләгә кайтару мәсьәләләренә, балаларның тормышын җайга салу буенча күрелә торган чараларга аерым игътибар бирелде.

## 1.5. Аналитик эшчәнлек

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләре нигезендә, календарь елы тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлешенә бәяләүне, шулай ук аларның хокукый хәлен камилләштерү турында тәкъдимнәрне үз эченә алган ***Еллык доклад*** әзерли.

2020 елда бала хокуклары үтәлешенең торышын анализлау йомгаклары буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлешенә бәяләүне үз эченә алган ***еллык доклад*** әзерләнде.

Төп басым Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә аның эшчәнлеге барышында билгеле булган республикада балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашырудагы проблемалы мәсьәләләрне тасвирлауга юнәлтелде. Мондый тасвирлау Бала хокуклары турында БМО конвенциясендә баланың түбәндәге беркетелгән төп хокуклары төрләре буенча бирелде:

мәгариф өлкәсендә бала хокукларын тәэмин итү;

баланың гаиоәдә яшәүгә һәм тәрбияләнүгә хокукын тәэмин итү;

баланың торак һәм милек хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү;

баланың сәламәтлеген саклауга һәм сәламәт үсешенә хокукын тәэмин итү; лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокукны тәэмин итү;

баланың социаль тәэминатка хокукын тәэмин итү;

баланың тормышка, рәхимсезлектән һәм үзенә карата көч куллanудан яклануга хокукын тәэмин итү.

2020 елның 12 мартында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының сигезенче утырышында докладның төп нигезләмәләре белән чыгыш ясады.

Күрсәтелгән доклад Законның 13 статьясы нигезендә шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Прокурорына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына җибәрелде.



Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2020 елның 12 мартындагы 351-VI ДС номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнарына, муниципаль берәмлекләр башлыкларына “2019 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында Бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында” Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил докладындагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар күрергә, шулай ук бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү буенча чаралар комплексын эшләргә тәкъдим ителде.

2020 елда эксперт-аналитик, контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан түбәндәге ***махсус докладлар*** әзерләнде:

“Махсус эпидемиологик режим гамәлдә булган чорда балаларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү турында”;

“Татарстан Республикасында демографик хәлне яхшырту буенча чаралар комплексы турында”.

2020 елда 8 муниципалитетка карата ***конкрет муниципаль районнар дәрәҗәсендә балаларның хокукларын үтәүнең торышына комплекслы анализ*** ясалды. Әлеге эш республика районнарына һәм шәһәр округларына Вәкаләтле вәкил тарафыннан эш визитларын әзерләү һәм уздыру кысаларында оештырылды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гарызнамәсе буенча районнар тарафыннан бирелә торган мәгълүмати-аналитик материаллар мониторингның нигезе булды.

Ачыкланган проблемалы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасының 7 муниципаль берәмлеге башлыгы адресына эшнең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм бала мәнфәгатьләрендәге мәсьәләләрне хәл итү буенча конкрет күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр белән бәяләмәләр җибәрелде.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратының компетенцияләре өлкәсенә керә торган мәсьәләләр буенча мәгълүмат кырын мониторинглау йомгаклары буенча түбәндәге профильле темалар ачыкланды:

1. Мәгариф өлкәсендә балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;
2. Балаларның иминлеккә хокукларын яклау;
3. Балаларның сәламәтлеген һәм сәламәт үсешен саклауга хокукларын яклау;
4. Балаларның гаиләдә яшәүгә һәм тәрбияләнүгә хокукларын яклау;
5. Баланың торак һәм башка мөлкәт хокукларын, шулай ук законлы мәнфәгатьләрен яклау;
6. Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын яклау;

7. Балаларның социаль тәэминатка хокукларын яклау;

8. Балигъ булмаган балаларның ата-аналары яки башка законлы вәкилләре тарафыннан балигъ булмаганнарны карау һәм тәрбияләү бурычларын үтәү.



Әлеге проблематика 2020 елның 7 декабрендә «Бердәм Россия» партиясе Рәисе Д.А. Медведевның кабул итү бүлмәсендә «Татарстан Республикасында балалар мәнфәгатьләре һәм аларның хокукларын яклау» темасына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең туры эфирда гражданнар белән онлайн режимында аралашуының нигезен тәшкил итте.



Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре белән туры эфирда интервьюлар циклын бирүче #ТатарстанОнлайн проектына карата интернет-аудиториянең һәм массакүләм мәгълүмат чараларының зур кызыксынуын исәпкә алып, югарыда аталган проблематика 2020 елның 25 декабрендә әлеге проект кысаларында узган туры эфирда да Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил чыгышының нигезен тәшкил итте. Интернет-аудитория белән әлеге очрашуда 2020 елга йомгаклар ясалды һәм 2021 елга максатлар һәм бурычлар анонсланды.

2020 елда балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне анализлау нәтиҗәләре буенча, закон чыгару инициативасы хокукы булмаганга күрә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә мөрәҗәгатьләр аша норматив-хокукый документларга үзгәрешләр кертү инициативасы белән чыкты:

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгына;

Татарстан Республикасы Премьер-министрына;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына;

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетына;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр комитетына.

## 1.6. Эш визитлары


2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең республиканың муниципаль районнарына эш визитларын оештыру һәм уздыру практикасы дәвам итте.

Яңа короновирус инфекциясе буенча эпидемиологик вәзгыятьне, республика территориясендә махсус эпидемиологик режимны исәпкә алып, ел дәвамында 8 эш визиты оештырылды.

Мондый эш рәвеше республиканың түбәндәге муниципаль берәмлекләрендә оештырылды: Югары Ослан, Алабуга, Зеленодольск, Мамадыш, Нурлат, Теләче, Балык Бистәсе, Кукмара районнарында.

*Карта*

***2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эш визитлары картасы***




Эш визитына әзерләнү кысаларында баланың түбәндәге хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлешенә Вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан мониторинг уздырыла:

балаларның белем алуга хокукын гамәлгә ашыру, шул исәптән: мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар кытлыгы булу, белем бирү процессында катнашучылар арасында конфликтлы вәзгыятьләр булу, аларны хәл итү, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны укыту, гаиләдә укыту һәм үзлегеннән белем алу рәвешендә белем алучы балаларны укытуны оештыру;

тәрбиягә бала алган ата-аналар тарафыннан опекунлык бурычлары һәм хокуклары үтәлешен, ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче гражданнарның опекун ата-аналары тарафыннан хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлешен, шул исәптән: балигъ булмаганнарның әлеге категориясен диспансеризацияләү, инвалид балаларны тернәкләндерү чараларын гамәлгә ашыру, ятим балаларны торак алу өчен исәпкә кую мәсьәләләрен контрольдә тоту буенча муниципаль районның опека һәм попечительлек органының үз вәкаләтләрен тиешенчә үтәве;

тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеге, шул исәптән опекага алынган балаларның җәйге ялын оештыру, аларны өстәмә белем бирү системасында эш белән тәэмин итү буенча контроль;

балаларны гаиләләрдән аерып алуның законлылыгы;

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль район комиссиясенең социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре белән эшләве, социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне Татарстан Республикасының бердәм белешмәләр банкы нигезендә реабилитацияләүнең индивидуаль программалары анализланды;

балигъ булмаганнарны карау өчен алимент түләүләре буенча бурычларны түләтү эшенең торышы;

республиканың социаль приютларында торучы балигъ булмаганнар белән индивидуаль профилактика эшен оештыру;

балигъ булмаганнар тарафыннан җинаятьләр кылуның һәм балигъ булмаганнарга карата җинаятьчелекнең торышы, сукбайлыкны профилактикалау;

эшкә урнашуда һәм көнкүрештә ярдәм итү, шулай ук җинаять-үтәтү системасы учреждениеләреннән азат ителгән яки ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләреннән кайткан балигъ булмаган балаларга башка төрле ярдәм күрсәтү;



балигъ булмаганнарның суицидаль халәтен профилактикалау мәсьәләләре;

профилактик прививкалардан һәм туберкулезны диагностикалаудан баш тарту мәсьәләләре;

балалар арасында инвалидлык торышы.

Әлеге эш нәтиҗәләре районда балигъ булмаганнарның хокуклары үтәлешен комплексы һәм системалы рәвештә бәяләргә мөмкинлек бирә.

Районда вәкаләтле вәкил эше ***муниципаль район башлыгы белән эшлекле очрашуны*** һәм конкрет муниципаль берәмлектә (шәһәр округында) бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итүнең актуаль мәсьәләләре турында фикер алышуларны күздә тота.



***Гражданнарны*** – район (шәһәр) халкын ***кабул итү*** шулай ук эш визитлары программасының мәҗбүри пункты булып тора. Республика районнарында һәм шәһәрләрендә гражданнарны күчмә кабул итү вакытында Бала хокуклары буенча вәкилгә барлыгы 40 кеше мөрәҗәгать итте

2020 елда эш визиты кысаларында 24 учреждениенең эшчәнлеге өйрәнелде, шул ук вакытта укучылар (тәрбияләнүчеләр) арасында хокук бозуларны беренчел профилактикалау, мәктәп укучыларының дәрестән тыш вакытта мәшгульлеге буенча ***белем бирү оешмаларының эшчәнлеген өйрәнүгә*** басым ясалды.

Тикшерү чараларын уздырганда проблемалы мәсьәләләр ачыклана һәм аларны бетерү буенча чаралар күрелә, шулай ук аерым вәзгыятьләр, эшнең нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр һәм аңлатмалар да бирелә, бу муниципаль хезмәтләр һәм оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри компетенцияләре дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итә. Тәҗрибә күрсәткәнчә, тикшерү эшчәнлегенең мондый рәвеше нәтиҗәлелек күзлегеннән караганда күпкә отышлырак.

Эш визиты кысаларында белем бирү оешмаларының эшчәнлеген анализлаудан күренгәнчә, кайбер муниципалитетларда укучылар булган гаиләләрнең имин булмавы ачыкланганда, белем бирү оешмалары администрациясе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 22 апрелендәге 294 номерлы «Социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасының бердәм мәгълүмат банкын булдыру турында” карары белән расланган «Социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасының бердәм мәгълүмат банкын булдыру Регламентында каралган “Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау” мәгълүмат системасында (алга таба – мәгълүмат системасы) сигнал карталарын

урнаштырмый. Кагыйдә буларак, хокук саклау органнарына, социаль яклау органнарына телдән хәбәр итәләр.

Мондый хәлдә бала проблемасын хәл итү һәм бу хәлгә балигъ булмаганнар арасында сукбайлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалауның барлык субъектларын җәлеп итү шактый озакка сузыла яки нинди дә булса сәбәпләр аркасында мәгълүмат тиешле урынга барып җитми.

Ачыкланган проблеманы, шулай ук педагоглар персоналының алышынып торуын исәпкә алып, педагоглар коллективларының гаиләдә иминлек булмауны иртә ачыклау эшенә төзәтмәләр кертү зарурлыгы турында нәтиҗә ясалды.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, «Балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, мәгълүмат системасы ресурсларыннан һәм сигнал карталарыннан файдаланып, гаилә иминлеген алдан ачыклау мәсьәләсен белем бирү оешмалары җитәкчеләре белән якындагы киңәшмәләрдә, педагоглар советларында карауны планлаштыру үтенече белән мөрәҗәгать җибәрде.



Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы ***муниципаль хезмәтләр*** (опека һәм попечительлек органнары, мәгариф идарәсе, сәламәтлек саклау, социаль яклау органнары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр һәм башкалар) ***эшчәнлеген анализлау*** һәр районда тиешле белгечләр һәм җитәкчеләр катнашында уздырылды. Аерым катлаулы һәм үзенчәлекле, гадәттән тыш хәлләр буенча мәсьәләләрне эш визитлары кысаларында карау проблемалы вәзгыятьләрне ачыкларга һәм аларны балигъ булмаган балалар мәнфәгатьләрендә хәл итүнең оптималь юлларын табарга мөмкинлек бирде.

Һәр районда эш визитына йомгаклар район прокуроры, субъектларның һәм профилактика учреждениеләренең җитәкчеләре, белгечләре ***катнашында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссиянең киңәйтелгән утырышында*** ясала.



Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эш визиты җирле массакүләм мәгълүмат чаралары белән бергә алып барыла, бу районның киң җәмәгатьчелеге игътибарын балалар хокукларын яхшырак тәэмин итү мәсьәләләренә җәлеп итәргә мөмкинлек бирә. Моннан тыш, барлыкка килә торган проблемаларны эш визитларын әзерләү һәм уздыру кысаларында хокук бозуларны һәм сукбайлыкны профилактикалау органнары һәм учреждениеләре белгечләре, җитәкчеләре белән бергә карау балалар өлкәсендә эшләүче белгечләрнең һөнәри компетенцияләрен арттыруга ярдәм итә.

Эш визиты йомгаклары буенча, балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен җитди, системалы бозу очраклары ачыкланган очракта, район башлыгы адресына тиешле бәяләмәләр җибәрелә. 2020 елда визит йомгаклары буенча 7 бәяләмә җибәрелде.

2021 елда эш визитларын уздыру практикасы дәвам итә.

## 1.7. Нормалар чыгару эшчәнлегендә катнашу


Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен дәүләт яклавы гарантияләрен яхшырак тәэмин итү максатын гамәлгә ашыру механизмнарының берсе – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар мәнфәгатьләрендәге законнарны камилләштерүдә катнашуы.

2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең нормалар чыгару эшчәнлеге норматив хокукый актлар проектларын килештерүдә катнашу һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына балалар мәнфәгатьләрендә аерым мәсьәләләр буенча хәлне яхшыртуга юнәлдерелгән системалы чаралар күрү өчен федераль (региональ) норматив-хокукый актларга үзгәрешләр кертү инициативасы белән мөрәҗәгать итү рәвешендә гамәлгә ашырылды.

2020 елда балигъ булмаганнарның законнар белән гарантияләнгән хокукларына, шулай ук аларның мәнфәгатьләренә туры килү-килмәвен алдан килештерүгә балигъ булмаганнарның хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы 70 федераль һәм республика норматив хокукый акты проектлары керде (2019 елда – 58).

*11 нче диаграмма*

***2016-2020 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан каралган федераль һәм республика норматив хокукый актлары саны***




Аерым алганда, болар түбәндәге закон проектлары:

1. “Россия Федерациясендә гаиләдә-көнкүрештә көч куллануны профилактикалау турында”;

2. “Вакытлыча эшкә сәләтсезлек очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 255-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” (вакытлыча эшкә сәләтсезлек, йөклелек һәм бала тудыру буенча пособиеләрне, бала карау буенча айлык пособиене, иминләштерелгән затның уртача эш хакыннан, хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән чыгып, район коэффициентларын исәпкә алып, исәпләү тәртибен төгәлләштерү өлешендә);

3. “Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында” Федераль законның 11 статьясына үзгәреш кертү хакында” (ана (гаилә) капиталы акчаларын (аларның бер

өлешен) Россия Федерациясе территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарда укучы баласы (балалары) тарафыннан белем алуга җибәрү мөмкинлеге турында);

4. “Россия Федерациясендә мәгариф турында” Федераль законга үзгәреш кертү хакында” (мәктәпкәчә белем бирү оешмасында урын бирелмәгән яшь ярымнан өч яшькә кадәрге балаларның ата-аналарына яисә законлы вәкилләренә компенсация билгеләү өлешендә);

5. “Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында” Федераль законның 1 статьясына үзгәреш кертү хакында” (авыр тормыш хәлендә калган балалар категорияләре исемлеген төгәлләштерү өлешендә);

6. “Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында” Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында” (ана (гаилә) капиталы акчаларын пенсия тупламасын формалаштыру өчен пенсия билгеләнү көненә кадәр кулланудан баш тарту хокукы турында);

7. “Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында” Федераль законның 3 статьясына үзгәреш кертү хакында” (2019 елның 1 гыйнварыннан башлап дүртенче бала тапкан (уллыкка алган) хатын-кызларда өстәмә дәүләт ярдәме чараларына хокук барлыкка килү турында);

8. “Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында” Федераль законның 14 статьясына һәм «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында” Федераль законның 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” (тыгызландырылган углеводородлы газлы, балигъ булмаганнар өчен потенциаль куркыныч булган көнкүреш товарлары сатуны чикләү өлешендә);

9. “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” (бала тормышына турыдан-туры куркыныч янаганда аны аерып алу турында);

10. “Россия Федерациясендә мәгариф турында” Федераль законның 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында”, дистанцион укытуның ихтыярый булу мәсьәләсе буенча;

11. “Гаилә институтын ныгыту максатларында Россия Федерациясе Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында” Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында”;

12. “Гаилә институтын ныгыту максатларында Россия Федерациясе Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында” Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Граждан кодексының 31 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” (опека турындагы кагыйдәләрне төгәлләштерү турында);

13. “Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында” Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында”;

14. “Россия Федерациясе Гаилә кодексының 55 статьясына һәм “Опека һәм попечительлек турында” Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” (балаларны бабаларында, әбиләрендә, балигъ булган бертуган абыйларында, апаларында һәм башка якын туганнарында вакытлыча тоту өлешендә);

15. “Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында” Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында” (мәгълүмати продукциягә экспертиза уздыручы экспертларны, эксперт оешмаларын аккредитацияләү процедуралары өлешендә);

16. “Аерым закон актларына балалы гаиләләр өчен өстәмә гарантияләр бирү өлешендә үзгәрешләр кертү турында” («Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында” Федераль законда каралган чараларның гамәлдә булу срогын чикләмәү хакында);

17. “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” (Россия Федерациясе Җинаять кодексының 157 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацында, “Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында” Россия Федерациясе Законының 4 статьясындагы 3 пунктына, “Корал турында” Федераль законның 19 статьясындагы 4 өлешенә, “Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында” Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешенә).

Үткәрелгән экспертиза нәтиҗәләре буенча закон проектларына тиешле бәяләмәләр әзерләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде, аларның икесе тискәре характерда һәм карала торган закон проектын республика исеменнән хупламаска кирәк дигән тәкъдимнәр күрсәтелде, бәяләмәнең тагын берсендә закон проектының ахыргы редакциясен әзерләгәндә исәпкә алырга тәкъдим ителгән искәрмә бирелде.

2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә алдан килештерүгә ***53 региональ норматив хокукый акт проекты*** кертелде.

Республика норматив хокукый актлары проектларын (Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре проектларын) рәсми килештерү аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертү стадиясендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла (әлеге Регламент белән 2013 елдан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бала хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив хокукый актлар проектларын килештерүдә катгый катнашырга тиешле вазыйфаи затлар исемлегенә кертелде). Республика законнары проектларын карауда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашуының тагын бер мөмкин формасы – закон проектлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары тарафыннан алдан карау стадиясендә Вәкаләтле вәкилгә кергән рәсми гарызнамәләр буенча бәяләмәләр бирү юлы белән катнашу һәм закон проектлары буенча эшләү өчен төзелә торган эшче төркемнәр утырышында комитетлар инициативасы белән катнашу.

Узган ел Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бала һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы түбәндәге ***11 Татарстан Республикасы законы проектын*** карауда катнашты:

1. “Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм “Балигъ булмаганнарга тәмәке булмаган никотинлы продукция, никотин үткәрә торган электрон системаларны сатуны тыю һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында”;

2. “Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында”;

3. “Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында”;

4. “Пенсиягә федераль социаль өстәмә күләмен билгеләү өчен Татарстан Республикасында 2021 елга пенсионерның яшәү минимумы күләмен билгеләү турында” Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында”;

5. “Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында”;

6. “Фән һәм фәнни эшчәнлек турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында”;

7. “Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында”;

8. “Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында”;


9. “Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”;

10. “Физик культура һәм спорт турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында”;

11. “Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Балигъ булмаганнарга тәмәке булмаган никотинлы продукция сатуны, никотин үткәрә торган электрон системаларны сатуны тыю һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында”.

*12 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы законнары проектларын алдан килештерүдә катнашуын тәэмин***




Төбәк законасты норматив хокукый актлар өлешендә 2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 40 карар һәм күрсәтмә проектлары һәм Татарстан Республикасы Президентының 2 указы проекты каралды, болар:

1. “2019 елның IV кварталы өчен Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында”;

2. “2020-2022 елларда Татарстан Республикасында “Демография” илкүләм проектының “Хатын-кызларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү – өч яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү шартларын булдыру” федераль проекты кысаларында” өч яшькә кадәрге баланы карау буенча ялда булган хатын-кызларны, шулай ук хезмәт мөнәсәбәтләрендә булмаган һәм эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән, мәктәпкәчә яшьтәге балалары булган хатын-кызларны яңадан укыту һәм квалификацияләрен күтәрү чараларын гамәлгә ашыру чаралары турында”

3. “Дәүләт казна учреждениесе тибын үзгәртү турында”;

4. “2020-2022 елларга «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп” федераль проекты кысаларында укучыларда заманча технологик һәм гуманитар күнекмәләр булдыру өчен матди-техник базаны яңарту чараларын гамәлгә ашыру турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 2 июлендәге 535 номерлы карары проекты”;

5. “Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү” дәүләт программасын раслау турында” 2013 елның 23 декабрендәге 1023 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган 2014 – 2025 елларга “Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү” дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында”;

6. “Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында” 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган “Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе”нә үзгәрешләр кертү хакында”;

7. “Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында” 2014 елның 31 декабрендәге 1101 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган “Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе”нә үзгәрешләр кертү хакында”;

8. “Казан шәһәре Яңа Савин районының “Инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган 165 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесен Татарстан Республикасы милкенә тапшыру турында”;

9. “Аутизм белән авыручы балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы югары белем бирү оешмасына ярдәм” гранты турында”;

10. “Республика психологик-медик-педагогик консультациясе” дәүләт казна учреждениесе тибын үзгәртү һәм аның исемен алыштыру турында”;

11. “Укучыларны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән тукландыру очраклары һәм тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 26 сентябрендәге 682 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында”;

12. “Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны карау” дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында”;

13. “Өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру” дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проекты;

14. “Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларында балаларны тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында”;

15. “Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында”;

16. “Казан шәһәре Яңа Савин районының «Казан шәһәренең инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган 165 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесен Татарстан Республикасы милкенә кабул итү турында”;

17. “Төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру буенча дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары турында”;

18. “2020-2022 елларга “Мәгариф” илкүләм проектының «Заманча мәктәп” федераль проекты кысаларында укучыларда заманча технологик һәм гуманитар күнекмәләр булдыру өчен матди-техник базаны яңарту чараларын гамәлгә ашыру турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 2 июлендәге 535 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында”;

19. “2020/2021 уку елында Татарстан Республикасында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү турында”;

20. “2020 елның II кварталы өчен Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында”;

21. “Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында”;

22.“Татарстан Республикасында иртә ярдәм күрсәтү системасын оештыру буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 6 сентябрендәге 790 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында”;

23. “Аутизм белән авыручы балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы югары белем бирү оешмасына ярдәм” гранты турында”;

24. “Электрон балалар бакчасы” автоматлаштырылган мәгълүмат системасын булдыру һәм алып бару тәртибен раслау турында”;

25. “Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү Тәртибен һәм Программасын раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 20 гыйнварындагы 878 номерлы карары белән расланган “Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү программасына үзгәрешләр кертү хакында”;

26. “2020 елның III кварталы өчен Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында”;

27. “Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе җинаять җаваплылыгы башлана торган яшькә җитмәгән балаларга карата, шул исәптән иҗтимагыйкуркыныч гамәлләр кылган балаларга карата медиация процедурасын куллану мәсьәләләре буенча эшче төркемне раслау турында”;

28. “Балалар төркемнәрен чыгаруны оештыру буенча Татарстан Республикасының ведомствоара бердәм электрон документлар әйләнеше системасында ведомствоара хезмәттәшлек турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 19 гыйнварындагы 19 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында”;

29. “Мәгариф” илкүләм проектының “Заманча мәктәп” федераль проекты кысаларында укучыларда заманча технологик һәм гуманитар күнекмәләр булдыру өчен матди-техник базаны яңарту чараларын гамәлгә ашыру турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 октябрендәге 960 номерлы карары белән расланган “2019-2021 елларга “Мәгариф” илкүләм проектының “Заманча мәктәп” федераль проекты кысаларында укучыларда заманча технологик һәм гуманитар күнекмәләр булдыру өчен матди-техник базаны яңарту чараларын гамәлгә ашыру концепциясенә үзгәрешләр кертү хакында”;

30. “2021-2023 елларда “Мәгариф” илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасының авыл җирлекләрендә һәм кече шәһәрләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында, табигый-фәнни һәм технологик юнәлешләрдәге мәгариф үзәкләрен булдыру һәм аларны эшләтү чараларын гамәлгә ашыру турында”;

31. «2019-2021 елларга “Мәгариф” илкүләм проектының “Заманча мәктәп” федераль проекты кысаларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны укытуга ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыру турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 октябрендәге 961 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында”; «2018 елның 29 октябрендәге 961 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары»;

32. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 17 июнендәге 443 номерлы карары белән расланган “2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларны тәрбияләүне үстерү стратегиясенең 2020 – 2022 елларда гамәлгә ашыру буенча чаралар планын раслау турында”;

33. “2020 – 2022 елларга медиакиңлектә балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү буенча чаралар планын («юл картасын») раслау турында”;

34. “2004 – 2005 елларда туган Россия Федерациясенең ир-ат җенесендәге гражданнарына планлы медицина тикшерүләре уздыру турында”;

35. “2020 – 2022 елларга медиакиңлектә балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү буенча чаралар планын («юл картасын») раслау турында”;

36. “Инвалидларны һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле затларны һөнәри әзерләү һәм эш белән тәэмин итү проблемалары буенча ведомствоара эшче төркем составына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 17 августындагы 1012-р номерлы карары белән расланган “Инвалидларны, инвалид балаларны һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле затларны һөнәргә өйрәтү һәм һөнәри укыту өчен махсус шартлар тәэмин итүче Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмалары исемлеге”нә үзгәрешләр кертү турында”;

37. “Сәләт” Халыкара яшьләр белем бирү форумының алты сменасын уздыру турында”;

38. “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер күрсәтмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында”;

39. “Балалар өчен интернат-йортларда яшәүче балаларның, шулай ук, тормыш сыйфатын яхшырту максатларында, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен булган оешмаларда күзәтчелеккә алынган балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тормышка ашыру, үтәү һәм яклау механизмнары эшенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча чараларның төбәк комплексын раслау турында”;


40. “Балалар өчен интернат-йортларда яшәүче балаларның, шулай ук, тормыш сыйфатын яхшырту максатларында, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен булган оешмаларда күзәтчелеккә алынган балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тормышка ашыру, үтәү һәм яклау механизмнары эшенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча чараларның төбәк комплексын раслау турында”;

41. “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт югары белем бирү оешмалары студентларына дәүләт өстәмә ярдәме чаралары турында” Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында”;

42. “Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия эшчәнлегенең оештыру мәсьәләләре турында” Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында”.

*13 нче диаграмма*

***2016-2020 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары проектларын алдан килештерүдә катнашуын тәэмин итү***



Югарыда күрсәтелгән белешмәләр шуны күрсәтә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 5 февралендәге 563 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентының 57 пункты таләпләрен (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелә торган балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы барлык норматив хокукый актлар проектларын Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә алдан килештерүгә җибәрүнең мәҗбүрилеге өлешендә) үтәү тәэмин ителгән.

2020 елда балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлешен анализлау һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан, закон чыгару инициативасы хокукы булмаганлыктан, бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итүгә бәйле системалы мәсьәләләрне хәл итү өчен аерым мәсьәләләр буенча хәлне яхшыртуга юнәлдерелгән берничә чара эшләнде.

| **Төбәк (федераль) норматив-хокукый актларга үзгәрешләр кертү өчен нигезләр** | **Күрелгән чаралар** |
|---|---|
| Россия Федерациясе Президентының “Балалы гаиләләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары турында” 2020 елның 7 апрелендәге 249 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына, Россия Федерациясе гражданлыгы булган 3тән 16 яшькә кадәрге һәр балага (2020 елның 1 июленә кадәр 16 яшь тулган очракта) – 10 000 сум күләмендә (бер мәртәбә түләнә)<br><br>Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 16 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалары булган һәм аларга күрсәтелгән социаль ярдәм чаралары кагылмаган гражданнардан каралган социаль ярдәм чараларын аларның категориясенә дә тарату зарурлыгы турындагы мәсьәлә белән мөрәҗәгатьләр керде. | Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын 16 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалары булган гражданнарга тарату турындагы мәсьәләне карау инициативасы белән мөрәҗәгать. |
| Белем бирүче оешмалар тарафыннан дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда куллануга тәкъдим ителә торган Федераль дәреслекләр исемлегендә белем бирү оешмаларының 3-4 сыйныфларында укучы начар күрүче балалар өчен уку әдәбияты юк. | Россия Федерациясе Мәгариф министры С.С.Кравцов адресына белем бирү оешмаларының 3 – 4 сыйныф укучылары өчен тиешле уку әдәбиятын Федераль дәреслекләр исемлегенә кертү турында, андый әдәбият булмаганда – аны эшләргә кирәклеге турында мөрәҗәгать. |

| | |
|---|---|
| Судлар фикеренчә, торак урыны өчен бурычлы гражданның үзе һәм аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары өчен әлеге торак даими яшәргә яраклы бердәнбер урын булу, әгәр торак урыны ипотека предметы (шартнамәчел яки законлы) булса да, аны түләү өчен алуга киртә була алмый. Шул ук вакытта, кредит буенча түләүләр, шул исәптән ана капиталы ярдәмендә дә кертелгән түләү факты түләтүченең-банкның ипотека торагын бурыч түләтү өчен алу таләбен үтәүдән баш тарту өчен нигез булмый.<br>РФ ГПКның 446 статьясындагы 1 пунктының 2, 3 абзацлары нигезендә бурычлының бердәнбер торагын бурыч түләтү өчен алу тыела. Әмма ул ипотека фатирына кагылмый. Әгәр бердәнбер күчемсез милек залогка салынган булса, аны бурыч өчен сату рөхсәт ителә. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктураны үстерү комитеты рәисе А.В. Тыгин  һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр комитеты рәисе С.М. Захарова адресларына залогка салынган күчемсез милекне ана капиталы акчалары кертелгән кредит буенча бурычларны түләттерү өчен алганда һәм алга таба гаилә әгъзаларын аннан чыгарганда балаларның торак хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләсен карау, балигъ булмаган балаларның милек иммунитетын яклау һәм «Ипотека (күчемсез милек залогы) турында» 1998 елның 16 июлендәге № 102-ФЗ Федераль законда, РФ ГПКның 446 статьясы аналогы буенча, бердәнбер торакны бурыч өчен түләүгә алырга ярамау мәсьәләсен карау үтенече белән мөрәҗәгать. |
| Балаларның тышкы сәбәплрдән үлү сәбәпләрен анализлау шуны күрсәтә: гадәттәгечә, балигъ булмаган балалар арасында иң күп үлем очраклары төрле бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә килеп чыга, иң еш очраганы – мәктәпкәчә яшьтәге балаларның тәрәзәдән сикерүе, шуңа бәйле рәвештә, балалар иминлеге һәм аларның тәрәзәдән сикерү куркынычын булдырмау максатында, махсус тәрәзә конструкцияләрен булдыру зарурлыгын карарга кирәк. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктураны үстерү комитеты рәисе А.В.Тыгин, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры М.М. Айзатуллина адресларына мөрәҗәгать – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Илкүләм стандартлар исемлеген һәм кагыйдәләр җыелмаларын (мондый стандартларның һәм кагыйдәләрнең өлешләрен) раслау турында” 2020 елның 4 июлендәге № 985 карары белән регламентламентланган кагыйдәләрнең тиешле җыелмаларына үзгәрешләр кертү инициативасы белән, аларны катгый рәвештә куллану нәтиҗәсендә “Биналарның һәм корылмаларның иминлеге турында техник регламент” һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Федераль закон таләпләрен балалар иминлеге һәм тәрәзәдән сикерү куркынычын булдырмау өлешендә үтәү тәэмин ителәчәк. |

| | |
|---|---|
| Балаларда сирәк очрый торган авыру: "беренчел үт кислоталары синтезының бозылуы" каорфан авырулар исемлегенә кертелмәгән, Татарстан Республикасында әлеге авыру белән 1 бала теркәлгән. Гражданнарның гомер озынлыгын кыскартуга яки инвалидлыкка китерә торган бу авыруның тормышка куркыныч тудыра һәм тиз хроник авыруга әверелә торган сирәк (орфан) авырулар исемлегендә булмавы баланы үз вакытында дару белән тәэмин итү мәсьәләсен шактый катлауландыра. | Авыруны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 26 апрелендәге 403 номерлы карары белән расланган Гражданнарның гомер озынлыгын кыскартуга яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авырулар исемлегенә кертү турында Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгына, аннары Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына тәкъдимнәр әзерләү буенча эш оештырылды. |
| Өч яшькә кадәрге баланың балалар өчен сөт ризыгы белән тәэмин итүгә хокукы турыдантуры ата-ананың милек белән тәэмин ителешенә бәйле. Шул ук вакытта, балигъ булмаган баланың ата-аналарының артык мәйданы яки җир соткалары бала туганчы (ягъни имин милек хәле чорында) сатып алынырга мөмкин булуы, алар тарафыннан керем чыганагы буларак файдаланылмавы һәм ата-аналарның акчалата гомуми кеременә йогынты ясамавы, милекнең артыграк күләмдә булуы (кайвакыт бу артык мәйдан 2 кв.м тәшкил итә) бу чорда (ата-аналар социаль яклау органнарына мөрәҗәгать иткән вакытта) ата-аналарның балалар сөт ризыгын мөстәкыйль сатып алу мөмкинлегенә йогынты ясамавы исәпкә алынмый. | Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошинга:«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ***кушымтада билгеләнгән*** «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү һәм аны оештыру буенча чыгымнарны финанслау тәртибе турында» 2009 елның 31 декабрендәге 933 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә өч яшькә кадәрге балаларга табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары биргәндә ***гаиләнең (гражданның) милек белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе турындагы нигезләмәне төшереп калдыру*** турындагы мәсьәләне карау үтенече белән мөрәҗәгать җибәрелде. |

## 1.8. Балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашу

2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашуы гамәлдәге федераль граждан-процессуаль һәм җинаять-процессуаль законнар белән бирелгән процессуаль хокуклар кысаларында гамәлгә ашырылды.


Бала хокукларын суд тәртибендә яклау бала мәнфәгатьләрен дәүләт тарафыннан тәэмин итү гарантиясе һәм ысулы булып тора, шуңа бәйле рәвештә, бала язмышы өчен әһәмиятле булган ата-ана хокукларын чикләү яки алардан мәхрүм итү, яшәү урынын билгеләү, аралашу тәртибен билгеләү кебек актлар һәм гамәлләр бары тик суд тәртибендә генә хәл ителергә тиеш.

Балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашу белән бәрәттән, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлегендә гражданнар-

га суд процессына әзерләнү яки судта граждан эшен карау кысаларында юридик ярдәм күрсәтү, процессуаль документлар төзүдә ярдәм итү һәм кирәкле материаллар туплауда булышу (алга таба – юридик ярдәм) кебек гамәлләр актив башкарыла.

*Диаграмма*

***2016 – 2020 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашкан яисә юридик ярдәм күрсәтелгән суд процесслары саны***




Узган хисап чорында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 20 суд эшендә катнашты (2016 елда – 25, 2017 елда – 31, 2018 елда – 29, 2019 елда – 29 эштә). Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашындагы барлык суд процессларының 16 очрагында ул – эш буенча якларның берсенең инициативасы буенча өченче як буларак һәм 4 очракта Россия Федерациясе Граждан-процессуаль кодексының 47 статьясындагы 2 өлешендә каралган тәртиптә судның үз инициативасы буенча җәлеп ителде.

2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең суд практикасын, юридик ярдәмне дә кертеп, түбәндәгеләргә бәйле бәхәсләр тәшкил итте:

баланың яшәү урынын билгеләүгә;

ата-ана хокукыннан мәхрүм итүгә (хокукын чикләүгә);

балигъ булмаганнарның торак хокукларын яклауга – фатирны сату-алу шартнамәсендә аның ¼ өлешен сатуны гамәлгә яраксыз дип тануга, Күчемсез мөлкәткә хокукларның бердәм дәүләт реестрында милеккә хокукны теркәү турындагы язуны торгызу турында бәхәскә;

сыйфатсыз медицина ярдәме күрсәтү белән китерелгән мораль зыянны түләтүгә;

бала тууга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган пособиене һәм балага яшь ярым булганчы түләнә торган айлык пособиене түләттерүгә;

дәүләт хакимияте органының законсыз гамәлләренә дәгъва белдерүгә, рөхсәт бозылган хокук бозуларны бетерүгә һәм социаль түләүне үтәтүгә;

махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны ятим балалар чираты исемлегенә кертүне дәгъвалауга;

кеше гомере өчен кирәкле дару препаратлары белән тәэмин итүгә;

алиментлар түләтүгә бәйле бәхәсләр.

2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең суд практикасындагы яңалык түбәндәге таләпләрне (гаризаларны) карауга бәйле суд процессларында катнашудан гыйбарәт булды:

фатирны сату-алу шартнамәсендә аның ¼ өлешен сатуны гамәлгә яраксыз дип тану, Күчемсез мөлкәткә хокукларның бердәм дәүләт реестрында милеккә хокукны теркәү турындагы язуны торгызу турында;

махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны ятим балалар чираты исемлегенә кертүдән баш тарту турындагы законсыз карарны дәгъвалау, ятим балаларны торак урыннар алу чиратына кертүне йөкләү.

Шуның белән бергә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашкан 20 суд бәхәсе буенча, балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү максатыннан, судка дәлилләнгән бәяләмәләр тапшырылды. Судларда ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашкан граждан эшләрен карау нәтиҗәләре буенча күпчелек очракта карарлар аның позициясен исәпкә алып чыгарылды.

Балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен суд тарафыннан яклауда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең актив катнашуы республика судларының балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәүгә бәйле бәхәсләрне, бала мәнфәгатьләреннән чыгып, законлы һәм гадел хәл итәргә омтылулары белән аңлатыла.

2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлегендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне Конституция суды эшчәнлегендә катнашуга җәлеп итү практикасы дәвам итте. Узган чорда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил “Татарстан Республикасы Конституция суды турында” Татарстан Республикасы Законының 51 статьясы тәртибендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән расланган “Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, аларны гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 12 пунктындагы өченче абзацының, 15 пунктының, 16 пунктындагы икенче абзацының һәм 17 пунктындагы өченче абзацының конституциячеллеген гражданнар А. Н. Болдырева һәм О. М. Серова шикаятьләренә бәйле рәвештә тикшерү турындагы эш буенча бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан суд эшендә катнашуга җәлеп ителде.

Суд органының югарыда күрсәтелгән конституциячел контроль инициативасы Татарстан Республикасында балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны, үтәүне һәм яклауны тәэмин итү буенча дәүләт системасының нәтиҗәле эшләвенә ярдәм итә.

Дәүләт хакимите органнарының, җирле үзидарә органнарының, аерым дәүләт яисә башка гавами вәкаләтләр бирелгән органнарның һәм оешмаларның, вазыйфаи затларның, дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрләрнең карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип тану турындагы административ дәгъва гаризалары белән «Россия Федерациясендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2018 елның 27 декабрендәге Федераль закон нигезендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең судка мөрәҗәгать итүе өчен нигезләр билгеләнмәгән.

## 1.9. Балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерү эшчәнлеге

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, муниципаль хакимият органнары, граждан җәмгыяте институтлары,

Россия Федерациясе субъектларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән хезмәттәшлеген үстерү балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны яхшырак тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы территориясендә ***федераль структуралар белән*** хезмәттәшлеге үзара мөнәсәбәтләр һәм хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.



2020 елда Татарстан Республикасында балаларны яклауның нәтиҗәле системасын булдыру һәм проблемалы мәсьәләләрне нәтиҗәле хәл итү максатларында, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе, Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Җәза үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе, «Медик-социаль экспертизаның Татарстан Республикасы буенча баш бюросы» федераль казна учреждениесе, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү буенча Татарстан Республикасы баш идарәсе, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе, Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе белән хезмәттәшлек турында имзаланган килешүләр нигезендә үзара эшлекле мөнәсәбәтләр дәвам итте.



Татарстан Республикасы территориясендә балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итүнең нәтиҗәле системасын үстерү, күрсәтелгән өлкәдә дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының үзара хезмәттәшлеге механизмнарын камилләштерү һәм балигъ булмаганнарның хокукларын бозу турындагы белешмәләргә оператив игътибар итү максатларында, 2020 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Татарстан Республикасы Прокуроры арасында үзара хезмәттәшлек турында яңа килешү имзаланды.

Федераль структуралар белән хезмәттәшлекнең нәтиҗәле форматлары түбәндәгеләр булды:

гражданнарны уртак кабул итү;

уртак тикшерүләр;

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы координацион киңәшмә органнары (Координация комитеты, Гаиләләрдән балаларны аерып алуны анализлау буенча эшче төркем) эшендә катнашу;

аерым мәсьәләләр буенча эш киңәшмәләре һәм консультацияләр практикасы.

2020 елда ***суд органнары белән*** хезмәттәшлек практикасы дәвам итте.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне судларда суд-граждан процесслары барышында балаларны яклауда катнашуга суд инициативасы буенча җәлеп итү аларның бала мәнфәгатьләрен мөмкин кадәр күбрәк исәпкә алган карарлар кабул итүдә кызыксынуын күрсәтә. Балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашу белән беррәттән, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлегендә суд процессына әзерлек кысаларында гражданнарга юридик ярдәм күрсәтү яки судта граждан

эшен карау кысаларында консультация бирү, процессуаль документлар төзүдә ярдәм итү һәм кирәкле материаллар җыюда булышу актив кулланыла.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау кысаларында ***Россия Федерациясе Дәүләт Думасының депутатлар корпусы белән*** хезмәттәшлек итү буенча эш дәвам итте.

***Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары белән*** уртак эшнең түбәндәге традицион форматлары дәвам итте:



Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт, мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетлары эшендә катнашуы;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе белән хезмәттәшлек итү;



Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең һәм депутатларның республика районнарына эш сәфәре кысаларында гражданнарны бергәләп кабул итүләре;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты каршындагы Эксперт советы составында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләренең әгъзалыгы.

Яңа эш форматы – «Яңа Гасыр» телеканалында «Безнең Республика – безнең эш» ток-шоуында эксперт сыйфатында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең катнашуы.



Әлеге проект Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатлары, профильле министрлыклар вәкилләре, иҗтимагый оешмалар активистлары, Татарстан иҗат коллективлары һәм журналистлар катнашында төрле проблемалар һәм мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен дискуссия мәйданчыгы булып тора. Программа темаларының берсе – “Мәктәптә тукландыру”. Карала торган мәсьәләләр арасында: мәктәптәге төшке ашларның сыйфаты, башлангыч сыйныф укучылары өчен типлаштырылган меню үзенчәлекләре, Татарстан Республикасында мәктәптә туклануны оештыруны бәяләү.

***Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән*** үзара хезмәттәшлек республика министрлыклары, ведомстволары, муниципаль органнар белән балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү вәзгыятен яхшы якка үзгәртү максатында актив партнерлык форматында төзелде.

2020 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгының Татарстан Республикасында психологик хезмәтләр эшчәнлеген җайга салу ресурс үзәге «Ориентир» арасында нәтиҗәле хезмәттәшлек итүнең беренче елы булды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты белгечләре 2020 елда Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатларында республиканың ***даими эшләүче ведомствоара, координация, киңәшмә органнары, эш төркемнәре, комиссияләре, шул исәптән түбәндәгеләр составында*** актив эшләделәр:

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе;

Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия;

Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе;

Балаларның һәм яшьләрнең җәйге ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру буенча ведомствара комиссиясе;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советы;

Татарстан Республикасының Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы торак комиссиясе;

Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе Координация советы;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты каршындагы Эксперт советы;

Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, хокук бозуларын профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем;

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларның «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар эшчәнлеге һәм аларда ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 24 маендагы 481 номерлы карары таләпләренә туры килүен бәяләү буенча эксперт төркеме.

Балаларны яклау эшендә хезмәттәшлекнең тагын бер юнәлеше – ***гражданлык җәмгыяте институтлары*** белән хезмәттәшлек.

2020 елда әлеге үзара хезмәттәшлектә түбәндәгеләр яңа партнерлар булды:

Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы,

“Кояшлы дөнья бүләк ит” хәйрия фонды,

Сәламәтлек саклау өлкәсендә ихтыярый ярдәмчеләрнең бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәте «Волонтер-медиклар»,




“Тормыш өчен” гаилә кыйммәтләрен яклауда социаль технологияләр агентлыгы» балалар тууын арттыруга ярдәм итү буенча коммерцияле булмаган автоном оешма.

2020 елда «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» төбәк иҗтимагый оешмасы, «АК БАРС ЯҢАРЫШ» хәйрия фонды, Анжела Вавилова ис. фонд, «Дом Роналда Макдоналда» хәйрия фонды, «Татарстан Республикасының күпбалалы гаиләләре» төбәк иҗтимагый оешмасы, «Гаилә канаты астында» төбәк иҗтимагый оешмасы, «УМАЙ» Идел буе гаилә академиясе”, «Умиление» аналарны яклау үзәге” коммерциягә карамаган автоном оешма, «Татарстан Республикасының «Параллель» мәктәп психологлары ассоциациясе” коммерциягә карамаган партнерлык, «Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы» коммерциягә карамаган оешма, «Инвалид балалар ата-аналарының Бөтенроссия оешмасы» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының төбәк бүлекчәсе, «Балалар хыялы» хәйрия фонды, «Детские деревни – SOS» Россия комитеты” төбәкара хәйрия иҗтимагый оешмасы фонды, “Хокук зонасы” хокукый яклау оешмасы координаторы Булат Мөхәммәтҗанов белән, «Игелекле эшләр» хәйрия фонды белән хезмәттәшлек итү үстерелде.



2020 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең үзара хезмәттәшлеге турында түбәндәгеләр белән яңа килешүләр имзаланды:

сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен “ДАРИМ АНГЕЛАМ РАДОСТЬ” коммерцияле булмаган автоном оешма белән;

Мөмкинлекләре чикле балаларга ярдәм итү буенча “Көч – балаларда” хәйрия фонды;

Татарстан Республикасының “Әтиләр Берлеге” төбәк иҗтимагый оешмасы”;

инвалид балаларның ата-аналары Бөтенроссия оешмасының Татарстан Республикасы төбәк бүлекчәсе.



2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Россия Федерациясе субъектларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән ***төбәкара хезмәттәшлекне*** дәвам итте.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән хезмәттәшлектә урнашкан формат нигезендә бала хокукларын яклауның актуаль проблемалары буенча мәгълүмати материаллар алмашу, бала хокуклары мәсьәләләре буенча ике яклы консультацияләр, бөтенроссия һәм төбәкара форумнарда, конференцияләрдә, семинарларда, киңәшмәләрдә катнашу оештырылды.

2020 елның 20 – 21 августында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе субъектларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең Бөтенроссия киңәшмәсендә катнашты.



Чарада Россия Федерациясе субъектларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр, профильле федераль министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре, экспертлар һәм белгечләр катнашты.

Чара кысаларында Россия Федерациясе субъектларында балалар өлкәсенең актуаль торышын бәяләүнең яңа моделен тәкъдир итү, мәктәп укучыларының туклану сыйфатын мониторинглауга йомгак ясау, шулай ук балаларга белем бирү өлкәсендәге проблемалар буенча, шул исәптән төбәкләрдә үткәрелә торган карантин чаралар шартларында фикер алышу узды, бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр институтын алга таба стратегик үстерү буенча тәкъдимнәр эшләнде.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил кушуы буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең Координация советы эшчәнлеге кысаларында түбәндәге мәсьәләләр буенча мониторинг оештырылды:

Татарстан Республикасында паллиатив ярдәм күрсәтү;

илдә коронавирус инфекциясенә (COVID-19) бәйле вәзгыять мониторингы турында;

Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында махсус азык-төлек таләп итәлә торган балаларны тукландыруны оештыру турында;

башлангыч сыйныфларда балаларны бушлай кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру турында;

мәгариф өлкәсендә балигъ булмаганнарның хокукларын яклау;

2020 елгы җәйге савыктыру кампаниясе йомгаклары буенча Татарстан Республикасында җәйге ялны оештыру турында;

мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерүнең төбәк тәҗрибәсе турында;

законнарны ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга торак бирү өлешендә камилләштерү турында.






Әлеге эш нәтиҗәләре Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле вәкилнең Россия Федерациясе субъектларында Бала хокуклары буенча төбәк вәкаләтле вәкилләр катнашындагы Бөтенроссия тематик киңәшмәләрендә һәм эшче төркемнәр утырышларында, шул исәптән селектор утырышларында тәкъдим ителде.

2020 елда яңа эш форматы Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең, О.Е. Кутафин исемендәге Мәскәү дәүләт юридик университетының Кеше хокуклары буенча фәнни-мәгариф үзәге белән бергәләп, “Балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү һәм үтәү буенча бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр эшчәнлегенең актуаль проблемалары” темасына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләренең һөнәри компетенцияләрен арттыру буенча хезмәттәшлек итүеннән гыйбарәт булды.

Балалар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасының нәтиҗәле эш тәҗрибәсе Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Оренбург өлкәсенең Коми Республикасында тәкъдим ителде.

Республикада Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институты эшләү дәверендә бердәм алымнар системасын эшләү, балалар хокукларын яхшырак тәэмин итүнең актуаль мәсьәләләре буенча иң яхшы тәҗрибәләр алмашу, Россиянең башка төбәкләрендә яшәүче балаларга конкрет ярдәм күрсәтү буенча Россия Федерациясе субъектларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр белән хезмәттәшлек итүнең тотрыклы тәҗрибәсе барлыкка килде.

2020 ел дәвамында Россия Федерациясенең башка субъектларындагы хезмәттәшләреннән, шул исәптән түбәндәгеләрдән, кергән үтенечләре буенча кайбер проблемалы мәсьәләләр Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан анализланды:

Чиләбе өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән – Әлмәт шәһәре территориясендә «Снеговики-добряки» хәйрия акциясен гамәлгә ашыру турында;

Саратов өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән – экологик иминлек мәсьәләләренә бәйле гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау турында;

Иваново өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән – девиант холыклы (җәмгыять өчен куркыныч), аерым шартларда тәрбияләүгә, укытуга мохтаҗ һәм махсус педагогик ысул таләп итә торган укучылар өчен ачык типтагы белем бирү оешмаларының эше турында;

Хабаровск краенда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән – Балигъ булмаганнарның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү турында;

Новосибирск өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән – табиб-фтизиатр бәяләмәсе булмаганда, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрү мәсьәләләре буенча; мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында ата-аналардан алына торган түләү турында;

Әстерхан өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән – социаль куркыныч хәлдә булган балалар һәм гаиләләр турында бердәм электрон банк төзү турында;

Киров өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән – төбәк законнарында каралган социаль түләүләрне бирү мәсьәләләре турында;

Тула өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән – балалар үлеме һәм имгәнүе очракларына бәйле эшне оештыру тәҗрибәсе турында;

Чувашия Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән – бэби-бокслар эшчәнлеге турында;

Ленинград өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән – “Балалы гаиләләргә ипотека торак кредитлары (заемнары) буенча йөкләмәләрне түләү өлешендә дәүләт ярдәме чаралары турында һәм “Гражданлык хәле актлары турында” Федераль законның 13.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 2019 елның 3 июлендәге 157-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Салым кодексына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе турында;

Түбән Новгород өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән – 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү тәҗрибәсе турында.

Идел буе федераль округында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең Координация советы әгъзасы буларак, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Совет утырышларын әзерләү һәм уздыру кысаларында хезмәттәшләре белән түбәндәге мәсьәләләрне карады:

балаларның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларын тәэмин итү;

“Россия Федерациясендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр турында” 2018 елның 27 декабрендәге 501-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында РФ субъектларында балалар хокукларын суд тарафыннан яклауны гамәлгә ашыру;

балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген реформалау һәм камилләштерү концепциясен эшләү буенча Ведомствоара эшче төркем төзү турында;

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен Бердәм буйсынудагы оешмага кучүнең оештыру моделен эшләү һәм Россия Федерациясе опека һәм попечительлек органнарын булдыру буенча Ведомствоара эшче төркем төзү турында;

Идел буе федераль округында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең мәгариф өлкәсендә балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау эшчәнлеге турында;

балалар хокукларын яклау контекстында мәгълүмати иминлек;

Балалар унъеллыгын тормышка ашыруның төбәк практикалары: тәҗрибә һәм перспективалар.

Идел буе федераль округында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең Координация советы түгәрәк өстәлләрендә шулай ук түбәндәге мәсьәләләр дә фикер алышу предметы булып торды:

Россия Федерациясе субъектларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр тарафыннан баланың яшәү урынын билгеләүгә, аны ата-анасының берсенә тапшыруга бәйле эшләр буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау; аерым яшәүче ата-ана белән баланың аралашу тәртибен билгеләү турында;

Россия Федерациясе субъектларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең еллык докладларын әзерләү турында: теория һәм тәҗрибә;

дәүләт органнары тарафыннан балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны һәм үтәүне тәэмин итү буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең актуаль проблемалары.

***Массакүләм мәгълүмат чаралары*** (алга таба – ММЧ) ***белән үзара мөнәсәбәтләр*** хезмәттәшлекнең мөһим юнәлешләренең берсе булып кала. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ММЧ белән эшләүнең төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: кирәкле/кызыктыргыч яки актуаль мәгълүмат бирергә, сорауларга җавап бирергә яки үз казанышлары һәм киләчәккә планнары белән уртаклашырга әзер булу; ММЧның теләсә кайсы вәкиле белән хезмәттәшлек итү өчен ачык булу.

ММЧ белән аралашуның тиешле форматлары булып телевидение тапшыруларында, «турыдан-туры линияләрдә» һәм интервьюларда катнашу, төрле басмаларга һәм интернет-басмаларга комментарийлар һәм интервьюлар бирү тора.

Безнең республиканың инвестиция куәтен алга этәрү кысаларында Татарстан Республикасының Инвестиция үсеше агентлыгы 2020 елның 30 августыннан 10 сентябренә кадәр «100% Татарстан» онлайн-чарасын оештырды.

«100% Татарстан» цифрлы платформасы социаль-икътисадый өлкәдә Татарстан Республикасы казанышларын күрсәтү, төбәкара һәм халыкара дәрәҗәләрдә уңай мәгълүмат фонын һәм төбәкнең имиджын өзлексез алга чыгару, шулай ук республика хакимияте органнары белән халык арасында үзара хезмәттәшлекнең яңа цифрлы рәвешләрен булдыру максатында эшлекле видеоконтент агрегаты булып хезмәт итте.

Әлеге чаралар кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институтын үстерүнең төп нәтиҗәләре, балалар хокукларын яклауга юнәлдерелгән проектлар тәкъдим ителде.




Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең социаль челтәрләрдә #ТатарстанОнлайн программасында катнашуы да яңа эш форматы булды. Әлеге программа Татарстан Республикасының рәсми бергәлекләрендә 2020 елның апреленнән чыга башлады. Әлеге проект кысаларында Татарстанлылар студия кунакларына онлайн режимда актуаль темалар буенча үз сорауларын бирә алалар.

25 декабрьдә “Бала хокуклары: ата-аналар нәрсә белергә тиеш?” Татарстанда Бала хокуклары ничек яклана? Яклау табу өчен кая мөрәҗәгать итәргә?” темасына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән #ТатарстанОнлайн программасында сәгать ярымлык туры эфир узды.



Әлеге сорауларга Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан җаваплар, шулай ук кулланучылардан сораулар ВКонтакте, Одноклассники һәм YouTube платформасында Татарстан Республикасының рәсми бергәлекләрендә бирелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә балалар мәнфәгатьләрендә нәтиҗәле хезмәттәшлек өчен рәхмәт белдерә һәм балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча кызыклы комментарийлар һәм актуаль белешмәләр алуда мөмкин кадәр күбрәк ярдәм күрсәтү, журналистларга материаллар әзерләүдә, балалар хокукларын яклау өлкәсендәге вакыйгалар турында мәгълүмат бирүдә ярдәм итү аша алга таба хезмәттәшлекне үстерүне күздә тота.

## 1.10. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең проект эшчәнлеге

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 2020 елда, бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү бурычларын хәл итеп, бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау үз компетенциясенә кергән дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлектә, бала хокукларын яклауның гамәлдәге рәвешләрен һәм чараларын үстерү һәм аларга яңаларын өстәү, бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү механизмнарын камилләштерүгә юнәлдерелгән берничә проектны гамәлгә ашыру буенча эшен дәвам итте.

### «Снеговики-добряки»




2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил республикада яңа проект – ***«Снеговики-добряки»*** хәйрия акциясен үткәрүне хуплап алды. Яңа ел алдыннан ЧТПЗ төркеме хәйрия акциясенең төп партнеры булды, ул коммерциячел булмаган оешмалар берләшмәсе һәм Россия балалар фонды тарафыннан оештырылган иде. ЧТПЗ төркеме ярдәме белән акция беренче тапкыр Татарстан Республикасында Чиләбе өлкәсендә һәм Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр ярдәме белән узды. Яңа ел бүләкләрен каты авырулар белән авыручы яки башка катлаулы тормыш хәлендә калган Әлмәт балалары да алды. «Снеговики-добряки» масштаблы акциясе кысаларында декабрь дәвамында барлыгы 700гә якын баланың хыяллары тормышка ашты.

### «Әниләргә бүләк»



2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ***«Әниләргә бүләк»*** дигән яңа проектка старт бирде, ул Җитлекми туган халыкара балалар көненә багышланган иде. Баланың вакытыннан алда тууы – барысы өчен дә зур сынау. Әмма мондый балалар туганнан башлап көрәшергә һәм җиңәргә өйрәнә, диләр белгечләр. Шуңа күрә яшьтәшләреннән ким үсмиләр алар. Вакытыннан алда дөньяга туган күренекле шәхесләрне тарих күп белә. Әлеге проект кысаларында ***«Кояш нуры бүләк ит»*** хәйрия фонды катнашында балалары вакытыннан алда туган әниләргә дә рдәм күрсәтелде. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ДРКБ дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең җитлекми туган балалар бүлегендә һәм РКБ дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең перинаталь үзәгендә булды. Ул килгәч, учреждениеләрнең медицина персоналы белән очрашу оештырылды һәм яңа туган балаларның әниләренә бүләкләр тапшырылды.

### «Балалар белән бергәләп укыйбыз»




2020 елның 25 маеннан 30 августына кадәр Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» төбәк иҗтимагый оешмасы белән берлектә социаль челтәрләрдә республика акциясен үткәрде. Акция гаиләләрнең балалар белән бергә ялын оештыруга, гаилә укуы традициясен

үстерүгә, баланың уңышлы, социаль актив шәхес булып җитешеүендә, аның интеллектуаль мөмкинлекләрен арттыруда китапның ролен күтәрүгә, балалар һәм яшүсмерләр арасында укуны популярлаштыруга юнәлтелгән.

Акциядә Татарстан Республикасында яшәүче төрле яшьтәге кешеләр катнашты. Алар социаль челтәрләрдә #читаемдетямрт хэштегы астында видеолар урнаштырдылар, аларда балалар яисә гаилә әгъзалары белән бергә яратып укый торган китаплардан фрагментлар, шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр укылды. «ВКонтакте» һәм «Instagram» социаль челтәрләре акция өчен төп платформа булды, аларда республиканың барлык муниципаль берәмлекләреннән 3000нән артык видео-эш бастырылды.

Акциядә республика министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре, муниципаль берәмлекләр башлыклары һәм Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре катнашты. Социаль әһәмиятле инициативаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ларионова Т.П., Татарстан Республикасы прокуроры Нәфыйков И.С., Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – мәгариф һәм фән министры Борһанов Р.Т., Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сабурская С.Х., Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе җитәкчесе Липский В.А., Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының Архив эше буенча рәисе Габдрахманова Г.З., Татарстан Республикасы мәдәният министры Әюпова И. Х., Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсе җитәкчесе Патяшин М. А., Татарстан Республикасының инвестиция үсеше агентлыгы җитәкчесе Миңнуллина Т.И., Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы Баш идарәсе башлыгы Хәбибуллин Р.З. катнаштылар.

### «Аек акыл»




2015 елдан Татарстан Республикасы Президенты ярдәме белән **«Аек акыл»** ведомствоара проекты гамәлгә ашырыла, ул алкоголизмнан интегүче ата-аналарны инновацион методика буенча алкогольле бәйлелектән республика бюджетыннан өстәмә финанслау хисабына дәвалауны күздә тота.

Проект Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе җитәкчелеге белән берлектә тормышка ашырыла.

Проект гаиләдә авыр һәм куркыныч тормыш хәлгә төшүнең төп сәбәбе булган – ата-аналарның алкогольгә бәйлелеген дәвалауда нәтиҗәле инструмент булып тора. Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2015 елдан башлап 246 кеше дәваланды. Дәвалауның тулы курсын уңышлы узып, 202 кеше (проектта катнашучыларның 82%ы) программаны тәмамладылар, бу 472 балага «Ятим» статусын алмыйча, үз гаиләләрендә яшәп калырга мөмкинлек бирде. Хәзерге вакытта тулы дәвалау курсы узган «Аек акыл» проекты пациентларында программа буенча дәвалану фонында уңай динамика һәм тотрыклы ремиссия күзәтелә. Проектны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру өчен гаилә һәм балалар иминлеген икенчел профилактикалау буенча өстәмә чара булып торучы иҗтимагый оешмаларның ресурслары җәлеп ителә.

Социаль ятимлекне профилактикалауга юнәлтелгән социаль әһәмиятле проектны уңышлы гамәлгә ашыруны исәпкә алып, Татарстан Республикасында Бала хокуклары бу-

енча вәкаләтле вәкил үтенече буенча Татарстан Республикасы Президенты 2021 елда «Аек акыл» проектын гамәлгә ашыруны дәвам итү һәм аны гамәлгә ашыру өчен 9 995,0 мең сум акча бүлеп бирү турында карар кабул итте, проектның яңа этабына 80 кеше кертеләчәк.

### «Психологик ярдәм көннәре»



2020 елда психологик ярдәм күрсәтү көннәрен үткәрү буенча эш дәвам итә. Әлеге чара кысаларында өлкәннәр һәм балалар үзләрен борчыган темаларга, шул исәптән балалар-ата-аналар мөнәсәбәтләре, яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләр, яшүсмерләр арасында конфликтлар, психологик планның башка «балалар» мәсьәләләре (проблемалары) буенча һөнәри психологлар белән аралаштылар, профессиональ консультацияләр һәм киңәшләр ала алдылар.

Гражданнарга консультация бирүне түбәндәге оешмаларның педагог-психологлары үткәрде:

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Ориентир» Татарстан Республикасында психологик хезмәтләр эшчәнлеген координацияләү ресурс үзәге;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының “Ышаныч” балаларга һәм яшьләргә социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге;

Россия комитеты гаиләсен ныгыту буенча “Балалар авыллары-SOS” программалары;

“Параллель” Татарстан Республикасы мәктәп психологлары ассоциациясе” коммерциячел булмаган партнерлык җитәкчесе, Татарстан Республикасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе;

Барлыгы 33 гаиләгә консультация бирелде. Консультация нәтиҗәләре буенча 7 гаилә алга таба бергә эш алып бару һәм оештыру өчен алынды.

### «112 чакыру хезмәте»






Икенче ел рәттән «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыртуны тәэмин итү системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең мәгълүмати хезмәттәшлеге турында имзаланган Килешү кысаларында «112 чакыру хезмәте» ведомствоара проекты тормышка ашырыла.


Әлеге проект конкрет гаиләгә кирәкле комплекслы социаль ярдәм күрсәтү өчен барлык профилактикалау субъектларын балалы гаиләләрнең барлык проблемалы мәсьәләләренә оператив рәвештә тоташтырырга мөмкинлек бирә. 2020 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 7300дән артык хәбәр килде. Хәбәрләрне карау нәтиҗәләре буенча балигъ булмаганнар яши орган гаиләләрдә имин булмаган хәлләр турында 381 сигнал картасы формалаштырылды.

Әлеге сигнал карталары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасының бердәм белешмәләр банкын булдыру турында” 2010 елның 22 апрелендәге 294 номерлы карарында каралган «Татарстан Ре-

спубликасында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмати системасы аша Татарстан Республикасының Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасының бердәм белешмәләр банкына җибәрелде. 79 гаилә социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр буларак ведомствоара исәпкә куелды (куелган сигнал карталарының гомуми саныннан 13,3%).

Әлеге эш форматы конкрет гаиләгә кирәкле комплекслы социаль ярдәм күрсәтү өчен барлык профилактикалау субъектларының балалар һәм балалы гаиләләрнең барлык проблемалы мәсьәләләренә оператив кушылуны тәэмин итә.

### «Җәмәгать ярдәмчеләре»




2020 елда ***“Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре”*** проектын гамәлгә ашыру дәвам итте.

2020 елда республиканың 42 районында (шәһәрендә) Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 42 җәмәгать ярдәмчесе (алга таба – җәмәгать ярдәмчеләре) эшләде. Җәмәгать ярдәмчеләре эшчәнлеген оештыру – методик яктан тәэмин итүне муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары белән берлектә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты гамәлгә ашырды.



2020 ел дәвамында җәмәгать ярдәмчеләре:

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил йөкләмәсе буенча бала хокукларын бозу фактлары буенча тикшерүләрдә катнаштылар;

258 гражданнарны кабул итү оештырылды һәм үткәрелде, аларда 479 мөрәҗәгать каралды;




174 ведомствоара тикшерүдә катнаштылар, шул исәптән 186 имин булмаган гаиләгә чыктылар;

гражданнарны хокукый агарту буенча, шул исәптән онлайн режимда, 150дән артык чараны актив тормышка ашырдылар;



массакүләм мәгълүмат чараларына, шул исәптән җирле ММЧларга, балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары турында мәгълүматлар тупланган мониторинг үткәрделәр һәм бу хакта Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә хәбәр иттеләр;



массакүләм мәгълүмат чаралары мониторингы нәтиҗәләре буенча, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты социаль челтәрләрдә атна саен гаилә һәм балалар мәсьәләләре буенча төбәк һәм федераль законнардагы үзгәрешләргә бәйле хокукый мәгълүмат урнаштырып барды;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә бала хокукларын, иреген һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга кагылышлы мәсьәләләр буенча фәнни-гамәли

конференцияләр, киңәшмәләр һәм семинарлар (96 чара) оештыруда һәм үткәрүдә катнаштылар.

Иҗҗимагый эшчәнлек кысаларында Н.В.Веретенникованың җәмәгать ярдәмчесе сыйфатында балигъ булмаганның анасына баланың атасын билгеләү һәм ата булуны билгеләү нәтиҗәләре буенча аннан алимент түләттерү мәсьәләләре буенча судта бушлай юридик ярдәм күрсәтелде, алимент алу билгеләнде, үтәтү кәгазе Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенә тапшырылды.

### «Остазлар: бергә түгел, әмма янәшәдә!»




«УМАЙ» Идел буе гаилә академиясе” АНО ярдәмендә оештырылган “Остазлар: бергә түгел, әмма янәшәдә!” проекты 2020 елда «Иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылган балаларга карата медиация хезмәтенең дәүләт-иҗтимагый моделен булдыру» юнәлеше буенча Президент грантлары фонды акчасына гамәлгә ашырылды. Чараны гамәлгә ашыру 2020 – 2021 елларга исәпләнгән. Проект чараларында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 25 җәмәгать ярдәмчесе катнаша.

Проектның максаты – балалар һәм яшүсмерләр белән эшләүдә катнашучы барлык органнарның һәм оешмаларның КДН һәм ЗП эшчәнлегенә медиатив якын килүне кертү юлы белән ведомствоара хезмәттәшлеген яхшырту.

Проект кысаларында түбәндәгеләр узды:

“ТРның КДН һәм ЗП эшчәнлегенә медиация хезмәтләрен булдыруның һәм медиатив якын килүне кертүнең актуаль мәсьәләләре” республика конференциясе;

“Медиатив-торгызу алымындагы конфликт зонасында эшчәнлек принциплары» темасы буенча гамәли секцияләр, практик юнәлешле семинарлар, алар Балаларга, шул исәптән иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылган әмма Россия Федерациясендә җинаять җаваплылыгы билгеләнә торган яшькә җитмәгән балаларга карата суд-хокук эшчәнлеген кабат торгызуны гамәлгә ашыру максатларында 2025 елга кадәр медиация хезмәтләре челтәрен үстерү концепциясен гамәлгә ашыру буенча Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча Хөкүмәт комиссиясе тарафыннан 2019 елның 25 сентябрендәге 23 номерлы карары белән расланган ведомствоара комплексы чаралар планын үтәүгә юнәлдерелгән.

### «Балачак иминлеге»




2020 елда балигъ булмаганнар белән гадәттән тыш хәлләрне профилактикалауга юнәлдерелгән ***«Балачак иминлеге»*** Бөтенроссия акциясен гамәлгә ашыру дәвам итте.

Акциянең беренче этабы Татарстанда 2020 елның 1 июненнән 31 августына кадәр узды, 2020 елның 1 ноябреннән 2021 елның 1 мартына кадәр «Балачак иминлеге – 2020» Бөтенроссия акциясенең (алга таба – Акция) икенче (кышкы этабы үткәрелә.

Акциянең максаты – балаларның һәм балалы гаиләләрнең күпләп ял итү, җыелу, күңел ачу урыннарында балигъ булмаганнар белән гадәттән тыш хәлләрне профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру.

Татарстан Республикасында акцияне түбәндәгеләр оештырды: Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, «Татарстан Республикасының Аталар советы» РОО, ОНФның Татарстан Республикасында төбәк башкарма комитеты, «ОНФ яшьләре» яшьләр оешмасы, республиканың җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасының муниципаль Аталар советлары.

Татарстан Республикасында акция чаралары Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре һәм «Балалар җәмәгать кабул итү бүлмәсе» проектында катнашучылар – Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар җәмәгать ярдәмчеләре катнашында узды.

Яңа коронавирус инфекциясе таралу куркынычына бәйле рәвештә барлыкка килгән санитар-эпидемиологик вәзгыятьне исәпкә алып, җәйге чорда республика балаларының мәшгульлеген оештыру бүгенге көннең актуаль мәсьәләсе булып кала.

Бу шартларда шәһәр читендәге, мәктәп яны, хезмәт лагерьларында балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыруның традицион рәвешләрен тормышка ашыру чикләнгән һәм проблемалы булып калуын исәпкә алып, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балаларның һәм яшүсмерләрнең яшәү урыны буенча ялын, күңел ачуын, иҗат, спорт эшчәнлеген тәэмин итәргә сәләтле түбәндәге учреждениеләр челтәренең эшчәнлеген җәйге чорга активлаштыру һәм мобилизацияләү эше оешетырылды: мәктәптән тыш эшләр үзәкләре, техник иҗат йортлары, сәнгать мәктәпләре, спорт мәктәпләре һәм секцияләре, яшүсмерләр клублары, яшьләр үзәкләре, мәдәният йортлары һәм авыл клублары, китапханәләр, спорт объектлары. Эпидемиологик вәзгыять үсешенә бәйле рәвештә, әлеге учреждениеләрнең эше онлайн режимда оештырылды һәм әкренләп гадәти форматтагы эшчәнлеккә күчте.

«Балачак иминлеге» акциясенең беренче (җәйге) этабын уздыру йомгаклары буенча, Акциядә катнашучылар тарафыннан 13 170 объект тикшерелде, шул исәптән балалар мәйданчыклары – 3 686, спорт мәйданчыклары – 2 104, белем бирү оешмалары һәм аларга чиктәш территорияләр – 2 178, көндез килеп тора торган балалар лагерьлары – 129, шәһәр читендәге савыктыру лагерьлары – 68, парклар, скверлар – 371, ял итү һәм коену урыннары – 101, коену тыелган урыннар – 399.

Акциядә катнашучылар көче белән 3 519 тәртип бозу очрагы бетерелде.

Россия Федерациясе субъектларында Акциянең кышкы этабына йомгакларны 2020 елның 10 мартына кадәр ясау планлаштырыла, балаларның иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән күрелә торган чараларны корректировкалау буенча тәкъдимнәр дә эшләнәчәк.

### «Балалар җәмәгатьчелек кабул итү бүлмәсе»




2020 ел «Балалар җәмәгатьчелек кабул итү бүлмәсе» республика белем бирү проектын гамәлгә ашыруның соңгы елы булды, аңа 2015 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан «Татарстан Республикасы Балалар оешмалары советы» (алга таба – БОС) Татарстан Республикасы Төбәк иҗтимагый оешмасы (ТИО) һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән берлектә старт бирелгән иде.

2020 елда республикада бу эшчәнлекне 72 ярдәмче һәм республика проектының 35 активисты алып барды, алар көче белән балаларны хокукый агарту буенча белем бирү проектының 200дән артык чарасы гамәлгә ашырылды.

2021 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Балалар хокук академиясе» һәм «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Балалар советы» дигән ике яңа проектны гамәлгә ашыруны планлаштыра.

## «Балалар хокук академиясе»

**Проектның идеясе:** яшь буынны хокукый тәрбияләүдә уртак эш алып бару буенча Татарстан Республикасы хакимият органнарының, мәгариф оешмаларының, җәмгыятьнең ресурсларын берләштерү.

**Проектның максаты:**

– балалар һәм яшьләр мохитендә традицион кыйммәтләрне хокукый агарту һәм пропагандалау, балаларның хокукка, законга карата ихтирамлы мөнәсәбәтен булдыру һәм үз дәүләтеңнең уңышлары өчен горурлану тудыру;

- хокукый белемне һәм хокукый культураны үстерү өлкәсендә балаларның һәм яшьләрнең уңай юнәлешле һәм иҗтимагый файдалы эшчәнлеген пропагандалау.

**Проектның бурычлары:**

– җәмәгатьчелек игътибарын балаларның һәм яшьләрнең, тулаем халыкның хокукый культурасын күтәрү мәсьәләләренә җәлеп итү;

- балалар һәм яшьләрнең актив гражданлык позициясен булдыру;

- хокукка һәм хокукый белемнәрне таратуга кызыксынуны арттыруга ярдәм итә торган хокукый тематика буенча мәктәп укучыларының интеллектуаль конкурсларын эшләү һәм башлап җибәрү;

- хокукый культураны булдыру буенча балалар һәм яшьләр белән эшләүнең эчтәлеген, рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү;

- балаларга хокукый белем бирүне оештыруның алдынгы тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм анализлау;

- Балалар хокук академиясе сайтын эшләү.

Проектның оештыручылары – Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты, Россия дәүләт гадел хөкем университеты – Казан шәһәрендәге филиалы.

Әлеге проект Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты тарафыннан хупланды.

## «Балалар советы»

**Проектны гамәлгә ашыруның максаты:** Вәкаләтле вәкилнең балигъ булмаганнарның хокукларын, ireген һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендәге балалар берләшмәләренең вәкилләре белән хезмәттәшлеген үстерү, әлеге эшчәнлекне камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү, балалар хокуклары мәсьәләләре буенча агарту эшен оештыру.

**Бурычлары:**

балалар-яшүсмерләр, ата-аналар һәм педагогик берләшмәләрдә Бала хокуклары һәм балалар хокуклары турында белемнәр конвенциясе принципларын алга этәрү;

балаларның хокукый белемен һәм культурасын күтәрү;

балаларны җәмәгать тормышында катнашуга җәлеп итү өчен социаль технологияләрне үстерү, балаларның хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы карарларны барлык дәрәҗәләрдә карау һәм экспертизалау;

массакүләм мәгълүмат чараларында балаларның җәмәгать тормышында катнашу темасын яктырту;

балаларда һәм яшүсмерләрдә актив гражданлык позициясен булдыруга ярдәм итү.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты белән әлеге проектка ярдәм итү буенча килешүгә ирешелде.

# 2020 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛАЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕ ҮТӘЛЕШЕНЕҢ ГОМУМИ МОНИТОРИНГЫ

2

БҮЛЕК


## 2.1. 2020 елда Татарстан Республикасында төп демографик тенденцияләр

Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының рәсми белешмәләренә караганда, 2021 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы халкының саны 3 902,9 мең кеше тәшкил итте.

2020 ел башына республикада ***балалар саны*** 843 709 кеше булган, ягъни гомуми халыкның 21,6%ы һәм, 2019 ел белән чагыштырганда, 7 508 балага арткан. 2010 елдан башлап алып барылган статистик белешмәләрне анализлау республикада балаларның гомуми санының ел саен артуын күрсәтә.

*15 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда тулаем һәм яшьләре буенча балалар динамикасы***





Кече яшьтәге (0 яшьтән 13 яшькә кадәрге) балалар саны – 688 115 кеше, яшүсмер (14 яшьтән 17 яшькә кадәрге) балалар саны – 155 594 кеше.

2020 елда республикада 361846 мәктәпкәчә яшьтәге бала исәпләнә иде. 2018 елга кадәр мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны артып барса, 2020 елда, 2019 ел белән чагыштырганда, мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны 12 366 кешегә кимегән. Мәктәп яшендәге балалар саны (7 – 17 яшь) 19 874 кешегә арткан.

*16 нчы диаграмма*


***2013 – 2020 елларда мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балалар саны динамикасы***




Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе белешмәләренә караганда, 2020 елда бала туу турында 41 888 акт теркәлгән. Татарстан Республикасында, гомумән Россия Федерациясендә дә, туучылар санының кимүе күзәтелә.

*17 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда Татарстан Республикасында балалар туу динамикасы (кеше)***





Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС Идарәсе белешмәләренә караганда, 2020 ел йомгаклары буенча, республикада 16 116 бала (38,5%) гаиләдә беренче бала булып туган, 15900 (38%) – икенче, 7 556 (18%) – өченче, 2 316 (5,5%) – дүртенче һәм аннан да күбрәк.

Балалар туу структурасында соңгы биш елда беренче балалар тууның кимүе игътибарга алына (2015 елда 24 832 бала беренче бала булып туган, 2016 елда – 22 511, 2017 елда – 19 543, 2018 елда – 18 357, 2019 елда – 16 833, 2020 елда – 16 116). 2018 елдан башлап икенче бала туу очракларының кимүе күзәтелә башлады. Шул ук вакытта 2020 елда өченче балалар саны, узган ел белән чагыштырганда, 1,7%ка арткан, ә дүртенче балалар саны 0,5%ка арткан.

*18 нче диаграмма*


***2020 елда беренче һәм аннан соңгы балаларның туу өлеше***




2020 елда 292 бала үлгән, 2019 ел белән чагыштырмача (370 бала), Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның үлем дәрәҗәсе киму күзәтелә.

*19 нчы диаграмма*

***2016 – 2020 елларда Татарстан Республикасында балалар үлеме динамикасы (кеше)***




***Гаилә кору һәм аерылышулар*** демографик процессларны тәшкил итәләр. Шуңа бәйле рәвештә әлеге өлкәдә статистик анализ ясау бик мөһим.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС Идарәсе белешмәләренә караганда, 2020 елда 19 348 никах теркәлгән, бу 2019 ел белән чагыштырганда 4 834 никахка (25 %) кимрәк.

Аерылышу очраклары буенча 11 350 акт теркәлгән. Бу күрсәткеч узган ел белән чагыштырганда 1 966 очракка кимрәк.

*20 нче диаграмма*

***2016–2020 елларда Татарстан Республикасында теркәлгән никахлар һәм аерылышулар динамикасы***




Аерылышулар саны кимүгә карамастан, 2020 елда язылышу һәм аерылышулар саны турындагы статистик белешмәләр шуны раслый: 1000 никахка 587 аерылышу теркәлгән (2014 елда – 464, 2015 елда – 440, 2016 елда – 522, 2017 елда – 503, 2018 елда – 541, 2019 елда – 551).

Аерылышу мәсьәләсе аеруча игътибар бирүне таләп итә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС Идарәсе белешмәләренә караганда, 2020 елда 10 213 бала ата-аналары аерылышу аркасында кризис вәзгыятен кичергәннәр.

**«Демография» илкүләм проектының** «Балалар туганда гаиләләргә финанс ярдәме» Федераль проекты кысаларында 2020 елда балалы гаиләләргә финанс ярдәме күрсәтү максатларында түбәндәгеләр гамәлгә ашырылды:

– беренче бала тууга (уллыкка алуга) бәйле рәвештә, айлык керемнәре җан башына 20 170 сумнан артмаган гаиләләр өчен өч яшькә җиткәнче ай саен 9 373 сум күләмендә (Татарстан Республикасында хезмәткә сәләтле халыкның яшәү минимумының икеләтелгән күләмендә, 2020 елда – 10 085 сум) айлык түләү, аны алучылар саны – 28 567 кеше, Россия Федерациясе бюджетыннан 3,2 млрд сум бирелде;

– авылда яшәүче хатын-кызларга республика бюджеты акчаларыннан бер мәртәбә түләү: 25 яшькә кадәр беренче бала тудыручыларга – 50 мең сум, 29 яшькә кадәр өченче бала тудыручыларга – 100 мең сум. Аны алучылар саны – 2 320 кеше, Татарстан Республикасы бюджетыннан 164,7 млн сум акча бирелде.

2020 елның 1 гыйнварыннан балалы гаиләләргә ярдәм итү максатларында республика бюджеты ачалары исәбенә аз керемле күпбалалы гаиләләргә 483,3 млн. сумлык өстәмә

ярдәм чаралары бирелде, бу чара аеруча ярдәмгә мохтаҗ балалы гаиләләргә пандемия шартларында нык ярдәм итте.

2020 елда 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү кертелде. Моны 53 266 кеше ала, барлыгы 3,1 млрд. сум акча (Россия Федерациясе бюджетыннан – 1,7 млрд. сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1,4 млрд. сум) бирелде.

«Хатын-кызларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү – өч яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен шартлар тудыру» төбәк проекты кысаларында 2020 елдан өч яшькә кадәр бала карау буенча ялда булган хатын-кызларны, шулай ук эшләми торган һәм эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән мәктәпкәчә яшьтәге балалары булган хатын-кызларны яңадан укыту һәм квалификацияләрен күтәрү буенча чаралар гамәлгә ашырыла. 2020 елның 17 декабренә 3 387 кеше (планнан 223%, план буенча – 1 518 кеше) укый башладылар, 3 066 кеше укуны тәмамлады.

Шулай итеп, 2020 елда балалар тууының абсолют саны гына түгел, ә туура һәм демографиягә бәйле тулаем вәзгыятьнең торышы бәйле булган социаль-демографик төркемнәргә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтләре тарафыннан шактый ярдәм күрсәтелде.

## 2.2. 2020 елда Татарстан Республикасында бала хокукларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән төп гамәлләр һәм чаралар









2020 елда Татарстан Республикасында балалы гаиләләрнең тормыш сыйфатын күтәрү буенча системалы эш дәвам итте, шул исәптән түбәндәге 11 илкүләм проектны гамәлгә ашыру аша да:

«Демография»;

«Сәламәтлк саклау»;

«Мәгариф»;

«Торак һәм шәһәр мохите»;

«Мәдәният»;

«Куркынычсыз һәм сыйфатлы автомобиль юллары»;

«Хезмәт житештерүчәнлеге эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү»;

«Кече һәм урта эшкуарлык шәхси эшкуарлык эшчәнлегенә ярдәм итү»;

«Халыкара кооперация һәм экспорт»;

«Цифрлы икътисад»;

«Экология».

2020-2022 елларда Татарстан Республикасында илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга 77,8 млрд. сум юнәлдереләчәк, шул исәптән 51,4 млрд. сум –федераль бюджеттан һәм 26,4 млрд.сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан.

Татарстан Республикасында 2020 елда 50 дәүләт программасы гамәлгә ашырылды. Аларның гомуми күләме 54 млрд. сумнан артык тәшкил итте.

**Сәламәтлек саклау өлкәсендә** социаль-мәдәни өлкә объектларын төзү һәм капиталь ремонтлау буенча ике программа гамәлгә ашырылды, аның кысаларында 51 объект төзү, 13 объект проектлау һәм 23 объектка капиталь ремонт ясау, шул исәптән 8 объектны җиһазландыру каралган.

43 ФАП һәм 7 табиб амбулаториясе төзелде, Биектау районында гомуми практика табибы офисы төзелеп килә. 14 медицина стационары ремонтланды, тагын берсе буенча эш бара.



«Сәламәтлек саклау системасын үстерү» илкүләм проектының «Балалар сәламәтлек саклау системасын үстерү» федераль проекты буенча «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе территориясендә балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәге төзелә.

Шулай ук программадан тыш мөһим объектлар төзелде:



– “Профессор А.Ф. Агафонов исемендәге Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең йогышлы авырулар хастаханәсе бинасы, Казан шәһәре, Җиңү проспекты, 83 йорт (икенче чират);

– “Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Әлмәт филиалының радиология корпусы;

– “Перинаталь үзәк белән Әлмәт балалар хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең хирургия корпусы;

– “Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Чаллы филиалы бинасы.



2020 елда Татарстан Республикасы Президенты республика район хастаханәләренең баш табибларына яңа ашыгыч ярдәм автомобильләре ачкычларын тапшырды. Медикларга бүләк ителгән 54 машина Татарстанның 42 муниципаль районына җибәрелде һәм татарстанлылар файдасына эшләячәк. Барлык автомобильләр дә үзебезнең илдә җитештерелгән заманча медицина җайланмалары белән җиһазландырылган һәм фельдшер бригадалары көче белән ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү, пациентларның халәтен мониторинглау һәм госпитальгә кадәрге этапта интенсив терапия уздыру өчен билгеләнгән.



Татарстанлыларның социаль иминлеген тәэмин итүдә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе – ***мәгариф өлкәсендә*** гамәлгә ашырыла торган программалар. Мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасында балалар бакчаларында өстәмә урыннар булдыру буенча чаралар гамәлгә ашырыла. 2020-2021 елларда «Демография» илкүләм проектының «Хатын-кызларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү – өч яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү шартларын булдыру» Федераль проекты кысаларында тагын 10 меңнән артык өстәмә мәктәпкәчә урыннар бул-



дыру планлаштырыла, шул исәптән ясли яшендәге балалар өчен 5 050 урын, 49 балалар бакчасы төзү һәм эшләп торучы балалар бакчаларында 37 өстәмә урын булдыру юлы белән дә. Чараларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча 2022 елга өч яшькә кадәрге балалар өчен 100% мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеген тәэмин итү планлаштырыла.

2020 елда «Демография» илкүләм проекты буенча 5 495 урынлы 29 балалар бакчасы төзелгән, шул исәптән:

– Әлки муниципаль районында (40 урынлы 1 балалар бакчасы);
– Арча муниципаль районында (40 урынлы 1 балалар бакчасы);
– Балтач муниципаль районында (120 урынлы 1 балалар бакчасы);
– Буа муниципаль районында (260 урынлы 1 балалар бакчасы);
– Биектау муниципаль районында (340 урынлы 1 балалар бакчасы);
– Зеленодольск муниципаль районында (2 балалар бакчасы, барлыгы 300 урын);
– Саба муниципаль районында (50 урынлы 1 балалар бакчасы);
– Тукай муниципаль районында (140 урынлы 1 балалар бакчасы);
– Балык Бистәсе муниципаль районында (50 урынлы 1 балалар бакчасы);
– Лаеш муниципаль районында (260 урынлы 1 балалар бакчасы);
– Питрәч муниципаль районында (220 урынлы 1 балалар бакчасы);
– Түбән Кама шәһәрендә (һәрберсе 260 урынлы 2 балалар бакчасы);
– Чаллы шәһәрендә (һәрберсе 220 урынлы 3 балалар бакчасы);
– Казан шәһәрендә (10 балалар бакчасы, барлыгы 2340 урын).

Буа муниципаль районының Вольнистан авылында башлангыч мәктәп, 15 урынга исәпләнгән балалар бакчасы, авыл мәдәният йорты, китапханә һәм фельдшер-акушерлык пункты урнашкан бина реконструкцияләнде.





Татарстанның 33 районында барлык яшь категориясендәге балалар балалар бакчаларында урыннар белән 100% тәэмин ителгән, тулаем республика буенча балаларның 94%ы балалар бакчаларында урыннар белән тәэмин ителгән.

2020 елда гомумән 10 799 урынга исәпләнгән 10 мәктәп төзелеп бетте. *Болар түбәндәгеләр:*

– Питрәч муниципаль районындагы «Усадьба Царево» торак комплексында 1 224 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү оешмасы;

– Казан шәһәренең Нәҗип Җиһанов урамы буенча 1 224 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү оешмасы;



– Казан шәһәренең Яңа Савин районында 1 224 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү оешмасы;

– Чистай шәһәрендә 800 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү оешмасы;

– Әлмәт шәһәрендә 858 урынга исәпләнгән инженер мәктәбе;

– Казан шәһәренең Киров районында 1 224 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү мәктәбе (“Салават Күпере” торак районы»);

– Алексеевск муниципаль районы Олы Тигәнәле авылында балалар бакчасы белән 80 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү оешмасы;

– Алабуга шәһәрендә 1 224 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү мәктәбе төзелеше бара.

*Түбәндәгеләр реконструкцияләнде:*

– Казан шәһәренең халыкара гомуми белем бирү үзәге (140 урын);

– Казан шәһәре Яңа Савин районының инглиз телен тирәнтен өйрәнүле 165 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе (768 урын).

Шулай ук дүрт республика программасы кысаларында 2020 елда 478 мәгариф объектында капиталь ремонт эшләре алып барылды.

2012-2019 елларда адаптация буенча чаралар 350 мәгариф оешмасында үткәрелде, 2020 елда 12 мәгариф объекты җайлаштырылды, шул исәптән 5 мәктәп, 5 балалар бакчасы һәм 2 өстәмә белем бирү объекты.

Федераль ярдәм кысаларында Татарстан Республикасы 70 яңа мәктәп автобусы алды.



“Азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм иминлеге турында” Федераль законга һәм “Россия Федерациясендә мәгариф турында” Федераль законның 37 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 2020 елның 1 мартындагы 47-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, республиканың барлык мәктәпләрендә 2020 елның 1 сентябрендә кече яшьтәге мәктәп укучылары өчен түләүсез кайнар ризык кертелде. 2020/21 уку елының беренче яртыеллыгында 1-4 сыйныф укучыларын түләүсез туклану белән тәэмин итүгә чыгымнар 859,9 млн.сум тәшкил иткән, шул исәптән федераль бюджеттан – 498 778,1 млн. сум (58 %), республика бюджетыннан – 361 184,1 млн. сум (42%).



2020 елда Татарстан Республикасында балаларга өстәмә белем бирү буенча 1438 мәгариф оешмасы, балалар спорт оешмалары эшли, аларда 320 меңнән артык бала (мәктәп укучыларының 71,2%) шөгыльләнә.





2020 елда Чистай шәһәрендә Балалар сәнгать мәктәбенең яңа бинасы төзелде.



Республиканың ***спорт объектлары челтәрен***, шул исәптән балалы гаиләләр өчен дә, инфраструктурасын үстерү дәвам итә.

Татарстан Республикасында балалар шөгыльләнә торган 11 205 спорт корылмасы эшли.

Яңа файдалануга кертелгән (төзелгән) спорт корылмалары саны 406 объект тәшкил итте.

2020 елда түбәндәге объектларны төзү тәмамланды:

– 93 универсаль спорт мәйданчыгы;

– 6 модульле чаңгы базасы, алар барысы да мебель, инвентарь һәм җайланмалар белән җиһазландырылган;

– 20 x 40 мәйданлы футбол кыры һәм административ бина белән, ябык түбәле, каркас-тент өслек белән футбол манежы.

31 спорт объектына капиталь ремонт ясалды (реконструкцияләнде).

«Демография» илкүләм проектының “Спорт – тормыш нормасы” федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2020 елда 4 объектны төзү тәгәлләнде һәм 5 объектта җайланмалар комплектлары урнаштырылды.



Шулай ук агымдагы елда программадан тыш 21 спорт объектын төзү алып барылды.

Татарстан Республикасында балаларны ***ял иттерү һәм савыктыру*** өчен кирәкле һәм тиешле шартлар тудыруга җитди игътибар бирелә. 2019 елдан республикада «Җәй – балаларга» лагерьларын капиталь ремонтлау, реконструкцияләү һәм төзү буенча комплекслы программа старт алды, аның нигезендә лагерьларны капиталь ремонтлауга 7 млрд. сум акча бүлеп бирелде. Әлеге программага 94 дәүләт һәм муниципаль лагерь керде.

2019 – 2020 елларда 23 балалар савыктыру лагере капиталь ремонтланды, реконструкцияләнде һәм төзелде. Балалар лагерьларын төзү һәм капиталь ремонтлау буенча өч программага 35 объект кертелде. 2020 елда 13 балалар савыктыру лагере төзелде, реконструкцияләнде һәм ремонтланды.



Шулай ук 2020 елда 9 муниципаль берәмлектә 12 балалар савыктыру лагерена керү юллары ремонтланды һәм төзелде.

Республикада балалар һәм яшьләр өчен ***ял учреждениеләре челтәрен*** үстерүгә аерым игътибар бирелә.

2015 елда Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов яшүсмерләр клубларын капиталь ремонтлау программасын хуплады, аны гамәлгә ашыру барышында 20 яшьләр үзәге (2020 елда – 5 яшьләр үзәге), 162 яшүсмерләр клубы, шуларның 15е – 2020 елда, капиталь ремонтланды.

*8 нче таблица*

***2018-2020 елларда Татарстан Республикасында яшүсмерләр клублары һәм аларда шөгыльләнүче балалар саны:***

| | ***2018*** | ***2019*** | ***2020*** |
|---|---|---|---|
| ***Яшүсмерләр клублары саны*** | 217 | 223 | 224 |
| ***Аларда шөгыльләнүче балалар саны*** | 372 423 | 280 256 | 293 110 |
| ***Яшүсмерләр клублары төзелгән муниципаль берәмлекләр саны*** | 28 | 29 | 28 |

Татарстан Республикасы мәдәният системасында:

– 1 842 сарай (мәдәният йорты) эшли, алар базасында балалар өчен ял итү чаралары оештырыла, шул исәптән 1 753 учреждение авыл җирлегендә урнашкан;

– 89 махсуслаштырылган балалар китапханәсе эшли, шул исәптән 32 авыл китапханәсе.




2012 елдан башлап республикада күп функцияле мәдәни үзәкләр (авыл клублары) төзү программасы гамәлгә ашырыла. Бу чорда 318 авыл мәдәният йорты (клуб) төзелде. 2020 елда республика программалары кысаларында 1 300 урынга исәпләнгән 12 авыл клубы төзелде, шулай ук 45 объектка капиталь ремонт ясалды. Капиталь ремонт республиканың 17 балалар сәнгать мәктәбендә дә үткәрелде.

«Мәдәният» илкүләм проектының «Мәдәни мохит» федераль проекты буенча 8 авыл мәдәният йорты төзелеше тәмамланып килә (Буа, Кукмара, Питрәч, Саба, Тукай, Чирмешән һәм Апас муниципаль районнарында), шулай ук «Чаллы дәүләт курчак театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесендә (ДАМУ) капиталь ремонт тәмамланып килә.



Аерым категория гражданнарны ***торак белән тәэмин итү*** программасы кысаларында 716 гаилә үзләренең торак шартларын яхшыртты.

2020 елда республикада 2 млн. 680 мең 100 кв. метр торак төзелгән, бу узган ел белән чагыштырганда 4 600 кв.метр күбрәк.



2020 елда торак-коммуналь хуҗалык тармагын камилләштерү буенча системалы эш дәвам ителде. Бу юнәлештә 8 программа тормышка ашырылды.

Алар арасында иң зурысы – күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау программасы: аның финанс күләме – 6 млрд. 473 млн.сум. Бу суммага муниципалитетлар акчалары да кертелгән.




2020 ел программасына 1 063 йорт кертелгән. Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан барлык йортлар да кабул ителде.

2020 елда 600 ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала һәм алар арасыннан булган затлар торак алды, бу 2019 ел белән чагыштырганда ике тапкыр диярлек күбрәк (2019 елда – 309 кеше).

Күп балалы гаиләләргә торак төзелеше өчен бушлай җир кишәрлекләре бирүне күздә тоткан федераль һәм төбәк җир законнары нормаларын гамәлгә ашыру дәвам итте. 2020 ел ахырына югарыда күрсәтелгән дәүләт ярдәме чарасына хокуклы һәм аны тормышка ашырырга теләк белдергән 38 523 күпбалалы гаилә үз хокукларын гамәлгә ашырдылар һәм гомуми өлештәге җир кишәрлекләрен рәсмиләштерделәр.

2020 елда күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшырту буенча дәүләт ярдәме чараларын төбәк финанславы арттырылды, бу биш һәм аннан да күбрәк баласы булган 46 күпбалалы гаиләгә торак субсидияләрен түләргә мөмкинлек бирде, әлеге максатны тормышка ашыру өчен 211,9 млн сум (2019 елда – 156 млн сум) акча бүлеп бирелде.

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 2020 елда социаль ипотека программасында катнашучы гаиләдә һәр бала туганда, уллыкка (кызлыкка) алганда түләүгә юнәлдерелгән финанс чараларының гомуми күләме 617 769,6 мең сум тәшкил итте.

«Демография» илкүләм проектының «Балалар туганда гаиләләргә финанс ярдәме» федераль проекты кысаларында 2020 елда балалы гаиләләргә финанс ярдәме күрсәтү максатларында түбәндәгеләр гамәлгә ашырылды:

– беренче бала тууга (уллыкка алуга) бәйле рәвештә өч яше тулганчы айлык түләү. Алучылар – 28 567 кеше, Россия Федерациясе бюджетыннан 3,2 млрд. сум җибәрелгән;

– авылда яшәүче хатын-кызларга республика бюджеты акчалары исәбеннән бер тапкыр бирелә торган түләү – 25 яшькә кадәр тудырган беренче бала өчен – 50 мең сум, 29 яшькә кадәр тудырга өченче бала өчен – 100 мең сум. Алучылар – 2 320 кеше, Татарстан Республикасы бюджетыннан 164,7 млн сум акча җибәрелгән.



2020 ел Россия Федерациясе дәрәҗәсендә дә, Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә дә балалы гаиләләргә яңа социаль ярдәм чаралары саны буенча уникаль булды.

Россия Федерациясе Хөкүмәте дәрәҗәсендә балалы гаиләләргә түбәндәге социаль ярдәм чаралары күрсәтелде:



• 2020 елның 1 июненнән Россия Федерациясе субъектында бер яшәү минимумыннан кимрәк керемле (алга таба – ПМ), 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә ай саен бирелә торган түләүләр; республикада 53 266 кеше алган, шул исәптән Россия Федерациясе бюджетыннан – 3,1 млрд. сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1,7 млрд. сум һәм 1,4 млрд. сум;

• вакытлыча эшкә яраксызлык очрагына социаль иминләштерү мәҗбүри булмаган гражданнарга беренче баланы 1,5га кадәр карау буенча минималь пособие күләмен 3 375 сумнан 6 752 сумга кадәр арттыру; алучылар – 5 284 кеше, Россия Федерациясе бюджетыннан 138,7 млн сум җибәрелде.

2020 елның 1 гыйнварыннан балалы гаиләләргә ярдәм итү максатында республика бюджеты акчаларыннан аз керемле күпбалалы гаиләләргә ярдәм итү өчен 483,3 млн. сумлык өстәмә ярдәм чаралары булдырылды, пандемия шартларында балалы аеруча ярдәмгә мохтаҗ гаиләләргә бу сизелерлек ярдәм булды, болар түбәндәгеләр:



• җан башына керемнәре яшәү минимумыннан ким булган гаиләләрдәге өч яшькә кадәрге балаларга дару чаралары сатып алу өчен ярты елга бер мәртәбә 5 000 сум күләмендә түләү; 22 212 кешегә түләнде;

• җан башына керемнәре яшәү минимумыннан ким булган 5 һәм аннан күбрәк балалы гаиләләргә айлык пособие. Пособие гаиләнең һәр әгъзасына гаиләнең җан башына уртача кереме белән ПМ арасындагы аерма күләмендә билгеләнде; алучылар саны – 12 605;



• җан башына уртача керемнәре кимендә 3 һәм аннан күбрәк балалы гаиләләргә балалар бакчасы өчен түләүне 100% компенсацияләү; алучылар саны – 5 194 кеше;

• җан башына уртача керем ПМ күләменнән түбән булган гаиләләргә яңа туган балалары өчен бүләк комплектлары бирү (1 комплект бәясе – 8847 сум); алучылар саны – 4 415 кеше.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының оператив белешмәләреннән күренгәнчә, балаларга һәм балалы гаиләләргә Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарында каралган социаль ярдәм күрсәтүгә республика бюджетының гомуми чыгымнары 2020 елда 7 015,6 млн сум тәшкил итте (2019 елда – 6 467,8 млн сум).

2020 елда социаль хезмәт күрсәтү буенча 37 бина, шул исәптән балалар һәм яшүсмерләр өчен 6 тернәкләндерү үзәге, балалар һәм яшүсмерләр өчен 8 социаль приютта капиталь ремонт ясалды.



2020 елда Татарстанда ***уңайлы шәһәр мохитен булдыру*** буенча масштаблы чараларны гамәлгә ашыру дәвам итте. 61 иҗтимагый объект төзекләндерелде. Программа тәгәлләнде. Шулай ук 2019 һәм 2020 елларда кече шәһәрләрдә җиңүчеләр конкурсы кысаларында Мамадыш, Баулы, Зәй һәм Лаеш шәһәрләрендә дүрт объект төзекләндерелде.

Шулай ук агымдагы елда йорт яны территорияләрен төзекләндерү буенча «Безнең ишегалды» программасына старт бирелде. 2020 елга аны финанслау лимиты 8 млрд. сум булды. 2020 елда ишегалды территорияләре исемлегенә 1 091 ишегалды кертелгән иде.

## 2.3. 2020 елда федераль һәм республика законнарында бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре өлкәсендәге яңалыкларга күзәтү

Илдә һәм тулаем дөньяда коронавирус инфекциясенә бәйле вәзгыятьне исәпкә алып, балалы гаиләләргә матди ярдәм күрсәтүгә, шул исәптән балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән норматив актлар закон дәрәҗәсендә кабул ителде.

***Федераль дәрәҗәдә*** түбәндәге мәсьәләләр регламентлаштырылды.

*«Россия Федерациясе Гаилә кодексының 86 статьясына үзгәреш кертү турында» 2020 елның 6 февралендәге 10-ФЗ номерлы Федераль закон белән* әлеге шартлар аркасында килеп чыккан өстәмә чыгымнарны күтәрүдә катнашуга ата– аналарны суб юелән җәлеп итү өчен нигезләр исемлеге тулыландырылды – даими яшәү өчен яраклы торак урыны булмау һәм башка шартлар.

*«Ана (гаилә) капиталы акчалары белән эш итүгә бәйле мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон белән* ана капиталын бакча кишәрлегендә торак йорт төзелешенә җибәрү һәм беренче бала туганда (уллыкка алганда) гаиләләргә ярдәм итүнең яңа чаралары билгеләнде.

Элегрәк торак йорт төзү хосусый торак төзелеше (ИЖС) өчен бирелгән җир кишәрлегендә генә мөмкин иде. Кертелгән үзгәрешләр нигезендә мондый төзелешне бакча җир кишәрлегендә дә алып барырга мөмкин. Шуңа бәйле рәвештә, законда ана капиталының бер өлешен төзелешкә (реконструкцияләүгә) яки бакча җир кишәрлегендә төзелгән ИЖС объектына чыгымнарны компенсацияләүгә юнәлдерү мөмкинлеге каралган. Моннан тыш, закон белән 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап, беренче баласын тудырган (уллыкка алган) хатын-кызларга, шулай ук элек өстәмә дәүләт ярдәме чараларыннан файдаланмаган беренче баланы уллыкка алган ир-атларга дәүләт ярдәменең өстәмә чараларына хокук билгеләнгән, әгәр уллыкка алу турындагы суд карары 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә кергән булса. Закон белән шулай ук беренче, икенче, өченче яки аннан соңгы балаларның тууына (уллыкка алуга) бәйле рәвештә, ана капиталының дифференциацияләнгән күләмен кертү карала. Балалы гаиләләргә ана капиталын алу һәм куллану өчен яңа мөмкинлекләр бирелә. 2020 елның апрель уртасыннан Россия Пенсия фонды (ПФР) сертификатларны актив бирә башлады. Ягъни бала тугач, ана капиталы автомат рәвештә рәсмиләштерелә һәм гаилә, сертификат алу өчен мөрәҗәгать итмичә дә, акчаларны тота ала. 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап, беренче балалары туган гаиләләр 466 617 сум күләмендә ана капиталы алу хокукын алдылар. 2020 елдан икенче яки аннан соңгы балалары туган гаиләләр өчен ана капиталы 616 617 сум тәшкил итә. 2021 елдан башлап, сертификат бирү срогы кыскара (биш эш көненнән дә артык түгел), шулай ук акчалар белән эш итү турындагы гаризаны карап тикшерү срогы да кыскара (ун эш көненнән дә артык түгел). 2020 елда боалрның срогы – беренчесенеке унбиш эш көне иде һәм икенчесенеке – бер ай. Шулай ук ана капиталын кредитларны түләүгә оператив җибәрү мөмкинлеге барлыкка килде – тиешле гаризаны хәзер, Россия Пенсия фондына мөрәҗәгать итмәчә, турыдан-туры банкка тапшырырга мөмкин.

*«Вакытлыча эшкә сәләтсезлек буенча пособиеләрне исәпләү һәм беренче яки икенче бала тууга (уллыкка) бәйле айлык түләүләрне гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында» 2020 елның 1 апрелендәге 104-ФЗ номерлы Федераль закон* нигезендә 2020 елның 1 октябренә кадәр беренче яки икенче бала тууга (уллыкка алуга) бәйле айлык түләүләр алучыларның аларны билгеләү турында, күрсәтелгән түләүләрне яңа вакытка озайту турында гариза бирергә тиеш булулары каралган нигезләмәләрнең гамәлдә булуы тукта-

тылды. Шулай ук халыкны социаль яклау органнарына һәм ПФРның территориаль органнарына яшәү (тору) урынын, фактта яшәү урынын алыштыру, шулай ук түләүләрне туктатуга китерә торган шартлар турында хәбәр итү зарурлыгына да кагыла. 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 октябренә кадәр: беренче яки икенче бала тууга (уллыкка алуга) бәйле айлык түләү билгеләү тәртибе үзгәрде – мондый түләү аны билгеләү турында гражданнардан керә торган гаризаларсыз гына билгеләнә.

*“Россия Федерациясендә мәҗбүри пенсия иминияте турында” 2001 елның 15 декабрендәге 167-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясына үзгәреш кертү хакында” 2020 елның 1 апрелендәге 86-ФЗ номерлы федераль закон белән* түләү шартнамәсе буенча опекуннар яисә попечительләр булган пенсионерларга 2020 елның 1 июленнән елдан эшләмәүче пенсионерларның статусы билгеләнде. Шул көннән мәҗбүри пенсия иминиятенә кагылышлы затлар исемлегеннән Россия Федерациясе законнары нигезендә иминият пенсияләрен алучы һәм опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыру шартнамәсе буенча, шул исәптән тәрбиягә алучы гаилә турындагы шартнамә буенча, шул исәптән тәрбиягә бала алган гаилә турында килешү буенча үз вазыйфаларын түләүле башкара торган опекуннар яисә попечительләр булган затлар төшереп калдырылды. Яңалык аларның иминият пенсияләрен ел саен индексацияләүне һәм эшләмәүче пенсионерлар өчен билгеләнгән тәртиптә аңа беркетелгән түләүне гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә.

*“Азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм иминлеге турында” Федераль законга һәм “Россия Федерациясендә мәгариф турында” Федераль законның 37 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 2020 елның 1 мартындагы 47-ФЗ номерлы Федераль закон белән* гомуми белем бирү оешмаларында балаларны тукландыруны тәэмин итү тәртибе җайга салынды. Мәсәлән, 2020 елның 1 сентябреннән дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч белем бирү программалары буенча белем алучы укучылар шундый оешмаларны гамәлгә куючылар тарафыннан Федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар ассигнованиеләре акчалары һәм Россия Федерациясе законнарында каралган башка финанслау чыганаклары исәбенә көнгә кимендә бер мәртәбә, кайнар эчемлекне исәпкә кертмичә, кайнар ризык белән тәэмин ителәләр.

*“Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында” Федераль законның 1 статьясына үзгәреш кертү хакында” 2020 елның 8 июнендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон белән* “ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар” төшенчәсе “ятим балалар; ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар” сүзләренә алыштыру юлы белән киңәйтелде.

*«Россия Федерациясендә мәгариф турында «Федераль законның 71.1 һәм 108 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 8 июнендәге 164-ФЗ номерлы Федераль закон* аерым гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда һәм (яки) барлыкка килү куркынычы булганда, Россия Федерациясенең бөтен территориясендә йә аның берәр өлешендә югары әзерлеклтә булу һәм гадәттән тыш хәл режимы кертелгәндә, белем бирү программаларын гамәлгә ашыру тәртибен, шулай ук төп һөнәри белем бирү программаларын үзләштерүгә нәтиҗәләрне күрсәтә торган дәүләт йомгаклау аттестациясен электрон укыту, дистанцион белем бирү технологияләрен куллану юлы белән үткәрү тәртибен билгеләнде. Белем алу һәм (яки) квалификация турында документларның, уку турындагы документларның электрон рәвештә бирелгән күчермәләре (кәгазьдә бирелгән документның, реквизитлары электрон машинада укылуын тәэмин итеп, сканерлау яки фотога төшерү юлы белән бирелгән электрон рәвеше) белем алу һәм (яки) квалификация турында, уку турында кәгазьдә бирелгән документлар кебек үк укырга керү һәм (яисә) эшкә урнашу мөмкинлеген бирә.

*«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 декабрендәге 429-ФЗ номерлы федераль закон белән* «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертелде, дәүләтара органнарның Россия Федерациясе халыкара шартнамәләренең Россия Федерациясе Конституциясенә туры килми торган нигезләмәләре нигезендә кабул ителгән карарлары Россия Федерациясендә үтәлми, дип билгеләнде. Мондый каршылык федераль конституциячел законда билгеләнгән тәртиптә билгеләнергә мөмкин.

*«Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 8 декабрендәге 409-ФЗ номерлы Федераль закон белән* ана (гаилә) капиталы акчаларын (бер өлешен) пенсия тупланмасын булдыруга файдаланудан баш тарткан хатын-кызлар Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органы тарафыннан әлеге затларга Россия Федерациясе Пенсия фонды счетына кире кайтарылган акчалар турында хәбәр җибәрелгән көннән алып алты ай эчендә ана (гаилә) капиталы акчаларын (бер өлешен) кабат файдалану турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Ана (гаилә) капиталы акчалары (бер өлеше) белән эш итү турында гариза бирү вакытын озайту турында гариза бер мәртәбә һәм күрсәтелгән срок узганчы бирелергә мөмкин.

*«Балалы гаиләләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 7 апрелендәге 249 номерлы Указы белән* 2020 елның апреленнән июнь аена кадәр *2006 елның 29 декабрендәге 256-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә* ана капиталы хокукына ия (ия булган) балалы гаиләләргә Россия Федерациясе гражданлыгы булган 3 яшькә кадәрге һәр балага 5 000 сум күләмендә айлык түләүләр бирелде.

*«Балалы гаиләләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 7 апрелендәге 249 номерлы Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 11 маендагы 317 номерлы Указы нигезендә* 2020 елның 1 июненнән Россия Федерациясе территориясендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданлыгы булган 3 яшьтән алып 16 яшькә кадәрге (балага 2020 елның 1 июленә кадәр 16 яшь булса) һәр балага 10 000 сум күләмендә бер мәртәбә бирелә торган түләүләр бирелде.

*«Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 20 мартындагы 199 номерлы Указы нигезендә* 2020 елның 1 гыйнварыннан 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләнгән. Түләү Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган тәртиптә һәм шартларда, әгәр гаиләдә җан башына уртача керем күләме *«Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә* айлык түләү билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән елның икенче кварталы өчен Россия Федерациясе субъектында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган булса, бирелә. Түләү күләме Россия Федерациясе субъектында билгеләнгән балалар өчен яшәү минимумы күләменең 50%ын тәшкил итә.

*"Балалы гаиләләргә бер мәртәбә бирелә торган түләү турында" Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 17 декабрендәге 797 номерлы Указы белән* Россия Федерациясе территориясендә яшәүче һәм Россия Федерациясе гражданлыгы булган сигез яшькә кадәрге балаларның ата-аналары, уллыкка алучылары, опекуннары, попечительләре булган Россия Федерациясе гражданнарына һәр бала өчен 5 000 сум күләмендә бер мәртәбәле түләүләр бирелде. Бер мәртәбә бирелә торган түләү гражданнарның гаилә керемнәре составында башка социаль ярдәм чараларын күрсәткәндә исәпкә алынмый.

Балаларның хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы законнарның норматив актлары арасында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең түбәндәге актлары яңалык булды.

*“Балалы гаиләләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары турында” Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 7 апрелендәге 249 номерлы Указында һәм “Балалы гаиләләргә бер мәртәбә бирелә торган түләү турында” Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 23 июнендәге 412 номерлы Указында каралган түләүләрне гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау хакында” 2020 елның 9 апрелендәге 474 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә* ана (гаилә) капиталы хокукына ия гаиләләргә айлык түләүне гамәлгә ашыру кагыйдәләре билгеләнде.

*«3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру тәртибенә төп таләпләрне, күрсәтелгән айлык түләүне билгеләү өчен кирәкле документларның (белешмәләрнең) якынча исемлеген һәм аны билгеләү турында гаризаның үрнәк формасын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 31 мартындагы 384 номерлы карары белән* 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру тәртибенә төп таләпләр; мондый түләүне билгеләү өчен кирәкле документларның (белешмәләрнең) якынча исемлеге; айлык акчалата түләү билгеләү турында гаризаның үрнәк формасы расланды. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнарына түбәндәгеләрне башкарырга тәкъдим ителде: 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләүне билгеләү тәртибен һәм шартларын расларга; кирәк булганда, күрсәтелгән түләү билгеләгәндә, аларның мохтаҗлыгын ачыклау өчен гаиләләрнең мөлкәти тәэмин ителешенә таләпләр билгеләргә.

*“Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 27 мартындагы 485 номерлы карарына үзгәреш кертү һәм Үзенә туры килә торган эш эзләү һәм эшсезләр буларак гражданнарны теркәү буенча вакытлыча кагыйдәләренең аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, шулай ук билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга, 2020 елның 1 мартыннан эштән җибәрелгән һәм эшсез дип танылган гражданнарга (хезмәт дисциплинасын бозган яки башка гаепле гамәлләр өчен эштән җибәрелгән гражданнардан тыш) социаль түләүләрне гамәлгә ашыруны туктатып тору турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 12 апрелендәге 485 номерлы карары белән* апрель – июнь айларында 12 130 сум күләмендә эшсезлек буенча пособие билгеләнде. 2020 елның 1 мартыннан эштән җибәрелгән һәм эшсез дип танылган һәм 18 яшькә кадәрге балалары булган гражданнарга эшсезлек буенча пособие күләме 2020 елның апрель – июнь айларында һәр ата-аналарның берсенә, тәрбиягә бала алган ата-аналарның берсенә, уллыкка алучыларга, шулай ук опекунга (попечительгә) һәр бала өчен 3000 сум исәбеннән арттырылды. Шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 8 апрелендәге 460 номерлы карары белән расланган Вакытлы кагыйдәләрнең уртача хезмәт хакына процент нисбәтендә эшсезлек буенча пособие күләмен билгеләү тәртибен урнаштыра торган 13-16 пунктларының гамәлдә булуы туктатылды.

*«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 мартындагы 383 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән* ана капиталы акчаларын электрон рәвештә һәм кыска срокларда торак шартларын яхшыртуга җибәрү мөмкинлеге билгеләнгән. Сертификат алган зат гади электрон имза белән имзаланган электрон формада гариза бирү юлы белән, мобиль телефонның расланган номерына СМС-хәбәрләр җибәрү рәвешендә ике факторлы аутентификациясен кулланып, Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең бердәм порталы аша РПФның территориаль органына мөрәҗәгать итә ала. Ана капиталы акчаларыннан файдалану турында гариза биргәндә, гаризаны карау өчен кирәкле документларның күчермәләре урынына алардан белешмәләрне бирү

мөмкинлеге каралган. Ана капиталы акчаларын файдалану турындагы гаризаларны карау срогы бер айдан 10 көнгә кадәр кыскартылды; гаризаны канәгатьләндерү турында карар чыгарылган очракта, акчаларны күчерү срогы 10 көннән 5 көнгә кадәр кыскартылды. Сертификат алган зат (әлеге затның ире) сатып алынган торакны сертификат алган затның, аның иренең, балаларының гомуми милкенә, билгеле бер вакыйга булган вакыттан алып (объект файдалануга тапшырылганнан соң, кредит буенча бурычлар тулысынча түләнгәннән соң, торак белән эш итүгә чикләүләр алынганнан соң һ.б.лар) 6 ай эчендә, килешү буенча өлешләр күләмен билгеләп, рәсмиләштерергә тиеш, дигән таләп билгеләнгән.

*“2021 елга инвалид балалар өчен дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары исемлеген раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 7 декабрендәге 3242-р номерлы боерыгы белән* инвалид балалар өчен дәвалау туклануы продуктлары исемлеге 11 төр белән тулыландырылды.

*«Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында үрнәк нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 10 февралендәге 120 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән* балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия вәкаләтләре даирәсе киңәйтелде.

*«Затны инвалид дип тану кагыйдәләренә кушымтаның 17 һәм 17.1 пунктларына үзгәреш кертү турында» 2020 елның 22 октябрендәге 1719 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән* уртача авырлыкта уза торган фенилкетонуриянең классик формасы баланы 18 яшькә кадәр инвалид дип тану өчен нигезләр исемлегенә кертелде.

*«Чит илләр органнарының һәм оешмаларының Россия Федерациясе территориясендә балаларны уллыкка (кызлыкка) алу эшчәнлеге һәм аны гамәлгә ашыруны контрольдә тоту турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 11 сентябрендәге 1396 номерлы карары белән* балаларны уллыкка (кызлыкка) алу (алга таба – уллыкка алу) эшчәнлеген Россия Федерациясе территориясендә үз вәкиллекләре (алга таба – вәкиллекләр, чит ил оешмалары) аша гамәлгә ашыручы чит илләр дәүләт органнарының һәм оешмаларының (алга таба – чит ил дәүләт оешмасы) һәм чит илләрнең коммерциягә карамаган, хөкүмәтнеке булмаган оешмаларының (алга таба – чит илнең коммерциячел булмаган оешмасы) Россия Федерациясе территориясендәге эшчәнлеге җайга салынган. Ул 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм 2027 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә була.

*«Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы белән* Балаларны мәктәпкә кабул итү кагыйдәләре яңартылды. Балаларны абыйлары яки апалары укый торган учреждениеләргә өстенлекле кабул итү хокукы турында нормалар беркетелде. Документлар җибәрү ысуллары төгәлләштерелде.

Мәктәптә уку балага яшь 6,6 яшь (алты яшь ярым) булгач, сәламәтлеге буенча каршы күрсәткечләр булмаса, әмма 8 яшьтән дә соңга калмыйча, башлана. Аерым очракларда бала мәктәпкә соңрак яисә иртәрәк яшьтә алынырга мөмкин.

*“Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү, укыту, ял иттерү һәм савыктыру оешмаларына карата санитар-эпидемиологик таләпләр” СП 2.4.3648-20 санитар кагыйдәләрен раслау турында” Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары белән* балаларны һәм яшьләрне тәрбияләүне, укытуны, ял иттерүне һәм савыктыруны оештыру өчен яңа санитар кагыйдәләр расланды.

Кагыйдәләр 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм 2027 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булачак. Алар балаларның сәламәтлеген саклауга, аерым алганда, йогышлы һәм йогышлы булмаган массакүләм авыруларны булдырмауга юнәлдерелгән.

**Карар нигезендә:**

– уенчыклар көн саен көн азагында юыла, ә сабыйлар һәм кече яшьтәге балалар төркемнәрендә – көнгә 2 тапкыр;

– балалар яши торган йортлар мәктәпләрдән һәм балалар бакчаларыннан 500 метрдан артык булмаган ераклыкта булырга тиеш, ә тыгыз шәһәр төзелеше шартларында – 800 метрдан ераграк булмаган арада, ә авыл җирлегендә – 1 километрдан ераграк булмаган арада булырга тиеш. **Әгәр ераклык бу күрсәткечләрдән артып китсә, транспорт оештырылырга тиеш;**

– балалар мәктәпләрдә 4 сәгатьтән артыграк булганда, кайнар ризык белән тәэмин ителергә тиеш;

– белем бирү оешмаларында инфракызыл нурланыш белән җылыткычларны куллану тыела;

– массакүләм авыручыларны барлыкка китерә торган йогышлы авырулар килеп чыккан очракта, белем бирү оешмасы ике сәгать эчендә бу хакта территориаль башкарма хакимият органнарына хәбәр итәргә һәм профилактик чараларга керешергә тиеш;

– бу оешмаларның хезмәткәрләре даими рәвештә медицина тикшерүләрен үтәргә, медицина кенәгәсен булдырырга һәм прививкаларның илкүләм календаре нигезендә вакцинация узарга тиеш.

Мәктәпләрдә расписание укучыларның көндезге һәм атналык акыл эшчәнлеге динамикасын һәм фәннәрнең катлаулылыгын исәпкә алып төзелергә тиеш. Дәресләр 45 минуттан артык булмаска тиеш, ә үзгәрешләр 10 минуттан да ким булмаска тиеш. Балаларның аруын булдырмас өчен чәршәмбе көнне, йә пәнҗешәмбе көнне җиңелрәк уку көне булырга тиеш. Классларда имтиханны көтү вакыты 30 минуттан артмаска тиеш, ә әгәр ул 4 сәгатьтән артып китсә, укучыларны тукландырырга тиешләр.

Мәктәпләрдә дәресләр иртәнге сигездән иртәрәк башлана алмый. Нулевой дәресләр үткәрү һәм өч сменада укыту катгый тыела. Икенче смена, үз чиратында, 19 сәгатьтән дә соңга калып тәгәлләнергә тиеш түгел. Каникуллар җиде календарь көннән дә ким булмаска тиеш.

Класслардагы җиһазларга кагылышлы пунктларда парталарны ничек урнаштыру кирәклеге, башка җиһазларның һәм техниканың үзенчәлекләре язылган.

Документның мөһим өлешен электрон укыту чараларын куллануга бәйле нормалар алып тора. Мәсәлән, дәрестә интерактив тактаны куллану дәвамлылыгы: 10 яшькә кадәрге балалар өчен 20 минуттан артмаска тиеш, 10 яшьтән өлкәнрәкләр өчен 30 минуттан артыграк булмаска тиеш.

Мобиль элемтә чараларының уку максатларында кулланылмавы аерым билгеләп үтелә.

2020 елда ***Татарстан Республикасы законнары*** балалар хокукларына һәм аларның мәнфәгатьләренә кагылышлы түбәндәге иң мөһим норматив хокукый актлар белән тулыландырылды.

*“Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында” Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 2020 елның 25 июнендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән* опека һәм попечительлек органнарына социаль тәэминатның Бердәм дәүләт социаль тәэминат системасында опекуннарның һәм попечительләрнең исәбен алып бару вәкаләтләре бирелде.

*“Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 һәм 76 статьяларына һәм “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2020 елның 28*

*мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән* бер гаиләдә яшәүче һәм яшәү урыннары утрак булган балалар мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча укырга үзләренең абыйлары һәм (яки) апалары укый торган дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына өстенлекле кабул итү хокукына ия булалар, дип билгеләнгән.

Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт яисә муниципаль белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча укырга кабул итү мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы яисә мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы тарафыннан Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирүдә кулланыла торган мәгълүмат системасы аша гамәлгә ашырыла.

*“Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм “Балигъ булмаганнарга тәмәке булмаган никотинлы продукция, никотин үткәрә торган электрон системалар сатуны тыю һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында” 2020 елның 19 ноябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән бу* өлкәдәге Татарстан Республикасы законнары, федераль законнар белән балигъ булмаганнарга никотинлы продукция сату, балаларны аны куллануга җәлеп итү тыелуга, шулай ук бу тыюларны бозган өчен административ җаваплылык билгеләнүгә бәйле, юкка чыгарылды. Элек шундый ук нигезләмәләр Татарстан Республикасы законнарында бар иде.

*“Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында” 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 24 сентябрендәге 798 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 17 августындагы 688 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән* балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе вәкаләтләренең исемлеге киңәйтелде.

*2020-2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Хатын-кызларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү – өч яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү шартлары булдыру” федераль проект кысаларында Өч яшькә кадәрге баланы кару ялында торучы хатын-кызларны яңадан укыту һәм аларның квалификациясен күтәрү чараларын гамәлгә ашыру чаралары турында ны карау буенча отпускта булган, шулай ук хезмәт мөнәсәбәтләрендә булмаган һәм эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән мәктәпкәчә яшьтәге балалары булган хатын-кызларны яңадан укыту һәм аларның квалификациясен күтәрү чараларын гамәлгә ашыру чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 14 февралендәге 110 номерлы карары белән* федераль бюджеттан субсидия рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану тәртибе билгеләнде.

*“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, аларны гамәлгә ашыру кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 мартындагы 172 номерлы карары белән:* күпбалалы гаилә һәм (яисә) гаиләнең

аерым затлары тарафыннан милек хокукында үзләренә караган торак урынын (торак урыннарын) йә күрсәтелгән гражданнарга караган милекнең бер өлешен аерып алу буенча алыш-бирешләр ясаганда... күпбалалы гаиләгә сертификат бирелгәнгә кадәрге биш ел исәпкә алына, дип билгеләнә.

*«3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыруга бәйле Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 2 маендагы 358 номерлы карары белән* 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыруга бәйле Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану тәртибе билгеләнде.

*"Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналарның, күпбалалы ата-аналарның хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен эш бирүчегә кайтару өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчен югалтуын тану турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 июнендәге 478 номерлы карары белән* Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналарның, күпбалалы ата-аналарның хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен эш бирүчегә кайтару өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе билгеләнде.

*«Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында һәм муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларны, күрсәтелгән белем алу оешмаларында шундый укучыларның 100 процентын колачлап, түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү чараларының исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 14 июлендәге 588 номерлы карары белән* Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында һәм муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү тәртибе җайга салынды.

*«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны вакытлыча яшәүгә (шул исәптән вакытлыча опекага) алган Россия Федерациясе гражданнары реестрын булдыруга һәм раслауга вәкаләтле башкарма органы турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 27 августындагы № 749 номерлы карары белән* Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен дәүләт бюджет учреждениесеннән ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны вакытлыча яшәүгә (шул исәптән вакытлыча опекага) алган Россия Федерациясе гражданнары реестрын булдыруга һәм раслауга вәкаләт бирелде.

*«Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга һәм уку чорында ике ата-анасында яки бердәнбер ата-анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм дәүләт югары белем бирү оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы инвалидларга социаль*

*ярдәм төрләре буенча 2021 елга түләүләр күләмен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 7 сентябрендәге 792 номерлы карары белән* 2021 елның 1 гыйнварыннан социаль ярдәм төрләре буенча түләүләр барлык милек рәвешләрендәге һәм ведомствога караган белем бирү оешмаларында һөнәри әзерлек программалары, эшче һөнәрләр, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча, квалификацияле эшчеләр әзерләү, урта звено белгечләрен әзерләү программалары, бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән белем алучыларга да кагыла, дип билгеләнде.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 12 маендагы 926-р номерлы күрсәтмәсе белән* 2017–2022 елларга хатын-кызлар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең илкүләм стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын 2020-2022 елларда Татарстан Республикасында үтәү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Координация советы турында нигезләмә төзелде һәм расланды.

*«Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опекун (попечитель) билгеләү яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 ноябрендәге 1148/20 номерлы боерыгы нигезендә* опекун (попечитель) билгеләүнең яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында таныклык бирүнең бердәм стандарты һәм тәртибе билгеләнде.

***Татарстан Республикасы торак законнарының хокук куллану практикасындагы түбәндәге яңалыкларга*** игътибарны җәлеп итә.

*Татарстан Республикасы Конституция суды 2020 елның 29 апрелендәге 90-П карары белән* "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында" 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, аларны гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 12 пунктындагы өченче абзацының, 15 пунктының, 16 пунктындагы икенче абзацының һәм 17 пунктындагы өченче абзацының *конституциячеллегенә хокукый бәя бирде.* Кагыйдәләрнең 12 пунктындагы өченче абзацына һәм 15 пунктындагы беренче абзацына аңлатма бирү, хокук куллану практикасыннан күренгәнчә, гражданны сертификат алу өчен гражданнар исемлегенә кертү турында җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителгән карар буенча гражданнар аларны исемлеккә кертү турында ел саен кабат гариза бирергә, шулай ук аерым очракларда өстәмә документлар бирергә тиешлегеннән чыгып билгеләнә. Кагыйдәләрнең әлеге нормалары эчтәлегенә җентекле анализ уздыру мондый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: сертификат алырга хокуклы дип танылган гражданнарга аларны серификат алу өчен гражданнар исемлегенә кертү турында карарлар кабул итү вәкаләтләре булган җирле үзидарә органы таләбе буенча ел саен нинидидер гаризалар һәм өстәмә документлар бирү вазыйфаларын йөкләми. Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Конституция суды, җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнардан гаризалар һәм өстәмә документлар таләп итү бары тик норматив хокукый акт текстында мондый бурыч турыдан-туры каралган очракта гына мөмкин булуын билгеләп үтәргә кирәк, дип саный. Норматив хокукый акт текстында гражданнарның мондый бурычы булмаса, мондый хокук куллану практикасы, асылда, җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен нигезсез арттыруларын күрсәтә һәм гражданнарга Кагыйдәләрнең шикаять белдерелә торган пунктларында турыдан-туры каралмаган өстәмә бурычларны йөкли.

# 2020 ЕЛДА ТӨП ТОРМЫШ ЭШЧӘНЛЕГЕ ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ БАЛА ХОКУКЛАРЫН ҮТӘҮ

3

БҮЛЕК

## 3.1. Баланың белем алу өлкәсендә хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү

Балаларның белем алуга хокукын тормышка ашыру мәсьәләләре 2020 елда мөрәҗәгатьләр саны буенча беренче урында тора. Әлеге тематика буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 406 мөрәҗәгать керде, ягъни мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынннан 23% тәшкил итә, бу 2019 ел белән чагыштырганда 32%ка кимрәк.

*15 нче диаграмма*

***2020 елда белем алу хокукын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы***




### *3.1.1. Мәктәпкәчә белем*

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы юелешмәләренә караганда, 2021 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү системасында 1 994 белем бирү оешмасы эшли, аларда 220 259 бала тәрбияләә, шул исәптән:

1 690 – муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмасы (аларда – 211 262 бала);

34 – дәүләткә карамаган белем бирү оешмасы (аларда – 3 013 бала);

мәктәпләрдә 270 мәктәпкәчә төркемнәргә 5 935 бала йөри;

база мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәләре булган 16 гаилә балалар бакчасына 49 бала йөри.

Татарстанда 2018-2020 елларда балалар бакчаларында 13 435 яңа урын булдырылды, 59 яңа балалар бакчасы төзелде.

Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, балалар бакчаларында өстәмә урыннар булдыру буенча чаралар күрелә. 2020-2021 елларда «Демография» илкүләм проектының «Хатын-кызларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү – өч яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү шартларын булдыру» Федераль проекты кысаларында тагын 10 меңнән артык өстәмә мәктәпкәчә урын булдыру планлаштырыла, шул исәптән 5 050 ясле яшендәге балалар өчен – 49 балалар бакчасы төзү һәм гамәлдәге балалар бакчаларында 37 өстәмә урын булдыру юлы белән. Чараларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча 2022 елга 3 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеген 100% тәэмин итү планлаштырыла.

2020 елда 29 яңа мәктәпкәчә белем бирү оешмасы төзелгән, аларда 5 495 мәктәпкәчә урын булдырылган. Хәзерге вакытта 1 398 ясле төркеме эшли, аларга 24 478 бала йөри.

Соңгы өч елда гына да капиталь ремонт программасы буенча 292 мәктәпкәчә белем бирү оешмасына ремонт ясалды (реконструкцияләнде). 2020 елда 87 балалар бакчасына 1 771,7 млн. сумлык капиталь ремонт ясалды.



Күрелә торган чаралар нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте дәрәҗәсендә мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында барлык яшь төркемнәрендә балалар чиратының кимүе күзәтелә. Мәктәпкәчә учреждениеләрдә балаларның гомуми чираты 2020 елда 34,4%ка кимегән (19 925 баладан 13 071 бала чиратта).

*10 нчы таблица*

***2019-2020 елларда мәктәпкәчә оешмаларда балалар чираты***

| күрсәткеч | 2019 | 2020 | Динамика, % |
|---|---|---|---|
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында чиратта торучы балаларның гомуми саны *кеше)* | 19 925 | 13 071 | -34,4% |
| 0-1,5 яшь (тулы яшь) | 417 | 341 | -18,2% |
| 1,5-3 яшь | 14 376 | 9 036 | -37,1% |
| 3-7 яшь (тулы яшь) | 5 132 | 3 694 | -28% |

Шулай булса да, балалар бакчасында балага урын алу мәсьәләсе актуаль булып кала. Казан, Чаллы шәһәрләрендә, Әлмәт, Питрәч, Лаеш, Түбән Кама, Биектау, Арча муниципаль районнарында чират сакланып кала. Бигрәк тә Казан, Чаллы шәһәрләрендә хәлләр кискен тора.

*11 нче таблица*

***2020 елда дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә урын белән тәэмин ителмәгән балалар саны***

| **Муниципаль район (шәһәр округы)** | ***2020 елда дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә урын белән тәэмин ителмәгән балалар саны,яшьләре*** | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **2 айдан 1,5 яшькә кадәр** | **1,5 яшьтән 3 яшькә кадәр** | **3 яшьтән 7 яшькә кадәр** | **барысы** |
| Казан шәһәре | 148 | 5193 | 2543 | **7884** |
| Чаллы шәһәре | 103 | 1621 | 277 | **2001** |
| Әлмәт | 24 | 754 | 104 | **882** |
| Питрәч районы | 15 | 333 | 305 | **653** |
| Зеленодольск районы | 12 | 450 | 78 | **540** |
| Лаеш районы | 13 | 226 | 223 | **462** |
| Түбән Кама районы | 17 | 226 | 24 | **267** |
| Биектау районы | 5 | 114 | 101 | **220** |
| Арча районы | 4 | 119 | 39 | **162** |
| **ТР буенча БАРЫСЫ** | **341** | **9036** | **3694** | **13071** |

Республиканың калган районнарында балалар бакчаларына чират юк.

2020 елда балалар бакчасында урын алу мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 158 мөрәҗәгать керде, бу 2019 ел белән

чагыштырганда 11%ка күбрәк (2019 елда – 142). Әлеге тематика буенча мөрәҗәгатьләр саны елдан-ел арта бара.

Мәктәпкәчә белем алу хокукын гамәлгә ашыру турында гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр категориясен түбәндәгечә бүлергә мөмкин:

48% (76 мөрәҗәгать) – өч яшькә кадәрге балага балалар бакчасында урын бирүгә ярдәм итү мәсьәләләре;

47% (74 мөрәҗәгать) – 3 яшьтән олырак балага балалар бакчасында урын бирүгә ярдәм итү мәсьәләләре;

5% (8 мөрәҗәгать – мөмкинлекләре чикле балаларга балалар бакчаларында урын бирү мәсьәләләре.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләренә (балалар бакчаларына) гаризалар кабул итү, исәпкә кую һәм балаларны алу» административ регламентын бозу очракларын тикшерү барышында «Электрон балалар бакчасы» АИС электрон базасында балалар бакчаларын комплектлаганда балалар чиратының бозылу очраклары табылмады.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына мөрәҗәгать иткән ата-аналарның күбесенә җирле үзидарә органнары тарафыннан балалар бакчасының яшәү урыныннан ерак булуы аркасында баш тарткан ата-аналарга башка учреждениеләрдә урыннар тәкъдим ителде.

Шул ук вакытта, күп кенә ата-аналарга (27 ата-ана) мәгариф идарәсе органнары белән берлектә, чиратны күчерү юлы белән ата-аналар риза булган башка балалар бакчасында урын алуда ярдәм ителде. Мөрәҗәгать иткәнчегә кадәр бу ата-аналар мондый мөмкинлекнең булуы турында хәбәрдар булмаганнар.

2020 елда балаларны карау буенча хезмәтләр күрсәткәндә мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлегенә карата шикаятьләргә бәйле гражданнар мөрәҗәгатьләренең саны ике тапкырга кимеде.

Әмма соңгы елларда гражданнардан кергән ике шикаять беренче тапкыр мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында бәхетсезлек очракларына китергән хокук бозуларга бәйле иде. Әлеге хәлләр Казан шәһәре Совет районының 110 нчы балалар бакчасында һәм Казанда Хөсәен Мәүлетов урамындагы Sun School хосусый балалар бакчасында булды.

Әлеге фактлар буенча Татарстан Республикасы прокуратурасына хәбәр ителде, анда прокурор ягыннан тиешле чаралар күрелде.

Тикшерү чараларын үткәргәндә, мәктәпкәчә оешма җитәкчеләре тарафыннан «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон таләпләре һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада булган вакытта укучыларның бәхетсезлек очракларын тикшерү һәм исәпкә алу тәртибен раслау турында»гы 2017 елның 27 июнендәге 602 номерлы боерыгының бозылуы ачыкланды.

Шуның белән бергә, белем бирү процессында катнашучылар белән конфликтлы хәлләр килеп чыккан түбәндәге 3 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы игътибар үзәгендә булды:

Әгерҗе шәһәренең «8 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет балалар мәгариф учреждениесе (МББМУ),

Казан шәһәре Идел Буе районының «Катнаш төрдәге 131 нче «Стрекоза» балалар бакчасы» МББМУ,

Казан шәһәре Мәскәү районының «Катнаш төрдәге 279 нчы балалар бакчасы» МББМУ,

«Бибигон» мәктәпкәчә яшьтәге балаларны үстерү үзәге» балалар өчен шәхси белем бирү учреждениесе (ЧУДО).

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил югарыда күрсәтелгән оешмаларны гамәлгә куючылар адресына хокук бозулар һәм аларны бетерү буенча чаралар күрү турында бәяләмә юллады.

Гражданнар мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларга хезмәт күрсәтүчетүбәндәге ике шәхси оешма эшчәнлеге дә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибар үзәгендә булды:

Шулай итеп, граждан Х. тарафыннан бирелгән мәгълүмат буенча, Казан шәһәрендә урнашкан «Муми-Троль» балалар клубы (Интернетта шәхси балалар бакчасы буларак карала) мәктәпкәчә белем бирү оешмасына хас хезмәтләрнең тулы спектрын тәкъдим итә: 08.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр балаларны карау һәм тәрбияләү буенча хезмәтләр; балаларны ашату оештырылган; белем бирү программалары гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта оешманың белем бирү эшчәнлеген алып бару хокукына лицензиясе юк, балалар әлеге учреждениедә булганда аларның иминлеге тәэмин ителмәгән.

Әлеге факт буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тикшерү үткәрү инициативасы белән чыкты. Россия авыл хуҗалыгы күзәтчелегенең Татарстан Республикасы идарәсе белгече административ тикшерү максатында объектка килгәч, аны объектка кертмиләр, моның буенча, пүнәтәйләр катнашында, видеояздырулар ясап һәм фотога төшереп, бу балалар оешмасындагы хокук бозулар турында беркетмә төзелә. Административ хокук бозу турындагы эшне караучы башкаручы вазыйфаи зат таләпләрен аңлы рәвештә үтәмәү Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 17.7 ст. буенча квалификацияләнә. Шуңа бәйле рәвештә, Россия авыл хуҗалыгы күзәтчелегенең Татарстан Республикасы идарәсе тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 17.7 ст. буенча беркетмә төзелде, барлык документлар судка җибәрелде.

Республика шәһәрләре һәм районнары прокурорлары тарафыннан Мәгариф турындагы законнарның үтәлешенә күзәтчелекне гамәлгә ашырганда 2 673 хокук бозу очрагы ачыкланды, аларны бетерү өчен 901 беркетмә төзелде, 1 056 тәкъдим кертелде, алар буенча 1 515 вазыйфаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылды, административ хокук бозу (14) турында 19 эш кузгатылды.

Аерым торучы биналарда урнашкан республиканың барлык мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 2 августындагы 1006 номерлы карары (алга таба – 1006 номерлы карар таләпләре) нигезендә, карарда күрсәтелгән террорчылыкка каршы тиешле иминлек таләпләрен үтәп, паспортлаштырылды. Шул ук вакытта, террорчылыкка каршы иминлек турындагы законнарны бозу очраклары да ачыкланды.

Мәсәлән, 1006 нчы номерлы карар таләпләрен бозганда, районның мәктәпкәчә оешмаларында объектларны (территорияләрне) терроризмнан яклауны тәэмин итү өчен җаваплылык Кама Тамагы районы прокуроры тарафыннан тәрбиячеләргә йә хуҗалык җитәкчелегенә йөкләнде. Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының террорчылыкка каршы һәм янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы җитәкчеләрен билгеләү турында боерыклар үтәлде, закон бозулар бетерелде.

Зеленодольскиның шәһәр прокуроры тарафыннан 12 номерлы «Земляничка» балалар бакчасында террорчылыктан яклау таләпләренең бозылуы ачыкланды, аерым алганда: учреждение металл детектор белән җиһазландырылмаган; ведомство саклау хокукына ия федераль башкарма хакимият органнарының шәхси сак оешмалары хезмәткәрләре яки ве-

домство саклау бүлекчәләре тарафыннан объектларны (территорияләрне) саклау тәэмин ителмәгән. Шундый ук хокук бозулар 9 мәктәпкәчә оешмада ачыкланган. Балалар бакчалары җитәкчеләренә җитешсезлекләрне бетерү максатыннан шәһәр прокуроры 2020 елның 30 ноябрендә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турында күрсәтмәләр бирде.

Инициативалы тикшерүләр барышында ата-аналардан белем бирү оешмалары ихтыяҗлары өчен акча җыю фактлары ачыкланды.

Мәсәлән, Казан шәһәренең Идел буе районы прокуроры тарафыннан Казан шәһәре Идел Буе районының «31 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә тәрбияләнүчеләрнең ата-аналарын хуҗалык, канцелярия товарлары, көнкүреш химиясе сатып алуга, шулай ук төркем ихтыяҗлары өчен беркетелгән суммада акча җыярга мәҗбүр итүләре ачыкланган. Тикшерү нәтиҗәләре буенча район прокуроры тарафыннан балалар бакчасы мөдиренә күрсәтмә бирелгән, 2 тәрбияче дисциплинар җаваплылыкка тартылган, закон бозуларны бетерү буенча чаралар күрелгән.

Шәһәр һәм район прокурорлары тарафыннан мәктәпкәчә оешмаларда тәрбияләнүчеләрне тукландыруда санитар-эпидемиологик законнарның бозылу очракларын ачыклау дәвам итә. Мондый тәртип бозулар Чаллы шәһәре, Казан шәһәренең Мәскәү һәм Яңа Савин районнарыы, Кама Тамагы, Зеленодольск, Әлки, Әлмәт, Әгерҗе, Аксубай, Азнакай, Арча, Баулы, Балтач, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Зәй, Кукмара, Нурлат, Саба, Тукай, Тәтеш, Чирмешән муниципаль районнары прокурорлары тарафыннан ачыкланды.

Шундый ук тәртип бозулар шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында да очрый. Мондый бозулар Актаныш районы, Казан шәһәренең Киров һәм Мәскәү районнары прокурорлары тарафыннан ачыкланды. Ачыкланган фактлар буенча прокурор тәэсире чаралары күрелгән.

### *3.1.2. Гомуми белем бирү*

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләренә караганда, 2020/2021 уку елында Татарстан Республикасында 1 403 гомуми белем бирү оешмасы эшли, аларда 449 761 бала укый, шул исәптән:

1384 – дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү мәктәбе һәм интернат-мәктәпләр, аларда 447 237 бала укый, шуларның 248ендә (18%) югары дәрәҗәдә белем бирү программаларын үзләштерәләр, аларда 201 038 бала укый;

19 – дәүләткә карамаган мәктәп, аларда 2 524 бала укый.

*12 нче таблица*

***2020/2021 уку елында Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары челтәре***

| Белем бирү оешмаларының төрләре | Мәктәпләр саны, бер. | Аларда укучы балалар саны , кеше |
|---|---|---|
| **Дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү мәктәпләре һәм интернат мәктәпләр, шул исәптән:** | **1 384** | **447 237** |
| башлангыч мәктәпләр | 99 | 4 532 |
| төп мәктәпләр | 346 | 16 281 |
| урта мәктәпләр | 871 | 416 415 |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен гомуми белем бирү оешмалары | 53 | 7 868 |

| | | |
|---|---|---|
| шифаханә тибындагы интернат мәктәпләр | 2 | 220 |
| кечке мәктәпләр | 10 | 1 710 |
| Девиант холыклы балалар өчен махсус мәктәп | 1 | 29 |
| башка министрлыклар һәм ведомстволар карамагындагы мәктәпләр | 2 | 182 |
| **Дәүләткә крамаган мәктәпләр** | **19** | **2 524** |

Статистик хисап белешмәләренә караганда, 2020/2021 уку елында дәүләт (муниципаль) көндезге гомуми белем бирү оешмаларында 449 761 бала укый, бу алдагы уку елына караганда 4,7%ка күбрәк.

*16 нчы диаграмма*


***2016/2017 – 2020/2021 уку елларында Татарстан Республикасының көндезге дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмаларында укучылар санының үзгәрү динамикасы (кеше)***




2020/2021 уку елында 529 – шәһәр һәм 855 авыл гомуми белем бирү оешмалары эшләде.

*17 нче диаграмма*

***2016/2017 – 2020/2021 елларда Татарстан Республикасында шәһәр һәм авыл мәктәпләре нисбәте***




2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча, балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә гражданнарны иң борчыган мәсьәләләрнең түбәндәгеләр булуы ачыкланды:

республика территориясендә махсус эпидемиологик режим гамәлдә булган чорда дистанцион белем бирүне оештыру;

белем бирү процессында катнашучылар арасында конфликтлар;

укучыларны транспорт белән тәэмин итү;

укучыларны дәреслекләр һәм уку әсбаплары белән тәэмин итү;

белем бирү оешмаларын үзгәртеп кору мәсьәләләре.

Яңа короновирус инфекциясе буенча эпидемиологик вәзгыять чорында Татар-

стан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге, социаль челтәрләрне һәм массакүләм мәгълүмат чараларын мониторинглау, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына килгән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау барышында балаларның белем алуга хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга бәйле мәсьәләләр ачыкланды.

Республикада 6 апрельдән барлык мәктәп укучылары дистанцион режимда укыдылар. Республиканың муниципаль районнарыннан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына килгән белешмәләргә караганда, интернет булмау сәбәпле, 16 муниципаль районның 45 торак пунктында укучылар ***дистанцион укуны оештыруда кыенлыклар*** кичерде. Шул уңайдан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен, мәгълүмати технологияләрне һәм элемтәне цифрлы үстерү министры А.Р. Хәйруллинга мөрәҗәгать юллады. Мәсьәлә оператив рәвештә эшкә алынды.



Шуны әйтергә кирәк, бу чорда Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан җирле үзидарә органнары белән берлектә дистанцион укучы балаларны компьютер техникасы һәм планшетлар белән тәэмин итү буенча ашыгыч чаралар күрелде.

Республиканың төрле районнарыннан аз керемле һәм күп балалы гаиләләрдән булган өлкән сыйныф укучыларына дистанцион уку өчен Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча 30 млн сумнан артык суммага 2 меңнән артык ***компьютер җайланмалары*** бушлай файдалануга тапшырылды. 13 апрельдән аз керемле һәм күп балалы гаиләләрдән булган укучыларга ***планшетлар*** тапшырылды.



«Бердәм Россия» партиясе «Өйдә укырга ярдәм ит» проектын башлап җибәрде. Үзүзеңне изоляцияләү чорында республиканың 480 мәктәбе 2019/2020 уку елы ахырына кадәр укучыларга 4 116 бер. компьютер техникасы тапшырды. Югары уку йортлары ректорлары күбрәк авыл мәктәпләрендә укучы 11 нче сыйныф укучылары өчен 124 планшет компьютеры бүләк иттеләр.

«Запас гаджетыңны үз мәктәбеңә бир» һәм «Өйдә укырга ярдәм ит!» хәйрия акцияләре кысаларында Татарстан Республикасы кешеләре һәм бизнес-бергәлекләр вәкилләре – мәктәпне тәмамлаучылар үз мәктәпләре өчен 391 гаджет җыеп тапшырырга булыштылар.

Техниканы 8 594 укучы алды.

2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына мәктәпләрдә ***белем бирү процессында катнашучылар арасында конфликтлы вәзгыятьләргә бәйле*** гражданнар мөрәҗәгатьләре килү дәвам итте.

Шуның белән бергә шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 2020 елда аларның саны 2019 ел белән чагыштырганда 19%ка кимеде һәм 107 мөрәҗәгать булды, аларның 75%ы – гомуми белем бирү оешмаларындагы һәм балалар спорт оешмаларындагы конфликтларга кагылышлы.

2020 елда белем бирү процессын тиешенчә оештырмауга, педагогик булмаган тәрбияләү ысулларын куллануга, конфликтлы вәзгыятьтә балигъ булмаганнарның аларның сәламәтлеген какшатырлык психик халәттә калуларына бәйле хокук бозулар түбәндәге 19 мәгариф оешмасында һәм ике балалар спорт оешмасында ачыкланды:

*гомуми белем бирү оешмалары:*

Казан шәһәре Вахитов районының «Советлар Союзы Герое А.С.Умеркин исемендәге 116 нчы лицее» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе (МБМУ);

Казан шәһәре Идел буе районының «42 нче урта гомуми белем мәктәбе» МБМУ;

Казан шәһәре Яңа Савин районының «49 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Казан шәһәре Идел буе районының «83 нче лицее – Белем бирү үзәге» МБМУ;

Казан шәһәре Совет районының «141 нче гимназиясе» МАМУ;

Казан шәһәре Совет районының «174 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Казан шәһәре Киров районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрән торган 70 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Казан шәһәре Идел буе районының ««Перспектива» 186 нчы күппрофильле лицее» МБМУ;

Казан шәһәре Яңа Савин районының «13 нче татар телендә белем бирү гимназиясе» МБМУ;

Казан шәһәре Совет районының «187 нче лицее» МБМУ;

Түбән Кама шәһәренең «22 нче гимназиясе» МБМУ;

Казан шәһәре Идел буе районының «114 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Чаллы шәһәренең «27 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Чаллы шәһәренең «60 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Лениногорск муниципаль районының «2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Әлмәт муниципаль районының «21 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Югары Ослан муниципаль районының «Югары Ослан гимназиясе» МБМУ;

Зәй муниципаль районының «6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

*Урта һөнәри белем бирү оешмалары:*

«Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (ДАҺБУ);

*Балалар спорт оешмалары:*

Казан шәһәренең «Стрела» спорт мәктәбе» МБУ;

Әлмәт муниципаль районының «Футбол буенча спорт мәктәбе» МБУ;

Әлеге мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча укучыларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында гамәлгә куючылар, мәгариф оешмалары җитәкчеләре адресына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 18 бәяләмә җибәрелде.

Белем бирү процессында катнашучылар арасында конфликт үсешенә бәйле мөрәҗәгатьләрне караганда, җирле үзидарә органнарына, мәгариф оешмалары җитәкчеләренә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балигъ булмаганнар мәнфәгатьләрендә вәзгыятьләрне конструктив хәл итүдә медиатив алым куллану кирәкле тәкъдим ителде.

Казан шәһәре Киров районының аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнә торган «70 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУнең балалар иҗтимагый оешмасы ресурсларын кулланып конфликтларны хәл итү буенча эш тәҗрибәсе игътибарга лаек. 2015 – 2016 уку елыннан башлап мәктәптә ***Мәктәп килештерү хезмәте (алга таба – Килештерү хезмәте)*** эшли. Килештерү хезмәтенең кураторы -педагог-психолог, мәктәптә укучылар арасыннан 7 волонтер бар, алар профильле смена кысаларында Килештерү хезмәтендә эшләү күнекмәләренә өйрәнү буенча тренинг дәресләре узганнар. Килештерү хезмәте укучылар, педагоглар, ата-аналар белән эшли. Үзара мөнәсәбәтләрне конфиденциаль

рәвештә торгыза, конфликтларны хәл итә. Мәктәптә Килештерү хезмәте булдыру аркасында балалар, үз гамәлләре өчен җаваплылыкны үз өсләренә алып, теләсә нинди конфликтлы хәлдән дә чыгу юлы барлыгын аңлыйлар.

Конфликтлы ситуацияләрне хәл итүдә психологик хезмәтләр мөһим инструмент булып тора.

*13 нче таблица*

***2018/2019 – 2020/2021 елларда укучыларга психологик (психотерапевтик) ярдәме күрсәтү***

| Күрсәткеч | 2018/2019 уку елы | 2019/2020 уку елы | 2020/2021 уку елы |
|---|---|---|---|
| Психологик (психотерапевтик) ярдәм күрсәтү оештырылган гомуми белем бирү мәктәпләре саны | 507 | 511 | 533 |
| Мәгариф системасында булдырылган психологик-педагогик хезмәтләр саны | 26 | 26 | 27 |
| Гомуми белем бирү учреждениеләрендә психологлар саны | 507 | 511 | 533 |
| Штатта педагог-психологлар ставкалары булдырган мәктәпләр саны | 548 | 605 | 568 |

Республикада әлеге хезмәтләр үсешенең түбәндәге уңай аспектларын билгеләп үтәргә кирәк:

1. Психологик-педагогик ярдәм күрсәтелә торган мәктәпләр саны арту тенденциясе саклана;

2. Психологлар булмаган белем бирү оешмаларына психологик абонемент принцибы буенча ярдәм итүче муниципаль психологик-педагогик хезмәтләр челтәре үсә.

2. Республиканың психологик хезмәтләре эшчәнлеген координацияләүне, төрле ведомстволарга караган учреждениеләрнең психологик практикасы өлкәсендә бердәм һөнәри киңлекне үстерүне Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Ориентир» ресурс үзәге гамәлгә ашыра.

Болар барысы да психологик хезмәтләр эшенең нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итә, һәм балалар белән эшләүче психологларның кадрлар потенциалының өзлексез, системалы үсешен тәэмин итәргә, аларның эшчәнлегенә бердәм методик ярдәм күрсәтергә һәм системалы мониторинг нәтиҗәләре буенча эшчәнлекне корректировкаларга тиеш.

2020 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибарына түбәндәге ***гомуми белем бирү оешмаларына укучыларны алып баруны оештыру*** мәсьәләләре дә эләкте:

Питрәч муниципаль районының «Богородское гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Казан шәһәре Совет районының «185 нче күппрофильле лицее» (Зур Клыки һәм Самосырово торак массивыннан) МБМУ;

Биектау муниципаль районының «1 нче Биектау урта гомуми белем мәктәбе» МБМУ;

Лениногорск муниципаль районының «Ивановка төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ.

Шуның белән бергә Россия Федерациясе Конституциясенең 43 статьясы һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 56 статьясы белән дәүләт яки муниципаль белем бирү учреждениеләрендә мәктәпкәчә, төп гомуми белем алуның һәркем өчен мөмкин булуын гарантияләү игълан ителә.

«Мәгариф турында» Федераль законның 9 статьясы нигезендә муниципаль берәмлекләрдә һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез гомуми белем бирүне оеш-

тыру муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән.

Шул ук вакытта, күрсәтелгән законның 40 статьясы нигезендә, җирлекләр арасында төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларында укучыларны транспорт белән тәэмин итү (ягъни укучыларны белем бирү оешмаларына кадәр илтүне һәм кире кайтаруны оештыру) тиешле оешмаларны гамәлгә куючылар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Ачыкланган җитешсезлекләрне исәпкә алып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан чаралар күрелде, муниципаль берәмлекләр башлыкларына хокук бозу турында нәтиҗәләр җибәрелде. Питрәч, Биектау муниципаль районнарында транспорт белән тәэмин итү мәсьәләләре балалар мәнфәгатьләрендә үз чишелешен тапты. Калган проблемалы хәлләр Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил контролендә кала.

***Мисал:***

*Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Зур Клыки торак массивында яшәүче укучылар өчен Казан шәһәре Совет районының «185 нче күппрофильле лицей» МБМУга һәм Казан шәһәренең «Весна» торак комплексында урнашкан балалар бакчасына җәяү йөрү мөмкинлеген тәэмин итүдә булышу мәсьәләсе буенча гражданнардан мөрәҗәгатьләр килде.*

*Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре гражданнар мөрәҗәгатьләрендә бәян ителгән дәлилләрне урында тикшерү өчен Зур Клыки торак массивына чыктылар. Алар шуны ачыкладылар, рәсми үтеп йөрү булмау аркасында халык Нокса елгасы аша капма-каршы якка юлны мөстәкыйль рәвештә үзләре ясаганнар. Әлеге үтеп йөрү юлы балалар өчен бик имин түгел һәм ул шәхси милектәге җир кишәрлеге аша уза.*

*Халыкка, Нокса елгасын читләтеп, Зур Клыки торак массивына үтү мөмкинлеген тәэмин итү максатларында Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан «Совет районының Октябрь урамы буенча урнашкан җир кишәрлегенә даими гавами сервитутны билгеләү турында» 2020 елның 29 гыйнварында 191 номерлы карар чыгарылган. Шуның белән бергә, ачык сервитут билгеләнгән, 16:50:150416:283 кадастр номеры булган җир кишәрлеге хуҗасы тарафыннан әлегәчә юл ачылмаган. Әлеге факт буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан тиешле чаралар күрелмәгән.*

*Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Казан шәһәре Мэрына хокук бозу һәм аларны бетерү буенча чаралар күрү турында бәяләмә җибәрде. Мәсьәлә контрольдә кала.*

Гражданнарның күп санлы мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә, ***укучыларны дәреслекләр һәм уку әсбаплары белән тәэмин итү*** мәсьәләсе дә анализлау предметы булды.

Шулай итеп, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына «Иннополис мәктәбе» ДАМУ укучыларын дәреслекләр белән тиешенчә тәэмин итмәү мәсьәләсе буенча гражданнар мөрәҗәгате килде. Гариза бирүчеләр мәгълүматы буенча, мәктәптә күп кенә дәреслекләр җитешми, дәреслекләрнең бер өлешен ата-аналар үз акчаларына сатып алган. Әлеге мәсьәләне өйрәнү нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр ачыкланды.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге номерлы 273 Федераль законның 8 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе субъектларының мәгариф өлкәсендәге дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә торган нормативлар нигезендә, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, хезмәт өчен түләү чыгымнарын да кертеп, җирле бюджетларга субвенцияләр бирү юлы белән

муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне, хезмәт өчен түләү, дәреслекләр һәм уку әсбаплары, укыту, уен әйберләре, уенчыклар сатып алу өчен түләүне кертеп (бианаларны карап тоту һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнарыннан тыш) тәэмин итү;

Россия Федерациясе субъектларының муниципаль белем бирү оешмаларын һәм белем бирү оешмаларын дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда кулланырга рөхсәт ителгән дәреслекләр һәм әлеге белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда кулланырга рөхсәт ителгән уку әсбаплары белән федераль исемлек нигезендә тәэмин итүне оештыру.

Татарстан Республикасында муниципаль белем бирү оешмаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларын дәреслекләр белән тәэмин итү тәртибе «Татарстан Республикасында муниципаль белем бирү оешмаларын һәм дәүләт белем бирү оешмаларын дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда кулланырга рөхсәт ителгән дәреслекләр һәм әлеге белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда кулланырга рөхсәт ителгән уку әсбаплары белән федераль исемлек нигезендә тәэмин итү тәртибен (алга таба – **Тәртип**) раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1115 номерлы карары белән билгеләнгән.

Тәртип нигезендә дәреслекләр белән тәэмин итү процессында катнашучылар түбәндәгеләр була:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары);

белем бирү оешмалары.

Шул ук вакытта:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы дәреслекләр белән тәэмин итүне оештырганда вәкаләтле җирле үзидарә органнарының җыелма заказлары нигезендә дәүләт заказын җыялар;

Вәкаләтле җирле үзидарә органнары белем бирү оешмаларының дәреслекләргә җыелма заказын җыеп, аны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына тапшыралар;

белем бирү оешмалары җитәкчеләре киләсе уку елына дәреслекләргә заказны раслыйлар һәм дәреслекләрне комплектлау, дәреслекләрдән тулы файдалану һәм аларның сакланышы өчен җаваплы булалар.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тәкъдим иткән материалларны анализлау нәтиҗәләре буенча, әлеге проблеманың «Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (ДАМУ) администрациясенең яңа уку елына заказ оештырганда килеп чыгуы ачыкланды.

Шулай итеп, «Иннополис мәктәбе» ДАМУ җитәкчесе Татарстан Республикасында муниципаль белем бирү оешмаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларын дәреслекләр белән тәэмин итүнең билгеләнгән тәртибен бозган, бу, үз чиратында, балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга китергән.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан гамәлгә куючы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына хокук бозу һәм аларны бетерү буенча чаралар күрү турында бәяләмә җибәрелде.


Белем бирү оешмалары тарафыннан укучыларны дәреслекләр һәм эш дәфтәрләре белән тәэмин итү мәсьәләсе республика прокуратурасы контролендә кала.

2020 елда үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, әлеге мәсьәлә буенча прокурорлар тарафыннан белем бирү оешмаларына һәм муниципаль бүлекләргә закон бозуларны бетерү турында 124 күрсәтмә бирелде, судларга 7 дәгъва гаризасы җибәрелде, шулай ук Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрына күрсәтмә бирелде.

Белем бирү оешмаларында ***төрле сәбәпләр аркасында укымый калган*** балалар саны кимү күзәтелә. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләренә караганда, 2020/2021 уку елында республикада төрле сәбәпләр аркасында укымый калган балалар саны 223 булды, бу узган ел күрсәткеченнән 59 кешегә (21%) кимрәк. 2014/2015 уку елыннан аларның саны дүрт тапкырга кимегән.

*18 нче диаграмма*

***2014/2015 – 2019/202020 уку елларында мәктәп яшьтәге укымый калган балалар саны***




Әлеге статистик хисапка анализ ясаганда, 223 баладан 149 бала – 14-17 яшьтәгеләр, 74 бала – 13 яшькә кадәрге балалар.

223 бала

126 (57%) бала сәламәтлеге буенча белем ала алмый, шул исәптән 80 бала -сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар;

97 бала мәктәптән киткән, шул исәптән 46 бала эшкә урнашу сәбәпле киткән, 51 бала – башка сәбәпләр аркасында, шул исәптән сәламәтлек торышы буенча.

Бу хәл балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр белән тыгыз хезмәттәшлектә, мәгариф оешмасына дәрескә йөрмәү сәбәпләрен һәм шартларын ачыклауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар системасын үстерү кирәклеге турында сөйли.

2020 елда ***өй шартларында алучы һәм үзлегеннән укучы*** балаларны укытуны оештыру мәсьәләсе контроль-күзәтчелек эшчәнлеге предметы булып кала.

Ата-аналар (законлы вәкилләр), өй шартларында белем алуны сайлап, мәгариф оешмаларында белем алудан баш тарта һәм үз өстенә, шул исәптән өй шартларында белем алу вакытында (белем бирү оешмаларыннан тыш) барлыкка килә торган йөкләмәләр ала. Аерым алганда, ата-аналарда (законлы вәкилләрдә) белем алу рәвешен сайлаганда, укучының өй шартларында белем алуын тәэмин итү – белем, күнекмәләр һәм компетенцияләр үзләштерүне, эшчәнлек тәҗрибәсе бирүне, көндәлек тормышта белемнәрне куллану тәҗрибәсен бирүне һәм укучыда белем алу мотивациясен формалаштыруны тәэмин итү буенча йөкләмәләр барлыкка килә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләренә караганда, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын өй шартларында һәм үзлегеннән үзләштерүче балаларның гомуми саны 1198гә җитә, бу 2019/2020

уку елы белән чагыштырганда 3,2%ка күбрәк (2019/2020 уку елында – 1 161 кеше), шул исәптән:

– өй шартларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучылар – 1099 кеше;

– урта гомуми белем бирү программасы буенча үзлегеннән белем алу рәвешендә укучылар – 99 кеше.

Өй шартларында укуны оештыруның торышы барлык муниципаль районнарда да Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан эш визиты һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган статистик мәгълүматлар кысаларында анализланды.

2020 елда гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы укучыларның өй шартларында гомуми белем бирү программаларын үзләштерү һәм ***төрле сәбәпләр аркасында белем бирү оешмаларында белем алмаган балаларның*** өй шартларында белем алуы турындагы вәзгыятьләрне анализлау, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары хәбәрләре буенча, түбәндәге проблемалы очракларны ачыклады.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә массакүләм мәгълүмат чараларыннан Әлмәт шәһәрендә 2007 елда туган балигъ булмаган баланың хокукка каршы гамәл кылуы, нәтиҗәдә аның әнисе вафат булуы мәгълүм булды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил әлеге факт буенча тикшерү үткәрде, аның нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр ачыкланды.

Элегрәк балигъ булмаган **С.** озак вакыт дәвамында Татарстан Республикасы Түбән Кама районында законлы вәкилләрдән башка гына әбиседә яшәгән. Бу факт җирле үзидарә органнары, авыл җирлеге башлыгы, мәгариф идарәсе органнары ягыннан да игътибардан читтә калган.

2019 елның мартында Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт муниципаль районы буенча бүлегенең ПДНына балигъ булмаганның әбисе оныгын мәктәпкә урнаштыруда ярдәм итүләрен сорап мөрәҗәгать иткән, чөнки әнисе аны гадәти мәктәптә укытуга каршы. 2019 елның июлендә балигъ булмаган баланың әнисе Мәгариф идарәсендә була, шуннан соң улын өй шартларында укыта башлый. Бу вакытта балага 12 яшь була. 2019 елның июленә кадәр бала гомуми белем бирү оешмасына кертелмәгән һәм беркайда да укымаган.

Шуның белән бергә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль Закон) 5 статьясы нигезендә һәр кешенең белем алу хокукын гамәлгә ашыру максатларында, җирле үзидарә органнары тарафыннан сәламәтлек мөмкинлекләре чикле затларга белем алу өчен махсус педагогик алымнар нигезендә кирәкле шартлар тудырыла.

Федераль законның 9 статьясы нигезендә мәгариф өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр дә керә:

федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш, муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру;

мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алу, муниципаль белем бирү оешмаларын муниципаль районның, шәһәр округының конкрет территорияләренә беркетү;

Федераль законның 63 статьясындагы 5 өлеше нигезендә муниципаль районнарның

һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче һәр дәрәҗәдәге гомуми белем алу хокукына ия балаларны һәм ата-ана (законлы вәкилләр) тарафыннан билгеләнгән белем алу рәвешләрен исәпкә алып баралар.

Федераль законның 44 статьясы нигезендә җирле үзидарә органнары, мәгариф оешмалары балигъ булмаган балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) балаларны тәрбияләүдә, аларның физик һәм психик сәламәтлеген саклауда һәм ныгытуда, индивидуаль сәләтләрен үстерүдә һәм аларның үсешендәге кимчелекләрне тиешенчә коррекцияләүдә ярдәм итәләр.

Шулай ук социаль челтәрләрдән Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә Бөгелмә шәһәрендә ана үзенең кече яшьтәге инвалид баласына белем бирүне тәэмин итә алмавы турында да мәгълүм булды. Соңрак Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына инвалид баланың әнисе **В.** мөрәҗәгать итте. Мәсьәләне оператив карау нәтиҗәсендә түбәндәгеләр билгеләнде.

**В.** ханымның 2010 елда туган инвалид баласы бар. Әмма 2020 елның 1 сентябренә кадәр бала гомуми белем бирү оешмасына кертелмәгән һәм беркайда да укымаган.

Шулай итеп, җирле үзидарә органнарының гамәлләре балигъ булмаганнарның хокукларын бозуга китергән. Шул уңайдан Әлмәт һәм Бөгелмә муниципаль районнары башлыкларына закон бозылу һәм аларны булдырмау буенча чаралар күрү турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан бәяләмәләр җибәрелде.

Балаларга өстәмә белем бирү системасын саклау һәм үстерү мәсьәләсе мөһим булып кала. 2020 елда Татарстан Республикасында балаларга өстәмә белем бирү буенча 438 мәгариф оешмасы, балалар спорт оешмалары эшли, аларда 320 меңнән артык бала шөгыльләнә, бу мәктәп укучыларының гомуми санының 71,2%ын тәшкил итә.

*14 нче таблица*

***2020 елда Татарстан Республикасында балаларга өстәмә белем бирү оешмалары һәм аларда шөгыльләнүче балалар саны***

| Эшчәнлек юнәлешләре буенча оешмалар | Балаларга өстәмә белем бирүче оешмалар саны, берәмлекләр | Аларда укучылар саны, кеше |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | **154** | **187 159** |
| Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | **103** | **36 827** |
| Татарстан Республикасы спорт министрлыгы | **171** | **92 465** |
| Дәүләткә карамаган балаларга өстәмә белем бирү оешмалары челтәре | **10** | **3 596** |
| **Барысы** | **438** | **320 047** |

Чаллы, Әлмәт һәм Түбән Камада «Кванториум» өч балалар технопаркы балаларга өстәмә белем бирүне оештыруның яңа форматы булып кала, алар базасында 5 яшьтән 18 яшькә кадәрге 2000 бала инженер күнекмәләрен арттыралар.

Гражданнарның күмәк мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә, Казан шәһәрендә балалар муниципаль спорт мәктәпләрен үзгәртеп кору һәм мәктәпләрнең олимпия статусын калдыру турындагы мәсьәлә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил игътибарына эләкте. Мөрәҗәгать итүчеләр, мондый үзгәртеп кору тренировка процессы сыйфатын начарайта-

чак, ярышларда актив катнашу мөмкинлегенә тискәре йогынты ясыйачак, олимпия резервы статусын югалту аркасында ата-аналарга спорт-тренировка процессының түләүлегә күчүе финанс чыгымнарын арттыруга китерәчәк, дип борчылалар. Болар барысы да балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга китерә.

Мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча, хәзерге вакытта Казан шәһәрендә Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы 29 муниципаль физкультура-спорт оешмасы (16 спорт мәктәбе һәм олимпия резервының 13 спорт мәктәбе) һәм 4 муниципаль спорт объекты эшләп килүе ачыкланды. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты югарыда күрсәтелгән учреждениеләрне алар базасында 9 физкультура-спорт берләшмәсе (алга таба – ФСО) булдыру юлы белән үзгәртеп оештыруны тәкъдим итә.

Татарстан Республикасы спорт министрлыгы һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан Казан шәһәрендә физик культура һәм спорт тармагын үстерүгә тискәре йогынты ясарга мөмкин булган әлеге үзгәртеп кору мәсьәләсе буенча тискәре позиция әйтелде. Нәтиҗәдә, әлеге үзгәртеп кору балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга китерергә мөмкин.

Моннан тыш, Россия Федерациясе Спорт министрлыгы билгеләп үткәнчә, спортчылар әзерләүче оешмалар берләшмәсе төбәк проектын, шулай ук «Демография» илкүләм проектының «Спорт – тормыш нормасы» федераль проктын үтәмәүгә китерергә мөмкин.

Әлеге факт буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Президенты Р.Ф. Миңнехановка һәм Казан шәһәре Мэрына тискәре нәтиҗәләрне бетерү өчен әлеге процессны туктатып калуда ярдәм итүне һәм, олимпия резервы статусын саклап калып, балигъ булмаганнар мәнфәгатьләрендә физкультура-спорт оешмаларын этаплап үзгәртеп кору проектын эшләп бетерергә күрсәтмә бирүне үтенеп, мөрәҗәгать җибәрде.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча, спорт мәктәпләренең тренерлар составы, тарификация нигезендә хезмәт хакы фонды, барлык өстәмәләр һәм премияләрне дә кертеп, сакланачак, дип хәбәр итте. Бүген бюджеттан тыш акчалары булмаган спорт мәктәпләре хезмәткәрләренең ФСО кысаларында эшләрне сыйфатлы башкарган өчен өстәмә акча алу мөмкинлеге барлыкка киләчәк, Казан шәһәренең Физик культура һәм спорт комитеты карамагындагы муниципаль учреждениеләрне үзгәртеп кору, барлыкка килгән һәр мәсьәләне аерым өйрәнеп, спорт мәктәпләренең берсенә дә тискәре йогынты ясамаслык итеп, этаплап башкарылачак.

Гомуми белем бирү өлкәсендә бала хокуклары һәм аның законлы мәнфәгатьләре үтәлешен анализлауны исәпкә алып, югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, түбәндәгеләрне тәкъдим итү максатка ярашлы булыр дип уйлыйм:

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика һәм муниципаль комиссияләргә үз утырышларында балаларның өй шартларында һәм үзлегеннән белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру вәзгыятьләрен карарга һәм балигъ булмаганнарның белем алуга хокукларын яклау буенча тиешле карарлар кабул итәргә һәм чаралар күрергә

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә:

республика психологик хезмәтләренең, Татарстан Республикасында «Ориентир» ресурс үзәгенең белән берлектә, төрле ведомстволарга караган учреждениеләрнең психологик практикасы өлкәсендә бердәм һөнәри киңлекне үстерү, балалар белән эшләүче психологларның һөнәри компетенцияләрен системалы рәвештә арттыру, аларның

эшчәнлегенә бердәм методик ярдәм күрсәтү һәм системалы мониторинг нәтиҗәләре буенча эшчәнлекне корректировкалау буенча үзара нәтиҗәле хезмәттәшлеге аша балигъ булмаганнарга психологик ярдәм күрсәтүнең сыйфатын арттыруны, аннан һәркемнең файдалану алу мөмкинлеген тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Мәгариф идарәсе органнары белән берлектә:

мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны тиешенчә исәпкә алуны тәэмин итәргә, муниципаль белем бирү оешмаларын муниципаль районның, шәһәр округының конкрет территорияләренә беркетергә;

җирле үзидарә органнары белән берлектә, балигъ булмаганнар эшләре буенча муниципаль комиссияләргә федераль законның балаларның катгый рәвештә гомуми белем алуга кагылышлы таләпләрен үтәмәүгә китерә торган шартларына һәм сәбәпләренә җентекле анализ ясарга;

Татарстан Республикасында муниципаль белем бирү оешмаларын һәм дәүләт белем оешмаларын дәреслекләр белән тәэмин итүнең билгеләнгән тәртибе кысаларында белем бирү оешмаларының дәреслекләргә заказларны үз вакытында формалаштыруның һәм дөреслеген контрольгә алырга;

белем бирү оешмалары каршындагы белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасындагы бәхәсләрне җайга салу буенча комиссияләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар комплексын кертергә;

педагоглар һәм балалар арасында конфликтсыз мөнәсәбәтләр булдыру буенча эшне дәвам итәргә.

### *3.1.3. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга белем бирү*

Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының сәламәтлек мөмкинлекләре чикле һәм инвалидлык буенча укучыларга белем бирү өлкәсендәге (алга таба – СМЧ) сәясәте ике өстенлекле юнәлеш буенча формалашуын дәвам итә: инклюзив белем бирү системасын үстерү һәм гамәлдәге коррекцион мәктәпләре һәм балалар бакчалары челтәренә ярдәм итү һәм аны үстерү.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләренә караганда, 2020 елда республикада сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның гомуми саны 29 310 кеше иде, шулардан 17 291 – мәктәпкәчә яшьтәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар, 12 019 – мәктәп яшендәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар.

*15 нче таблица*

***2018-2020 елларда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен мәктәпкәчә учреждениеләр саны һәм аларга йөрүче балалар саны***

| Төп күрсәткечләр | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре яисә шундый балаларга белем бирүче учреждениеләр саны | 492 | 495 | 492 |
| *шуларга йөрүче сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны (кеше)* | 16 089 | 16 045 | 15 911 |
| Компенсацияләүче мәктәпкәчә белем бирү оешмалары саны | 17 | 16 | 17 |
| *шуларга йөрүче сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны (кеше)* | 1885 | 1496 | 1488 |

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 2020 елда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен яки сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга белем бирүче мәктәпкәчә белем бирү оешмалары саны 2019 ел белән чагыштырганда кимегән, нәтиҗәдә, сәламәтлек мөкинлекләре чикле балаларга белем бирү 2%ка диярлек кимегән.

Мәгариф идарәсе органнарында исәптә торучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле ***мәктәпкәчә яшьтәге*** 7 291 бала арасыннан 15 911 бала (92,1%, 2019 елда – 16 045 бала, 93,6%) мәктәпкәчә белем ала, шулардан:

14 594 бала (91,8%, 2019 елда – 14 952 бала, 93,2%) махсуслаштырылган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына яки төркемнәргә йөри;

1 317 бала (8,3%, 2019 елда – 1 093 бала, 7%) – махсуслаштырылган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына яки гомуми типтагы төркемнәргә йөри.

*16 нчы таблица*

***2018-2020 елларда мәктәпкәчә белем алучы мәктәпкәчә яшьтәге СМЧ балалар саны, кеше***

| Төп күрсәткечләр | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|
| ***Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә белем алучы мәктәпкәчә яшьтәге СМЧ балалар саны,*** *шулардан:* | **16089** | **16045** | **15911** |
| гомуми типтагы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче СМЧ балалар саны | 1307 | 1093 | 1317 |
| махсуслаштырылган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче мәктәпкәчә яшьтәге СМЧ балалар саны | 14782 | 14952 | 14594 |
| мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрмәүче мәктәпкәчә яшьтәге СМЧ балалар саны | **696** | **1097** | **1380** |

Мәгариф идарәсе органнарында исәптә торучы мәктәпкәчә яшьтәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле 15 911 бала арасыннан иң күп өлешен сөйләме бозылган (84%), күрү сәләте бозылган (7%) һәм терәк-хәрәкәт системасы бозылган (5,4%) балалар тәшкил итә.

*17 нче таблица*

***2018 – 2020 елларда авырулар төрләре буенча мәктәпкәчә яшьтәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны, кеше***

| Төп күрсәткечләр | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|
| Ишетү сәләте бозылган балалар саны | 224 | 176 | 147 |
| Күрү сәләте бозылган балалар саны | 1 337 | 1 447 | 1 147 |
| Сөйләме бозылган балалар саны | 13 439 | 13 231 | 13 320 |
| Терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар саны | 1 086 | 816 | 847 |
| Акыл үсеше буенча артта калган балалар саны | 590 | 662 | 668 |

2019/2020 уку елында терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар – 23,2%ка, ишетү сәләте бозылган балалар 21,4%ка кимегән. Шул ук вакытта акыл үсешендә тайпылышлар булган балалар – 12,2%ка, сөйләме бозылган балалар – 3%ка, күрү сәләте бозылган балалар 8,2%ка арткан.

2019/2020 уку елында мәктәпкәчә яшьтәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга белем бирү мәгариф идарәсе органнарында исәптә торучы балаларның 88,1%ын тәшкил итте (2018 елда – 90%).

*18 нче таблица*


***2020 елда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле мәктәпкәчә яшьтәге балаларны авырулар төрләре буенча укыту***

| **Күрсәткечләр** | **Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле мәктәпкәчә яшьтәге балалар чаны, барысы** | **Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле мәктәпкәчә яшьтәге белем алучы балалар саны** | |
|---|---|---|---|
| Сөйләме бозылган балалар саны | 4 320 | 4108 | 95,1% |
| Ишетү сәләте бозылган балалар саны | 147 | 106 | 72,1% |
| Күрү сәләте бозылган балалар саны | 1 147 | 904 | 78,8% |
| Терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар саны | 847 | 411 | 48,5 |
| Акыл үсеше буенча артта калган балалар саны | 668 | 506 | 75,7 |

2020/2021 елда педагог-дефектологлар санының артуы күзәтелде: республиканың мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында 137 педагог-дефектолог (2019/2020 уку елында – 124) һәм 958 логопед (2019/2020 уку елында – 934) эшли.

*19 нчы диаграмма*

***2017 – 2020 елларда мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында эшләүче профильле белгечләр саны***




Аутизм белән авыручы балалар өчен (алга таба – РАС) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан махсус мәктәпкәчә төркемнәр булдыру буенча эш оештырылды. Хәзерге вакытта 15 балалар бакчасында 21 төркем оештырылган, анда 140 бала тәрбияләнә. Түбәндәгеләрдә махсуслаштырылган мәктәпкәчә төркемнәр эшли:

Казан шәһәре (168 нче урта белем бирү мәктәбендә, 407, 109, 165, 332, 290, 33 нче балалар бакчаларында),

Чаллы шәһәре (17, 41, 81, 105, 106, 110 ныч балалар бакчаларына),

Бөгелмә шәһәрендә (33 нче балалар бакчасында),

Түбән Кама шәһәрендә (63 нче балалар бакчасында).

Мәктәпкәчә яшь – бик җаваплы чор, бу чорда баланың шәхес булып үсешенә нигез салына, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның мәктәптә алган белемнәренең алдагы казанышлары һәм социаль-эмоциональ иминлеге активлаша башлаган чор.

Бүгенге чынбарлык түбәндәгедән гыйбарәт: сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны, шул исәптән менталь тайпылышлар булган балаларны тәрбияләүче гаиләләр,

балаларны социальләштерү коралы буларак, мәктәпкәчә белем бирүнең мөһимлеген һәм кирәклеген аңлыйлар, мәктәпкәчә балачакны тулы канлы яшәү аларның үзенчәлекле бала булып үсешенең перспективасын, булачак белем алу маршрутын һәм мәктәптә белем алу программасын белгели. Шул ук вакытта ата-аналарның күпчелеге баласын гомуми типтагы балалар бакчасына җибәрергә әзер һәм нәкъ менә мәктәпкәчә белем бирү дәрәҗәсендә инклюзияләргә өстенлек бирә, шул ук вакытта бу оешмаларның үзенчәлекле бала белән эшләргә әзер булмавы белән очраша.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле мәктәпкәчә белем бирү системасы, башлангыч ярдәм күрсәтү кебек үк, мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирүне оештыруның вариатив рәвешләренең дәвамлылыгын тәэмин итәргә тиеш, ата-аналар үзләренең сайлап алу хокукын гамәлгә ашыра алырга һәм ул ата-аналар өчен дә уңайлы һәм бала өчен дә кирәкле булырга тиеш.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Татарстан Республикасы – сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен белем бирү учреждениеләренең бөтен челтәре сакланган Россия Федерациясе субъектларының берсе булып тора. Шул ук вакытта инклюзив белем бирүне үстерү өчен шартлар һәм инновацион механизмнар булдыру буенча системалы эш алып барыла.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләренә караганда, 2020/2021 уку елында ***мәктәп яшендәге*** сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның гомуми саны 12 019 бала булды, шулардан 99,4%ы мәктәптә белем ала (2019 елда – 99,8 %).

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны укыту адаптацияле төп белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы аерым оешмаларда да һәм башка барлык укучылар белән бергә дә, шулай ук аерым сыйныфларда, белем бирү оешмалары төркемнәрендә дә оештырылган.

*19 нчы таблица*

***2018 – 2020 елларда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар укый торган гомуми белем бирү оешмалары буенча санлы белешмәләр***

| Төп күрсәткечләр | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|
| Инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү мәктәпләре саны (массакүләм мәктәпләр) | 334 | 321 | 317 |
| *аларда укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны* | 2879 | 2657 | 2464 |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен махсус (коррекцияле) класслары булган гомуми белем бирү мәктәпләре саны | 27 | 28 | 28 |
| *аларда укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны* | 987 | 716 | 721 |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен махсус (коррекцион) класслар саны | 105 | 107 | 110 |
| *аларда укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны* | 728 | 752 | 786 |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар һәм башка балалар өчен уртак укыту оештырылган класслары булган гомуми белем бирү мәктәпләре саны | 525 | 578 | 584 |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар һәм башка балалар өчен уртак укыту оештырылган класслар саны | 1994 | 2101 | 2139 |
| *аларда укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны* | 3326 | 3201 | 3185 |
| Күрсәтелгән оешмалардагы тьюторлар саны | 93 | 117 | 124 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен гомуми белем бирү оешмалары саны | 52 | 52 | 53 |
| *шул мәктәпләрдә укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны* | 7551 | 7715 | 7 868 |

2020/2021 уку елында Татарстан Республикасында адаптацияле төп белем бирү программалары шулай ук түбәндәгеләр базасында гамәлгә ашырыла:

183 инклюзив мәктәптә, алар сәламәтлек мөмкинлекләре чикле һәм акыл үсешендә кимчелекләр булган (интеллектуаль кимчелекләр) балаларга башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартларын кертүне тәэмин итәләр;

2 шифаханә-интернат мәктәбендә – 220 бала укый;

адаптацияле төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы 53 белем бирү оешмасы.

*20 нче таблица*

| **Учреждениеләр исеме** | **2019-2020 уку еллары** | | |
|---|---|---|---|
| | **Учреждениеләр саны** | **Укчылар саны** | **Бу учреждениеләр эшли торган территорияләр** |
| Барлык мәктәпләр һәм интернат-мәктәпләр, шул исәптән | 53 | 7868 | |
| акыл үсешендә кимчелекләр булган балалар өчен | 37 | 5911 | республиканың 18 муниципаль районында |
| начар күрүче балалар өчен | 4 | 639 | Чаллыда, Казанда, Лаеш районында |
| ишетмәүче, начар ишетүче һәм соңгы вакытта ишетми башлаган балалар өчен | 5 | 479 | Бөгелмә, Алабуга, Чаллы, Түбән Кама, Казан шәһәрләрендә |
| полиомиелит һәм ДЦП белән авырый торган балалар өчен | 4 | 531 | Әлмәт, Чаллы, Казан шәһәрләрендә |
| сөйләмнәре бозылган балалар өчен | 2 | 308 | Чаллы, Казан шәһәрләрендә |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләренә караганда, агымдагы уку елында ишетү, күрү, сөйләм, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балаларны укыту 100% тәэмин ителгән. Акыл үсеше ягыннан артта калган балаларны укыту 99% тәшкил итте.

*21 нче таблица*

***2020-2021 уку елларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле мәктәп яшендәге балаларны авырулар төрләре буенча укыту, кеше***

| ***Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле мәктәп яшендәге балалар саны (авырулар төрләре буенча)*** | **2018** | **2019** | **2020** |
|---|---|---|---|
| **начар күрүче балалар** (белем алу – 100%) | **1644** | **1281** | **1155** |
| алар арасында махсус (коррекцион) белем бирү учреждениеләрендә белем алучылар | 614 | 639 | 639 |
| **сөйләмендә кимчелекләр булган балалар** (белем алу – 100%) | **1167** | **1192** | **1048** |
| алар арасында махсус (коррекцион) белем бирү учреждениеләрендә белем алучылар | 301 | 303 | 308 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **таяну-ахәрәкәтләнү аппаратында кимчелекләр булган балалар** (белем алу – 100%) | **1464** | **1302** | **1383** |
| алар арасында махсус (коррекцион) белем бирү учреждениеләрендә белем алучылар | 451 | 500 | 531 |
| **начар ишетүче балалар** (белем алу – 100%) | **418** | **661** | **691** |
| алар арасында махсус (коррекцион) белем бирү учреждениеләрендә белем алучылар | 418 | 482 | 479 |
| **акыл үсеше буенча кимчелекләр булган балалар** | **7228** | **7584** | **7742** |
| алар арасында мәктәптә укучы балалар | 7091 | 7502 | 7662 |
| алар арасында махсус (коррекцион) белем бирү учреждениеләрендә белем алучылар | 5688 | 5731 | 5911 |

2020/2021 уку елында әлеге категориядәге 2 211 бала өйдә белем ала, шуларның 74е дистанцион рәвештә укый.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле 16 бала бу уку елында өй шартларында белем алудан көндезге укуга күчте.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле 80 бала белем укымый, узган уку елында әлеге күрсәткеч 82 бала иде.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы укучы өчен, аның ихтыяҗларына һәм мөмкинлекләренә бәйле рәвештә, инклюзив белем бирү һәм индивидуаль укыту мөмкинлеген бирә торган «Ресурс классы» махсус белем бирү моделен үстерү буенча эшне дәвам итте. Әлеге модель теләсә кайсы балага белем алу хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итә һәм һәр укучының ихтыяҗларына туры килә торган белем бирүне иң аз чикләнә торган мохиттә оештырырга мөмкинлек бирә. Ата-аналарда бүген нәкъ менә әлеге модельгә ихтыяҗ зур, чөнки ресурс классында укыту адаптацияле белем бирү программалары буенча уза, укучылар эзлекле рәвештә гомуми белем бирү классларына кертелә, алар тьютор ярдәмендә үз яшьтәшләре белән бергә мәктәп фәннәрен өйрәнә алалар. Шул ук вакытта һәр укучы өчен уртак уку вакытының проценты төрле булырга мөмкин. Гомуми белем бирү классында укучылар шәхси тьюторлар белән шөгыльләнәләр, кирәк булганда, алар укучыларга биремнәрне үтәүдә һәм сыйныфташлары белән аралашуда булышалар. Тьютор шулай ук укучыга дәрес материалын үзләштерүдә ярдәм итә.

2020/2021 уку елында Татарстанда «Ресурс классы» моделен кертү өчен 5 гомуми белем бирү мәктәбе билгеләнде:

Казан шәһәре Мәскәү районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 65 нче татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «Соматик авырулары булган балалар өчен озынайтылган уку көне белән 168 нче төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;


Казан шәһәре Идел буе районының «97 нче рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Казан шәһәре Совет районының «156 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Әлмәт шәһәренең «21 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе – «Бир 5» белем бирү үзәге» МБМУ.

*20 нче диаграмма*

***2012-2020 елларда каршылыксыз мохит булдырылган гомуми белем бирү мәктәпләре саны***




2012 – 2020 елларда адаптация буенча чаралар 336 мәктәптә үткәрелде, шул исәптән 46 махсуслаштырылган мәктәптә. 2020 елда 5 мәктәптә аз хәрәкәтләнүче балалар төркемнәре өчен төзекләндерү объектлары барлыкка килде.

Шуның белән бергә, түбәндәге мәсьәләләрдә проблемалар бар әле:

1. Тискәре тенденцияләрнең булуы:

өй шартларында белем алучы балалар саны артты: 2020/2021 уку елында аларның саны 2 211 булды (18,4%);

инклюзив белем бирү системасы үсеше белән бергә барлык төрдәге махсус (коррекцион) гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны артты.

*22 нче таблица*

***2018/2019 – 2020/2021 уку елларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны укыту***

| Төр күрсәткечләр | 2018/2019 | 2019/2020 | 2020/2021 |
|---|---|---|---|
| **Өй шартларында белем алучы мөмкинлекләре чикле балалар саны** | 1 233 | 1 352 | 2 211 |
| инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү мәктәпләрендә (массакүләм мәктәпләр) сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга белем бирүче коллективлар саны | 2879 | 2657 | 2464 |
| сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен гомуми белем бирү оешмаларында укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны | 7551 | 7715 | 7868 |

Шул ук вакытта, инклюзив мәктәпнең төп таләбен түбәндәгечә бирергә мөмкин: бернинди кыенлыкларга яки аермаларга карамастан, мөмкин булганда, барлык балалар барлык очракларда да бергә укырга тиеш. Инвалидларны махсус мәктәпләргә, сыйныфларга, секцияләргә кабул итү искәрмә булып тора һәм бу гадәти сыйныфларда уку баланың белем яки социаль ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмый торган сирәк очракларда гына, йә бу аның үзе яки башка балалар иминлеге өчен кирәк булганда гына тәкъдим ителә.

Ишетү һәм күрү сәләте бозылган балалар өчен яшәү урыны буенча гомуми мәктәптә коррекция юнәлешендә белем алу мөмкинлеге аеруча проблемалы булып кала.

*23 нче таблица*

***2018/2019 – 2020/2021 уку елларында кимчелекләр төрләре буенча мәктәп яшендәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны***

| Төп күрсәткечләр | 2018/2019 | 2019/2020 | 2020/2021 |
|---|---|---|---|
| **Күрү сәләте бозылган мәктәп яшендәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны** | **1644** | **1281** | **1155** |
| алар арасыннан гомуми мәктәпләрдә укучылар | 1 030 | 642 | 516 |
| **Ишетү сәләте бозылган мәктәп яшендәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны** | **418** | **661** | **691** |
| алар арасыннан гомуми мәктәпләрдә укучылар | 0 | 179 | 212 |

2. Ата-аналар үзенчәлекле баланы яшәү урыны буенча мәктәпкә бирергә теләгән очракта, алар еш кына сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга белем алу өчен махсус шартлар тудыру мөмкинлеге булмау белән очраша.

Һәр бала индивидуаль һәм бу очракта белем бирүнең сыйфат һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләрен түбәндәгеләр тәшкил итә: белем бирү системасының баланың төрле проблемаларын хәл итүдә ярдәм күрсәтергә әзер бул, укыту һәм тәрбияләүнең махсус ысулларын булдыру, махсус уку программаларын һәм укыту, тәрбияләү ысулларын, махсус дәреслекләр, уку әсбаплары һәм дидактик материаллар куллану, күмәк һәм индивидуаль укытуда махсус техник чаралардан файдалану, укучыларга тиешле техник ярдәм күрсәтүче ассистент (ярдәмче) хезмәтләре күрсәтү, төркемле һәм индивидуаль коррекцион дәресләр үткәрү, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар биналарына кереп йөрү мөмкинлеген тәэмин итү һәм башклар.

3. Республика мәктәпләрендә тьютерларның җитәрлек булмавы (124 кеше) аркасында ата-аналар еш кына балаларын гомуми мәктәпкә бирә алмыйлар.

Белем бирүне инклюзив рәвештә нәтиҗәле үстерү һәм әлеге процессның уңышлы булуында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга ярдәм итү һәм булышу системасы мөһим шарт булып тора. Бүгенге көндә тьютор – укучыга индивидуаль белем алу траекториясен булдыру һәм гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыручы зат ул һәм нәкъ менә шул функция сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга карата тьюторлык өчен аеруча мөһим булып тора.

Инклюзив белем бирүдә тьютор, балага булышып, аның хәлен контрольдә тотып, белем алу прцессында, шулай ук коммуникатив планда ярдәм итеп, баланы мәктәпнең белем бирү киңлегенә кертүче ролен үти. Тьютор сәламәтлеге чикле булган баланың уңышлы адаптациясе, аның белем бирү һәм социаль мохиткә нәтиҗәле кереп китүе өчен шартлар тудыручы белгеч сыйфатында эш итә.

Баланың белем бирү маршрутын сайлау буенча белгечләрнең күрсәтмәләрен гаиләдә карау һәм фикерләшү кагыйдәләрен һәм рәвешләрен билгеләү актуаль мәсьәлә булып кала. ПМПК белгечләренең һөнәри эшчәнлегендә яңа бурыч – тәкъдим ителә торган белем бирү маршруты, мәктәптә белем алуның нәкъ менә белгечләр тәкъдим иткән вариантын сайлау нигезләре буенча гаилә белән фикер алышуны оештыру. Белгечләр тәкъдим иткән белем бирү маршрутын сайламаганда, алар ата-аналарга баланың үсешендә һәм укуында барлыкка килергә мөмкин булган хәтәрлекләрне дәлилләп, ышандырып, үтемле итеп аңлатырга тиеш булалар.

Инвалид балаларга һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга белем алу хокукын гамәлгә ашыру өлкәсендә ярдәм итүдә төп бурыч – үсештәге кимчелекләрне коррекцияләү һәм социаль адаптацияләү, махсус педагогик алымнар нигезендә иртә коррекцияләү ярдәме күрсәтү өчен кирәкле шартлар булдыру.

4. Белем бирү оешмаларының 3-4 нче сыйныфларында укучы начар күрүче балалар өчен уку дәреслекләренең федераль исемлектә булмау проблемасы.

Әлеге проблема начар күрүче балалар өчен уку әсбапларының булмау мәсьәләсе буенча инвалид бала Б. әнисенең мөрәҗәгатен карау барышында ачыкланды.

Әлеге мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр ачыкланды.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль законның 8 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе субъектларының мәгариф өлкәсендәге дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә торган нормативлар нигезендә, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, хезмәт

өчен түләү чыгымнарын да кертеп, җирле бюджетларга субвенцияләр бирү юлы белән муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне, хезмәт өчен түләү, дәреслекләр һәм уку әсбаплары, укыту, уен әйберләре, уенчыклар сатып алу өчен түләүне кертеп (биналарны карап тоту һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнарыннан тыш) тәэмин итү;

Россия Федерациясе субъектларының муниципаль белем бирү оешмаларын һәм белем бирү оешмаларын дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда кулланырга рөхсәт ителгән дәреслекләр һәм әлеге белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда кулланырга рөхсәт ителгән уку әсбаплары белән федераль исемлек нигезендә тәэмин итүне оештыру.

Татарстан Республикасында муниципаль белем бирү оешмаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларын дәреслекләр белән тәэмин итү тәртибе «Татарстан Республикасында муниципаль белем бирү оешмаларын һәм дәүләт белем бирү оешмаларын дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда кулланырга рөхсәт ителгән дәреслекләр һәм әлеге белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда кулланырга рөхсәт ителгән уку әсбаплары белән федераль исемлек нигезендә тәэмин итү тәртибен (алга таба – Тәртип) раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1115 номерлы карары белән билгеләнгән.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларына билгеләнгән Тәртип нигезендә, бүлеп бирелгән бюджет акчалары чикләрендә, аларның гаризалары буенча дәреслекләр үзәкләштереп җибәрүне башкара.

Шул ук вакытта, башлангыч мәктәп – балалар бакчасы 3-4 сыйныф укучылары өчен дәреслекләргә һәм уку әсбапларына заказ формалаштыра алмады, чөнки дәреслекләрнең федераль исемлегенә белем бирү оешмаларының 3-4 сыйныфларында белем алучы начар күрүче балалар өчен уку әдәбияты кертелмәгән.

Нәтиҗәдә, педагоглар, рус теле, математика һәм уку буенча материалларны арттырып бастырып чыгарып, дәрескә уку материалларын мөстәкыйль рәвештә әзерләргә мәҗбүр булалар. Уку процессында, гадәти дәреслекләрдән тыш, шрифты зурайтылган электрон китаплар кулланыла, бу балаларның сәламәтлегенә тискәре йогынты ясый һәм начар күрүче балаларның проблемаларын да катлауландыра.

Балыкка килгән вәзгыятьне исәпкә алып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, балаларга белем алу хокукын яхшырак тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе мәгариф министры С.С. Кравцовка, белем бирү оешмаларының 3-4 сыйныф укучылары өчен тиешле уку әдәбиятын Федераль дәреслекләр исемлегенә кертү мәсьәләсен карауны, ә әлеге әдәбият булмаганда – бу эшне башлап җибәрүне сорап мөрәҗәгать итте.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга белем бирү өлкәсендә ачыкланган проблемалы мәсьәләләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, муниципаль мәгариф идарәсе органнары, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары җитәкчеләре белән берлектә, түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк дип саныйбыз:

сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар тәрбияләүче ата-аналарга (законлы вәкилләргә) мәгълүмат бирүдә төбәк (муниципаль) мөмкинлекләр (хезмәт күрсәтүләр, оешмалар, социаль сервислар һ.б.) комплексында аларның юнәлешен тәэмин итә торган тотрыклы эшләүче ярдәм система булдыру;

баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) белән тыгыз хезмәттәшлектә индивидуаль маршрутларны эшләү һәм тормышка ашыру, бу, балалар үсешендә физик һәм (яки) психологик җитешсезлекләргә карамастан, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның (шул исәптән инвалид балаларның) һәрьяклы үсеше өчен тигез мөмкинлекләр тудырачак;

белем бирү оешмалары дәрәҗәсендә инклюзиянең төрле модельләрен гамәлгә ашыру, бу барлык балаларның, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек белем алу шартларын булдырырга мөмкинлек бирәчәк;

менталь тайпылышлы, шул исәптән дауна синдромлы балалар тәрбияләүче гаиләләр белән һөнәри берләшмәдә үзара хезмәттәшлекне оештыруда нәтиҗәле алымнар таратуга ярдәм итүче төрле ведомстволарга караган оешмалар һәм коммерциягә карамаган оешмалар базасында һөнәри стажировка мәйданчыклары булдыру эшен дәвам итәргә;

һәр балага белем алу хокукын тәэмин итәргә һәм һәр укучының ихтыяҗларына туры килә торган белем бирүне оештырырга, сыйфатлы белем алуны дискриминациясез алырга шартлар тудырырга мөмкинлек бирә торган, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның социаль үсешен, шул исәптән инклюзив белем бирү системасын оештыру аша, тәэмин итә торган «Ресурс классы» моделен үстерергә.

## 3.2. Баланың яшәү һәм гаиләдә тәрбияләнү хокукын үтәү

Соңгы елларда гражданнарның гаиләгә һәм гаилә мөнәсәбәтләренә хокукларын тәэмин итү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләре гомуми мөрәҗәгатьләр арасында икенче урында тора.

Шул ук вакытта 2020 елда әлеге тематика буенча мөрәҗәгатьләр саны 2019 ел белән чагыштырганда 29 %ка кимегән. Әлеге тематика буенча 389 мөрәҗәгать каралды, бу мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 28% тәшкил итте.

*27 нче диаграмма*

***2020 елда гаилә мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы***




### *3.2.1. Гаиләдә иминлек булмау проблемалары*

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гаиләнең шәхесне социальләштерү нигезе булуыннан чыгып эш итә. Баланың үсеше, аның иҗтимагый нормаларны һәм мәдәни кыйммәтләрне үзләштерүе гаиләнең социаль климатына бәйле. Нәкъ менә гаилә тирәлеге балага шәхес буларак формалашырга һәм җәмгыятьтә тормышка әзер булырга мөмкинлек бирә.

Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектларының (алга таба – органнар – профилактикалау субъектлары) гаилә

һәм балалар иминлеген ачыклау буенча эшчәнлеге даими рәвештә Бала хокуклары буенча вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге кысаларында игътибар үзәгендә кала.

2020 ел йомгаклары буенча гаилә иминлеге вәзгыятенә һәм аны булдырмау буенча профилактик чараларга анализ ясау түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкинлек бирә.


1. Балигъ булмаган балалары булган һәм төрле авыр тормыш хәлендә калган гаиләләр саны кимегән.

Әйтергә кирәк, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2020 ел ахырына балигъ булмаган балалары булган, авыр тормыш хәлендә калган һәм социаль яклау органнарының ведомство исәбендә торучы 3 577 гаилә булган, бу 2019 елга караганда 219 гаиләгә (6% ка) кимрәк.

Ел ахырына бу гаиләләрдә барлыгы 6 464 бала яшәгән, бу 2019 елга караганда 66 балага (1% ка) кимрәк. Балаларның гомуми санынан мондый балалар 0,8 % тәшкил итә.

*28 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда социаль яклау органнарының ведомство исәбендә торучы гаиләләр һәм аларда тәрбияләнүче балалар саны (кеше)***





2. Балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрдә ведомство исәбендә торучы гаиләләр, аларда яшәүче балалар саны 2019 ел дәрәҗәсендә калган.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белешмәләренә караганда, 2020 елда балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрдә ведомство исәбендә торучы 4 444 гаиләдә 7 588 бала яши. Мондый балалар саны 0,9%ка арткан.

*29 нчы диаграмма*

***2015 – 2020 елларда ПДН ведомство исәбендә торучы гаиләләр һәм аларда тәрбияләнүче балалар саны (кеше)***




3. Профилактикалау субъектлары гаилә һәм балалар иминлеген ачыклау буенча эшчәнлектә активрак булдылар.

Әйтергә кирәк, 2020 ел дәвамында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау системасы субъектлары белгечләре тарафыннан 4 373 ***сигнал картасы*** җибәрелгән.

4. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең карарлары нигезендә 2020 елда, социаль куркыныч факторлар булуга бәйле рәвештә, 1244 гаилә (сигнал карталары җибәрелгән гаиләләрнең гомуми санынннан 28,4%) ведомствоара исәпкә куелган, 2019 елда -1052 гаилә).

5. Профилактика субъектлары игътибар зонасына эләккән гаиләләр саны арту социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр санының артуына китергән – 6,6 %ка, алардагы балалар саны 8,7 %ка арткан.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белешмәләренә караганда, «Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасының бердәм мәгълүмат банкын формалаштыру турында» 2010 елның 22 апрелендәге 294 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә оештырылган «Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны һәм аларның гаиләләрен исәпкә алу һәм мониторинглау» Бердәм мәгълүмат системасы банкында ведомствоара исәптә 2020 ел дәвамында социаль куркыныч хәлдә булган 1 306 гаилә торган. Аларда 2 726 балигъ булмаган бала яши, бу балалар халкының гомуми санынннан 0,4% тәшкил итә, шулар арасында:

155 балигъ булмаган бала – закон белән каршылыкка керүчелә (6,3 %);


737 (30%) – гаилә әгъзалары тарафыннан рәхимсезлеккә дучар ителгән балигъ булмаган балалар;

1 244 (50,7 %) – алкогольле эчемлекләр белән мавыгучы ата-аналарыннан яки законлы вәкилләреннән бәйле балигъ булмаган балалар.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы буенча тормышка ашырыла торган «Аек акыл» ведомствоара проектының гаиләдәге авыр һәм куркыныч тормыш хәлләренең төп сәбәбен – алкогольгә бәйлелекне җиңеп чыгарга ярдәм итә торган нәтиҗәле инструмент булуын игътибарга алып һәм социаль ятимлекне профилактикалауга юнәлдерелгән социаль әһәмиятле проектның уңышлы гамәлгә ашырылуын исәпкә алып, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үтенече буенча Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан 2021 елда «Аек акыл» проектын гамәлгә ашыруны дәвам итү һәм проектның яңа этабына 80 кешене кертү өчен 9 995,0 мең сум акча бүлеп бирү турында карар кабул ителде.

*30 нчы диаграмма*


***2016-2020 елларда социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр һәм аларда тәрбияләнгән саны балалар саны***



Тулаем алганда, 2020 ел ахырына Татарстан Республикасында төрле дәрәҗәдәге имин булмаган хәлдә 7 472 гаилә яши, аларда 13 299 бала, ягъни барлык балаларның 1,6 проценты яши.

*31 нче диаграмма*

***2016–2020 елларда төрле дәрәҗәдәге имин булмаган хәлдә яшәүче гаиләләр һәм аларда яшәүче балалар саны***




Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, профилактика субъектларының имин булмаган хәлдә калган балалы гаиләләрне иртә ачыклау эше оперативрак һәм нәтиҗәлерәк булды, бу профилактика субъектларының игътибар зонасына эләккән гаиләләр һәм балалар саны артуга китерде.

*23 нче таблица*

***2019 – 2020 елларда профилактика субъектлары тарафыннан җибәрелгән сигнал карталары саны***

| ***Профилактика субъекты*** | ***Җибәрелгән сигнал карталары саны*** | | |
|---|---|---|---|
| | ***2019 елда*** | ***2020 елда*** | Динамика, % |
| эчке эшләр органнары | 1318 (28 %) | 1 476 (34 %) | 12,0 |
| сәламәтлек саклау идарәсе органнары | 760 (16,2 %) | 607 (14 %) | -20,1 |
| социаль яклау органнары һәм учреждениеләре | 737 (15,8 %) | 582 (13,5 %) | -21,0 |
| мәгариф идарәсе органнары | 662 (14,1 %) | 668 (15 %) | +1 |
| ТРында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты (112 телефоны хезмәте) | 581 (12,4 %) | 385 (9 %) | -33,7 |
| опека һәм попечительлек органнары | 334 (7,1 %) | 270 (8 %) | -19,2 |
| җинаять-үтәтү инспекциясе | 180 (3,8 %) | 225 (5 %) | +25,0 |
| авыл җирлекләре башлыклары | 57 (1,2 %) | 51 (1,2 %) | -10,5 |
| яшьләр эшләре һәм спорт буенча органнар | 15 (0,3 %) | 35 (0,8 %) | +133,3 |
| мәдәният органнры һәм учреждениеләре | 5 (0,1 %) | 6 (0,1 %) | +20,0 |
| башка органнар һәм гражданнар хәбәрләре | 40 (0,8%) | 68 (1,6 %) | +70,0 |

Шуның белән бергә, профилактика системасы органнары – субъектлары эшчәнлеге җитәрлек дәрәҗәдә түгел һәм аны камилләштерү буенча чаралар күрү таләп ителә.

***Имин булмаган вәзгыятькә оператив тәэсир итү*** мәсьәләсе актуаль булып кала. СОП мәгълүмат системасына эчке эшләр органнары тарафыннан җибәрелә торган сигнал карталарының өлеше шактый зур кала (2020 елда – барлык сигнал карталары саныннан – 34%, 2019 елда – 28 %), бу, кагыйдә буларак, озак вакытлар имин булмаган хәлдә торучы гаилә ведомствоара игътибар зонасына эләгә дигән сүз.

Сәламәтлек саклау, мәгариф идарәсе, опека һәм попечительлек органнары эшчәнлегенә активлык җитми.

Авыл җирлекләре башлыкларының, яшьләр эшләре органнарының, мәдәният органнарының һәм учреждениеләренең гаилә иминлеген ачыклаудагы активлыгы аеруча түбән булып кала.

Мәсәлән, «Ведомстволарның социаль куркыныч хәлдәге (СОП) гаиләләрне индивидуаль реабилитацияләү программаларында (ИПРда) катнашуы» җыелма хисабы» буенча, 2020 ел нәтиҗәләре буенча гаилә иминлеген ачыклауда түбәндәгеләр бөтенләй катнашмады:

Аксубай, Әлки муниципаль районнарында мәгариф органнары;

Әтнә районында сәламәтлек саклау органнары;

Әлки, Бөгелмә, Чүпрәле, Мөслим, Спас, Ютазы муниципаль районнарында, Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнарында опека һәм попечительлек органнары.

Югары Ослан муниципаль районында яшьләр эшләре, спорт һәм туризм буенча органнарның һәм учреждениеләрнең (ИПРны гамәлгә ашыруда катнашулары – 25%), мәдәният органнары һәм учреждениеләренең (ИПРны гамәлгә ашыруда катнашулары – 25%), белем бирү учреждениеләренең (ИПРны гамәлгә ашыруда катнашулары – 63%) катнашу дәрәҗәсе аеруча түбән;

Алабуга муниципаль районында социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаган балаларны һәм аларның гаиләләрен ачыклауда яшьләр эшләре, спорт һәм туризм буенча органнарның һәм учреждениеләрнең катнашуы 28% тәшкил итә, мәдәният идарәләренеке һәм учреждениеләренеке – 18%;

Балык Бистәсе муниципаль районында җирле үзидарә башлыкларының социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне ИПР проектларын эшләүдә һәм тормышка ашыруда катнашуы бөтенләй күзәтелми;

Кукмара муниципаль районында да җирле үзидарә башлыкларының социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне индивидуаль реабилитацияләү программаларын (ИПР) гамәлгә ашыруда катнашулары (3 %), яшьләр сәясәте органнарының (42 %), мәдәният учреждениеләренең (29 %), опека һәм попечительлек органнарының (39%) җирле үзидарә органнарының (39%) түбән булуы ачыкланды.

Имин булмаган гаиләләрне иртә ачыклау буенча эшнең мөһимлеген исәпкә алып, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр эшчәнлегендә хокук бозуларны һәм кимчелекләрне ачыклап һәм эш визитлары барышында бу өлкәдәге хәлләрнең торышын анализлап, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Югары Ослан, Алабуга, Мамадыш, Нурлат, Теләче, Балык Бистәсе, Кукмара муниципаль районнары башлыклары адресына ачыкланган хокук бозулар һәм мондый эшнең җитәрлек булмавы турында бәяләмәләр җибәрелде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен караганда башка районнарда да охшаш характерда ачыкланган хокук бозуларның булуын исәпкә алып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына мәгариф оешмалары җитәкчеләре катнашында уздырыла торган алдагы киңәшмәләрдә, педагогик советларда, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, сигнал карталары ресурсларыннан файдаланып, имин булмаган гаиләләрне алдан ачыклау мәсьәләсен карауны планлаштыру үтенече белән мөрәҗәгатьләр җибәрелде.

Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасы Бердәм мәгълүмат банкын (алга таба – Бердәм банк) булдыру һәм куллану максатларының берсе – гаиләнең имин булмаган очракларына профилактикалау системасындагы төрле органнарның оператив игътибар итүен һәм үзара хезмәттәшлеген булдырудан гыйбарәт.

Шуның белән бергә, 2020 ел нәтиҗәләре буенча, аерым муниципаль органнарда балигъ булмаганнарның хокукларын яклау буенча тиешле чараларның вакытында күрелмәве ачыкланды. Сигналь карталары Бердәм мәгълүмат банкын булдыру регламентында каралган срокларны шактый бозып каралган. Мондый фактлар түбәндәгеләрдә ачыкланды:

Чирмешән муниципаль районында – эчке эшләр органнары тарафыннан ике гаиләгә сигнал карталарының сроклары бозылган (имин булмаган гаиләләр 2020 елның 18 ноябрендә ачыкланган, ә сигнал картасы 2020 елның 4 декабрендә куелган);

Арча муниципаль районында эчке эшләр органнары тарафыннан шулай ук ике гаиләгә сигнал карталары соңга калып куелган;

Чаллы шәһәрендә эчке эшләр органнары тарафыннан бер гаилә буенча сигнал картасы срогы бозылып куелган (имин булмаган гаиләләр 2020 елның 10 августында ачыкланган, сигнал картасы 2020 елның 25 декабрендә куелган).

Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаган балалар һәм аларның гаиләләре турында гражданнарның имин булмаган гаиләләр турындагы мөрәҗәгатьләрен карау һәм Татарстан Республикасының Бердәм мәгълүмат банкын анализлау нәтиҗәләре буенча, ведомстволарның гаиләләрне комплекслы тикшерү турындагы белешмәләре Әгерҗе, Биектау, Зеленодольск, Кукмара, Мамадыш, Чирмешән районнарында тутырылмавы ачыкланды.

Гаилә турында белешмәләрнең җитәрлек булмавы гаилә хәленә сыйфатлы анализ ясарга һәм гаиләгә ярдәм күрсәтү буенча тиешле карар кабул итәргә комачаулый. Нәтиҗәдә, гаиләне һәм балаларны профилактикалау эше имин булмауның сәбәпләрен бетерүгә түгел, ә аның нәтиҗәләрен бетерүгә юнәлдерелә. Профилактика органнары эшендә мондый хәлләр булырга тиеш түгел.

Имин булмаган гаиләләр белән эшләүдә профилактика органнары – субъектлары тарафыннан ***хәтәр төркем гаиләләрне реабилитацияләү эшенең сыйфатына*** аерым игътибар бирелә. Аерым районнарда эшләнә торган индивидуаль реабилитацияләү программаларының (алга таба – ИПР) нәтиҗәлелеге мәсьәләсе актуаль булып кала.

Күрсәтелә торган ярдәмнең күпчелек өлеше социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан күрсәтелә – 57 %, чараларның 14 %ы – мәгариф органнары һәм учреждениеләре тарафыннан, 9 %ы – сәламәтлек саклау органнары һәм учреждениеләре тарафыннан башкарылган.

Районнарга эш визитлары, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау субъектлары эшчәнлеген, закон белән конфликтка кергән балаларны индивидуаль реабилитацияләү программаларының (ИТР) үтәлешен анализлау нәтиҗәләреннән балигъ булмаганнар катнашында булган хокук бозулар буенча торгызу медиациясен куллануга әзер булмау ачыкланды.

Шуның белән бергә, торгызу медиациясенең максаты – конфликтлы якларның килешүенә ирешү генә түгел, балигъ булмаганнар катнашында хокук бозуларны профилактикалау да ул. Торгызу медиациясе процедурасы кысаларында балигъ булмаганнарга үз гамәлләре өчен җаваплылык алу мәсьәләләре карала, ә Килештерү килешүендә мондый хәлләр кабатланмасын өчен балигъ булмаганнарның нинди адымнар ясарга тиешлеге күрсәтелә. Медиатив алым куллану яшүсмерләр һәм яшьләр арасындагы конфликтларны хәл итәргә ярдәм итә.

Моннан тыш, иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылган, әмма Россия Федерациясендә җинаять җаваплылыгы башлана торган яшькә җитмәгән балаларга карата хөкем итүне торгызуны гамәлгә ашыру, балалар һәм яшүсмерләр катнашында конфликтларны кисәтүнең һәм хәл итүнең Россия Федерациясе өчен яңалык булган медиатив-торгызу алымнарын һәм механизмнарын гамәлгә ашыру, хокук бозуларга оператив игътибар итү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 июлендәге күрсәтмәсе белән 2020 елга кадәр медиация хезмәтләре челтәрен үстерү концепциясе (алга таба – Концепция) расланды, ул 2024 елга кадәр дәвам итәчәк. Концепциядә медиация хезмәтләре челтәрен булдыру, аларның эшен оештыру, кадрлар әзерләү, алар ярдәмендә балалар һәм яшүсмерләр белән эшләүгә медиатив һәм торгызу практикасын кертү, шәхес тәрбияләүдә һәм формалаштыруда катнашучы барлык дәүләт һәм иҗтимагый институтларны – гаиләдән алып югары мәктәпкә кадәр, хокук бозучыларны җәлеп итә торган органнарны һәм оешмаларны да кертеп, җәлеп итү, шулай ук балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү өлкәсендә дәүләт идарәсенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән төп чаралар билгеләнгән.

Шулай итеп, закон белән конфликтка кергән балалар белән эшләүдә медиатив-торгызу ысуллары һәм технологияләр әлеге категория балалар белән эшләүдә кулланыла һәм эшләнә торган ИПРда чагылырга тиеш.

Шунысы ачык, ***социаль авыр хәлдә булган гаиләләр белән реабилитация эше*** уйланган вакытлы кысалар белән генә чикләнергә тиеш, күрәсең. Алай булмаса, мондый гаиләләрдә балаларның авыр хәле еллар буе дәвам итәргә мөмкин. Соңгы елларда гаиләләрнең, социаль авыр хәлдә булган гаиләләр буларак, ведомствоара исәптә торуын кыскарту буенча вәзгыятьне шактый үзгәртә алдык.

Гаиләне ведомствоара исәптә тотуның төп максаты – индивидуаль реабилитацияләү программасын нәтиҗәле эшләү, гаиләгә авыр тормыш хәленнән чыгарга булышырлык реаль ярдәм күрсәтү. Шуның белән бергә, гаиләнең ведомствоара исәптә уңай динамикасыз озак торган очраклары да бар.

Мәсәлән, 2020 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эш визиты кысаларында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр белән эшне анализлаганда түбәндәгеләр ачыкланды:

Кукмара муниципаль районында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр буларак 31 гаилә исәптә тора, шул ук вакытта 1 елдан артык исәптә торучылар – 8 гаилә (гаиләләрнең 26%ы): 1 елдан 1,5 елга кадәр – 3 гаилә, 1,5 елдан 2 елга кадәр – 15 гаилә;

Балык Бистәсе районында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр буларак ведомствоара исәптә 16 гаилә тора, шул ук вакытта 1 елдан артык исәптән торучы 3 гаилә бар (гаиләләрнең гомуми санынннан 19%);

Теләче муниципаль районында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр буларак 5 гаилә исәптә тора, шул ук вакытта 1 елдан артык исәптә торучылар – 2 гаилә.

Нурлат муниципаль районында 35 гаилә исәптә тора, шулардан 1 елдан артык исәптә торучы гаиләләр – 3 (9 %), ике елдан артык 1 гаилә исәптә тора.

«Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны һәм аларның гаиләләрен ведомствоара социаль патронажлауны оештыру буенча гомуми статистика» җыелма хисабы нигезендә, Татарстан Республикасында 01.01.2020 – 31.12.2020 еллар чорында ведомствоара учетта 1 елдан артык торучы гаиләләр саны – 260, шул исәптән 2 елдан артык торучылар – 21 гаилә, аларда 47 бала яши.

Имин булмаган гаиләләр белән эшләүдә профилактика органнары – субъектлары эшчәнлеге сыйфатының билгеле бер критерие – социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр белән реабилитацион ведомствоара эш нәтиҗәләре.

2020 елда социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр һәм балалар белән индивидуаль профилактикалау эшен оештырганда һәм үткәргәндә ачыкланган проблемалар уңай реабилитация аркасында ведомствоара мәгълүмат системасында гаиләләрне исәптән төшерү өлешенең кимүенә китергән.

2020 ел нәтиҗәләре буенча уңай реабилитация белән ведомствоара исәптән 961 гаилә (82,6%) алынган, аларда 1 914 балигъ булмаган бала яши. Әлеге күрсәткеч 2019 ел белән чагыштырганда кимегән (84 %).

Социаль приютларда реабилитация узганнан соң балаларның яшәү шартларын бәяләү дә мөһим булып тора. Узган ел махсуслаштырылган учреждениеләрдә тәрбияләнүчеләрнең 97,5 %ы реабилитация узганнан соң гаиләләргә, шул исәптән 82,5%ы – үз гаиләләренә (2019 елда – 82 %, 2018 елда – 80%), 13,3%ы туганнары опекасына яки тәрбиягә бала алган гаиләләргә тапшырылган.

Имин булмаган гаиләләр белән эшләүдә профилактика системасы субъектларының төп бурычлары гаиләдәге проблемаларны иртә ачыклаудан һәм мондый гаиләләргә нәтиҗәле һәм реаль реабилитация ярдәме күрсәтүдән гыйбарәт. Мондый эшчәнлекнең максаты – бала өчен аның үз гаиләсен саклап калу.

2018 елдан ата-ана хокукыннан мәхрүм итүгә бәйле рәвештә ведомствоара исәпкә куелган гаиләләр саны арта. 2020 елда ведомствоара исәптә торучы 75 гаиләдә ата-аналары ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән. Ата-ана хокукыннан мәхрүм ителүчеләрнең күбесе Зеленодольск һәм Түбән Кама районнарында күзәтелә.

2018 елдан балалары вакытлыча дәүләт учреждениеләренә урнаштырылган гаиләләр белән эшне оештыру буенча хәлләр сизелерлек яхшырды.

Балаларны гаиләдән алу өчен федераль законнар белән билгеләнгән нигезләр түбәндәгеләр була:

балаларны Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясы буенча опека һәм попечительлек органы карары белән аерып алу;

эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләре тарафыннан күзәтүчесез калган һәм сукбайлыктагы балигъ булмаган балаларны актлар буенча ачыклау;

авыр тормыш хәленә бәйле рәвештә ата-аналар гаризасы буенча балаларны институцион учреждениеләргә (социаль приютлар, балалар йортлары, сабый йорты) урнаштыру;

балигъ булмаган баланың үз гаризасы нигезендә аны институцион учреждениеләргә (социаль приютлар, балалар йортлары, сабый йорты), урнаштыру.

Шул ук вакытта, 2020 елда Алабуга муниципаль районында балаларны законсыз рәвештә тартып алу очраклары да ачыкланган.


Шулай итеп, Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясы таләпләрен бозып, балигъ булмаган балалар: 04.10.2011 елгы Ш., 01.10.2018 елгы Б., 04.10.2008 елгы Х., 23.01.2007 елгы Х., 13.07.2011 елгы И., 11.02.2013 елгы И., 02.10.2014 елгы Т. «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (ГАУЗ) балалар бүлегенә Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге хатлары нигезендә урнаштырылдылар, ә кече яшьтәге 22.11.2019 елгы П. «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (ГАУЗ) балалар бүлегенә балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе үтенече буенча урнаштырылды.

Әлеге факт буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан чаралар күрелде.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләренә караганда, 2020 елда ата-аналарның икесен дә яки бердәнбер ата-ананы ата-ана хокукыннан мәхрүм итү аркасында ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм ителгән балалар саны 335 кеше булды, бу 2019 елга караганда 30 %ка кимрәк.

*32нче диаграмма*

***2015 – 2020 елларда ачыкланган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саны (кеше)***




2020 ел нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясы тәртибендә опека һәм попечительлек органнары тарафыннан барлыгы 43 бала гаиләдән аерып алынды, бу 2019 елга караганда 13%ка күбрәк.

*24 нче таблица*

| Күрсәткеч | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясында каралган нигезләрдә гаиләдән аерып алынган балалар саны, барлыгы | 63 | 50 | 61 | 38 | 43 |
| шулардан, социаль-реабилитация эшләре уздырылганнан соң, ата-аналарына кайтарылганнар саны | 23 (36,5 %) | 13 (26 %) | 6 (10 %) | 5 (13 %) | 9 (21 %) |

2020 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Әлмәт, Югары Ослан, Алабуга, Зеленодольск, Зәй, Питрәч, Нурлат муниципаль районнарында, Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә балаларны гаиләләреннән аерып алуның 9 факты буенча гражданнардан 13 мөрәҗәгать керде. Балаларны аерып алу факты турындагы һәр хәбәр эшче төркем тарафыннан тикшерелде.



Нәтиҗәдә, мөрәҗәгать итүчеләрнең мондый карарның законсызлыгы турындагы дәлилләре расланмаган, балаларны аерып алу буенча күрелгән чаралар законлы һәм балалар мәнфәгатьләрендә һәм яклау максатында гамәлгә ашырылган, дип табылган.

Ачыкланган проблемаларга карамастан, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге органнар – профилактика системасы субъектлары тарафыннан, прокуратура органнары белән берлектә, имин булмаган гаиләләр белән индивидуаль профилактика һәм реабилитация эшен оештыру буенча республика дәрәҗәсендә системалы эш алып барылганын билгеләп үтәргә кирәк. Актив ведомствоара хезмәттәшлек нәтиҗәсендә республикада соңгы елларда түбәндәге мәсьәләләр уңышлы хәл ителә:

социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны һәм аларның гаиләләрен исәпкә алу өчен бердәм мәгълүмати кыр булдыру һәм үстерү;

профилактика системасы органнары һәм учреждениеләре арасында мәгълүмат алмашуны гамәлгә ашыру;

социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарның һәм аларның гаиләләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча профилактика системасының төрле органнары һәм учреждениеләре тырышлыгын координацияләү.

Әлеге эшне алга таба камилләштерү максатларында кирәкле органнарга-гаилә һәм балалар иминлеген профилактикалау субъектларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк, дип саныйбыз:

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә (алга таба – РКДН) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән берлектә:

РКДН утырышларында социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре белән эшләүдә ведомствоара хезмәттәшлек мәсьәләләрен карау тәҗрибәсен, СОП мәгълүмат системасының бердәм банкын булдыру регламентын бозуга юл куйган районнарны тыңлап, дәвам итәргә;

социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре белән эшләүдә ведомствоара бәйләнешләргә җентекле анализ ясарга; ведомствоара исәпкә кабат куелуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны комплекслы анализларга, ачыкланган проблемаларны бетерү алгоритмнарын эшләп бетерергә һәм әлеге җитешсезлекләргә юл куйган затларны җаваплылыкка тарту мәсьәләләрен тикшерергә.

Җирле үзидарә органнарына, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә:

балигъ булмаганнарны индивидуаль реабилитацияләү программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру, закон белән конфликтка кергән балигъ булмаганнар белән эшләүне оештыру, медиатив-торгызу ысулларын һәм технологияләрен куллану;

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки аларны чикләү турында судка дәгъвалар җибәрү практикасын гаилә белән ведомствоара учет кысаларында кирәкле тернәкләндерү чаралары комплексын уздырганнан соң гына үстерергә.


### *3.2.2. Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру*

Федераль статистик хисап формасы 103-РИК белешмәләре буенча, 2020 ел ахырына Татарстан Республикасында ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саны 10 124 кеше булган, ягъни барлык балаларның гомуми санынннан 1,2% тәшкил иткән (2019 елда – 1,3%, 2018 елда – 1,35%, 2017 елда – 1,4%, 2016 елда – ,5 %). Бу соңгы 12 елда иң түбән күрсәткеч.

Республикада ата-аналардан төрле сәбәпләр аркасында опекага алынган балаларны гаиләләргә урнаштыру мәсьәләсендә тотрыклы хәл күзәтелә. 2020 ел ахырына ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар (алга таба – ятим балалар) гомуми санының 93,7%ын тәшкил итә. Ятим балалар өчен дәүләт учреждениеләрендә 523 бала, ягъни ятим балалар санынннан 5,2%ы тәрбияләнә.

*33 нче диаграмма*


***2011–2020 елларда ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саны***




2020 ел дәвамында ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган 772 бала булуы ачыкланды (2019 елга караганда 5,6%ка кимрәк), шуларның 225се генә – ятим балалар (29%).

*34 нче диаграмма*

***2010 – 2020 елларда ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саны (кеше)***




Статистик хисапларны анализлаудан күренгәнчә, 2020 ел дәвамында төрле рәвештәге гаилә тәрбиясенә 555 бала тапшырылган, шулардан:

445 (80,2%) – туганнары опекасына (попечителенә);

71(12,8%) – гаиләләргә асрауга алынган;

39 (7,1%) уллыкка алынган.

2020 елда ачыкланган 772 ятим баланың 72 проценты ел дәвамында төрле рәвештәге гаилә тәрбиясенә урнаштырылган, аларның 39ы уллыкка алынган, 445е опекага бирелгән, 71е гаиләләргә асрауга алынган, 46сы – башлангыч опекага, 35е-ата-аналарга кире кайтарылган.

Статистик хисапларны анализлаудан күренгәнчә, 2020 ел дәвамында барлыгы 741 бала төрле рәвештәге гаилә тәрбиясенә тапшырылган, шулардан:

494 (67 %) – туганнары опекасына (попечительлегенә);

121 (16,4 %) – гаиләләргә асрауга алынган;


69 (9,4 %) уллыкка алынган.

Гаиләгә асрауга тапшырылган балалар арасында бары тик 20 бала гына инвалид статусына ия булган (2019 елда – 21, 2018 елда – 19, 2017 елда – 45, 2016 елда – 39). Аларның өчесе уллыкка алынган, тагын 13е – опекага (попечительлеккә), шул исәптән 4есе баланы асрауга алган гаилә белән килешү буенча тапшырылган.

2021 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында яшәүче ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру диаграммада күрсәтелә.

*35 нче диаграмма*


***2021 елның 1 гыйнварына ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру***




Балаларны урнаштыруның иң киң таралган рәвеше булып, элеккечә үк, ***балаларны туганнары тәрбиясенә тапшыру*** кала. 2021 елның 1 гыйнварына 3 602 опекун гаиләсендә 4 411 бала тәрбияләнде.

*36 нчы диаграмма*

***2011 -2020 елларда опекага (попечительлеккә) алынган балалар саны***





2020 елда ***балаларны асрауга алган гаиләләр*** саны 5%ка кимегән, 2019 елда 1 367 булса, 2020 елда ул 1 292 булган. 2021 елның 1 гыйнварына 1 292 асрауга бала алган гаиләдә 2 370 бала тәрбияләнгән.

Асрауга бала алган 78 гаиләдә (асрауга бала алган гаиләләрнең 6%ы) – 5 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләнгән, 170 гаиләдә (12%) – 3 – 4 бала, 1044 шундый гаиләдә (81%) – 1 – 2 бала тәрбияләнгән.

*37 нче диаграмма*


***2011 – 2020 елларда асрауга бала алган гаиләләрдә тәрбияләнгән балалар саны (кеше)***



2020 елда ***уллыкка алынган балалар*** саны кимү тенденциясе дәвам итә. 2021 елның 1 гыйнварына 2470 гаиләдә 2 632 уллыкка алынган бала тәрбияләнә. Алар арасында 5 уллыкка алынган бала – 2 гаилә, 3 – 4 уллыкка алынган бала – 12 гаилә, 1 – 2 уллыкка алынган бала – 2 456 гаилә бар.

*38 нче диаграмма*


***2010 – 2019 елларда уллыкка алынган (кызлыкка алынган) балалар саны (кеше)***




2020 ел дәвамында 69 бала уллыкка тапшырылган, бу 2019 елга караганда 12 балага кимрәк, 2019 елда 81 бала уллыкка алынган.

*39 нчы диаграмма*


***2011–2020 елларда уллыкка (кызлыкка) алынган балалар саны (кеше)***




Барлык балалар да Россия гражданнары тарафыннан уллыкка алынган.

*40 нчы диаграмма*

***2011–2020 елларда балаларны уллыкка (кызлыкка) алу***




Ел нәтиҗәләре буенча ***ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда*** тәрбияләнүчеләр саны 3,3%ка кимегән (541дән 523гә кадәр), шулардан 2020 ел ахырына кадәр түбәндәге рәвештә тәрбиядә булганнар саны:

сабыйлар йортында – 75 бала (2019 елда – 66);
балалар йортларында – 218 бала (2019 елда – 233);
ятим балалар өчен интернат-мәктәпләрдә – 64 бала (2019 елда – 67);
балалар өчен интернат-йортларда – 166 бала (2019 елда – 175).

Ятим балалар турында ***Төбәк белешмәләр банкында*** 2021 елның 1 гыйнварына ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган 638 бала исәптә тора, бу узган ел белән чагыштырганда 2 кешегә кимрәк (2020 елның 1 гыйнварына – 640).

2020 елда икенче мәртәбә ятимлеккә калуга бәйле хәлләр яхшырды – баланы гаиләгә асрауга бирү турында карарлар гамәлдән чыгарылды: балаларны аларның үз гаиләсен алыштыра торган гаиләгә (в замещающую семью) тапшыру өчтән бергә кимеде. 72 бала «ятим балалар учреждениеләренә» кире кайтарылган. Кире кайтаруның яртысыннан артыгы (40 очрак) асрауга бала алган гаиләләр аркасында булган.

24 очракта карарларны гамәлдән чыгару уллыкка алучыларның, опекуннарның һәм балаларны асрауга алган гаиләләрнең инициативасы буенча булган, шул исәптән асрауга бала алган ата-аналар инициативасы буенча – 16 очрак: Алабуга һәм Мамадыш районнарында – 3әр, Азнакай, Алексеевск һәм Әгерҗе районнарында – 2шәр, Чүпрәле, Биектау, Тәтеш районнарында – берәр очрак.

Шул ук вакытта, 13 карар асрауга бала алган ата-аналарның балаларны тәрбияләү буенча бурычларын тиешенчә үтәмәве сәбәпле кабул ителгән, шул исәптән асрауга бала алган 11 гаиләдә: Нурлат районында – 9, Кайбыч районында – 2 очрак.

Икенчел ятимлек күрсәткечләре югары саклана, аны булдырмас өчен системалы, уйланылган чаралар күрергә кирәк.

2020 елда республиканың опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеге Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең махсус контролендә һәм күзәтүендә тора.

2020 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил республиканың 12 районында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген тикшерде. Тәрбиягә бала алган балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен, шулай ук опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген тәэмин итүдә җитди хокук бозулар ачыкланды, шул исәптән:

Югары Ослан, Теләче, Нурлат муниципаль районнарында гаиләсез калган балаларны тиешенчә исәпкә алмау;

Алабуга, Нурлат, Югары Ослан, Теләче муниципаль районнарында асрауга бала алган ата-аналар тарафыннан торагы булмаган балаларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак белән тәэмин итү өчен исәпкә кую буенча системалы эш алып барылмау;

опекадагы балага беркетелгән торак урынның сакланышын, торак-коммуналь хезмәтләр өчен вакытында түләвен контрольдә тотмау;

***Мисал:*** *Нурлат муниципаль районында Э.Г. Абделманова тәрбиясендәге 2003 елгы М.ның 255 мең сум күләмендә бурычы бар, В.С. Макарова гаиләсендә тәрбиядә торучы 28.03.2003 елгы Ф. 2020 елның 26 февраленә махсуслаштырылган торак алу өчен чиратка куелмаган.*

Теләче, Алабуга, Нурлат муниципаль районнарында опекадагы балаларның акчаларын саклап тотуны тәэмин итмәү (инвалидлык буенча пенсия акчаларын, туендыручысыз калганда билгеләнгән пенсия акчаларын контрольсез алу һәм тоту), балигъ булмаган опекадагы баланың мөлкәтен саклау, аннан файдалану һәм андый мөлкәт белән эш итү турында асрауга бала алган ата-аналарның тиешенчә хисап бирмәве (дөрес булмаган хисап бирүе);

***Мисал:*** *Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге опекага алынган инвалид К.ның счетыннан ай саен пенсия акчаларын һәм башка социаль*

*түләүләрне алырга ел саен рөхсәт биргән, ә акчаларны опекага алынган бала мәнфәгатьләрендә тотуны раслый торган документлар тапшырылмаган; тикшерү вакытында опекага алынган бала счетында 1 033,4 сум акча калган, инвалид бала 2015 елда гаилә тәрбиясенә тапшырылган..*

Нурлат муниципаль районында тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче балигъ булмаганнарның тиешле яшәү һәм тәрбияләү шартларын булдырмау;

Югары Ослан, Теләче муниципаль районнарында тәрбияләнүчеләр мәнфәгатьләрендә алимент түләттерү буенча системалы эш алып барылмау;

Теләче, Югары Ослан муниципаль районнарында дәрестән тыш вакытта өстәмә белем бирү системасында тәрбиягә алынган балаларның мәшгульлеген, ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру мәсьәләләренә тиешле игътибар бирелмәү;

Биектау муниципаль районында опеканы вакытында рәсмиләштермәү.

***Мисал:** 2020 елның 15 апрелендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Л.Н. Нечаевадан 05.04.2011 елгы оныгы Б.ны опекага алуны рәсмиләштерү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгате кабул ителде.*

*Мөрәҗәгать итүче белешмәләренә караганда, Б.ның әнисе 2019 елның 30 октябрендә үлгән, баланың әбисе Л.Н. Нечаева Татарстан Республикасы Биектау районының опека һәм попечительлек бүлегенә баланы опекага алуда ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән. 2020 елның 15 апреленә кадәр опека һәм попечительлек органнары баланы опекага алу буенча тиешле чаралар күрмәгән, гаилә авыр тормыш хәлендә калган, әби балага туендыручысын югалту буенча пенсия рәсмиләштерә алмый, опека һәм попечительлек органнары тарафыннан бу эш шулай ук оештырылмаган. Әлеге факт буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан чаралар күрелде, җитешсезлекләр бетерелде.*

Эш визиты кысаларында ачыкланган хокук бозулар фактлары буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан муниципаль берәмлек башлыгы (башкарма комитет җитәкчесе) белән әлеге проблема турында фикер алышу, әлеге мәсьәләне балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең киңәйтелгән утырышларында карау оештырылды, хокук бозуларга юл куйган муниципаль район башлыклары адресына балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозулар турында бәяләмәләр (9 бәяләмә) җибәрелде, республика (район) прокуратурасы хәбәр ителде.

Шуның белән бергә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне башкарырга кирәк, дип саный:

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә:

муниципаль районда опека һәм попечительлек органының тәрбиягә бала алган ата-аналарның опекунлык бурычларын һәм хокукларын тиешенчә үтәвен, ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, асрауга бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре тәрбиягә бала алган ата-аналар тарафыннан үтәлүен контрольдә тоту буенча вәкаләтләрен тиешенчә үтәү мәсьәләләрен ел саен карарга;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

урыннарда опека һәм попечительлек органнары белгечләренең һөнәри компетенцияләрен күтәрү һәм эшчәнлекне методик яктан тәэмин итү тәҗрибәсен үстерергә, яңа билгеләнгән опека һәм попечительлек органнары хезмәткәрләренә, шул исәптән стажировка мәйданчыклары практикасыннан файдаланып, аерым игътибар бирергә;

контроль чаралар үткәргәндә әлеге категория балигъ булмаганнарның диспансеризациясен вакытында узу, инвалид балаларның реабилитация чараларын тормышка ашыру, ятим балаларны торак алу өчен исәпкә кую мәсьәләләренә аерым игътибар бирергә;

җирле үзидарә органнары белән берлектә:

прокуратура органнарын җәлеп итеп, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу мәсьәләләрен карарга;

ятим балаларны тәрбиягә алган гаиләләрдән аларны кире кайтаруны киметү буенча өстәмә чаралар күрергә, һәр очрак өчен гаиләне саклау буенча юл картасын эшләргә.

### *3.2.3. Баланың гаиләгә хокукын гамәлгә ашыру проблемалары һәм, гаиләдә конфликтлар булганда, гаилә эчендәге бәйләнешләр*

Балаларны тәрбияләү буенча бурычларны һәм хокукларны бүлү аркасында ата-аналар арасындагы бәхәсләрдә балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре соңгы елларда кискен булып кала. Мондый хәлләр, барыннан да элек, ата-аналар аерылышканнан соң һәм аерым яши башлагач барлыкка килә.

Моны бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына кергән мөрәҗәгатьләр саны да раслый.

2020 елда гражданнардан кергән гомуми мөрәҗәгатьләр арасында ***икенче урынны гаиләгә һәм гаилә элементләренә*** балаларның хокукларын яклау мәсьәләләре алып тора.


2020 елда әлеге тематика буенча мөрәҗәгатьләр 2019 елга караганда 29%ка кимрәк булды. Әлеге тематика буенча 389 мөрәҗәгать каралды, бу мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынннан 28 % тәшкил итә.

Шул ук вакытта балаларның гаиләгә һәм гаилә элементләренә хокукларын яклау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасында ***беренче урынны*** (тематика буенча мөрәҗәгатьләрнең 40%ы), гадәттәгечә, ата-аналары аерылышканнан соң балаларны тәрбияләүгә, аерым яшәүче ата-ана яки башка туганнар белән баланың яшәү урынын һәм аралашу тәртибен билгеләүгә, ***бала белән аралашуга каршылыкларны бетерүгә бәйле шикаятьләр*** алып тора.

2020 елда гаилә эчендәге низаглы хәлләрне хәл итүдә ярдәм сорап 154 мөрәҗәгать керде, бу 2019 елга караганда 34%ка кимрәк.

*41 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда балаларның яшәү урырын һәм ата-аналары белән аралашу тәртибен билгеләү мәсьәләләре буенча гражданнар мөрәҗәгате динамикасы***




154 мөрәҗәгать балаларның ата-аналары ***аерылышу йә аерым яшәүләре аркасында*** барлыкка килгән түбәндәге бәхәсле вәзгыятьләрне хәл итүдә ярдәм итүне үтенеп бирелгән:

бала белән аралашуга каршылыкларны бетерү (61%)

аерым яшәүче ата-ана белән баланың аралашу тәртибен билгеләү (18%);
баланың башка туганнары белән аралашу тәртибен билгеләү (10%);
баланың яшәү урынын билгеләү (7%);
ата-аналарның балаларын тоту тәртибен билгеләү (4%).

Һичшиксез, әлеге проблема һәм мәсьәләләрнең катлаулылыгы аерылышу мәсьәләләренә турыдан-туры бәйле. Соңгы елларда аерылышу статистикасы мониторингыннан күренгәнчә, ул өйләнешүчеләрнең яртысын тәшкил итә.

Мәсәлән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе белешмәләренә караганда, 2020 елда 1000 никахка 587 аерылышу туры килгән, бу узган елның шул ук күрсәткеченнән югарырак (2019 елда – 550, 2018 елда – 540 аерылышу).

*42 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда Татарстан Республикасында теркәлгән никахлар һәм аерылышулар динамикасы***




Аерылышу вәзгыятен ел саен ата-аналары белән бергә 10 меңнән артык бала да кичерә. Ата-аналар аерылышуга бәйле рәвештә балаларны тәрбияләүгә кагылышлы бәхәсле мәсьәләләргә карата гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча эш әлеге процессларга җәлеп ителгән балаларның катлаулы мораль-психологик халәттә булуларын күрсәтә һәм психологик ярдәм һәм коррекция таләп итеlә.

Бәхәсне җайга салуның ***медиация*** кебек альтернатив процедурасы, нәкъ менә аерылышуга һәм мөлкәт бүлешүгә бәйле мөнәсәбәтләр өлкәсендә, ир белән хатын арасында, шул исәптән балалар белән аралашу тәртибен билгеләү һәм балаларның эмоциональ тотрыклылыгын саклау мәсьәләләрендә, дөнья килешүенә ирешү мөмкинлеге күзлегеннән караганда, иң нәтиҗәлеләрнең берсе булып тора.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, гаиләне һәм балаларны яклау мәсьәләләре Татарстан Республикасының коммерциячел булмаган секторының да игътибар үзәгендә тора. Граждан җәмгыяте институтларын Татарстан Республикасында коммерциячел булмаган оешмалар, иҗтимагый советлар, профсоюз берләшмәләре, дини оешмалар һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тәшкил итәләр. Татарстан Республикасында 5500 дән артык коммерциячел булмаган оешма теркәлгән. Алар арасында 200гә якын коммерциячел булмаган оешмага уңай караша саклана һәм аларга муниципаль хакимият органнары гаилә һәм демографик сәясәтне гамәлгә ашыру өлкәсендә эшләүчеләр булараk карыйлар, коммерциячел булмаган оешмалар исемлегеннән 95%ы – социаль куркы-

ныч хәлдәге (СОП) һәм авыр тормыш хәлендә (ТЖС) булган гаиләгә (инвалид балалары булган гаиләләр, хокук бозуларны профилактикалау, социаль куркыныч авырулар һ.б.) социаль ярдәм күрсәтүче оешмалар. Шулай итеп, Татарстан Республикасының коммерцияле булмаган оешмаларыннан 5%тан да ким өлеше генә гаилә кризисларын кичергән гаиләләр белән эшли.

«Безнең буын» автоном коммерциягә карамаган оешма (АНО) һәм «Ышаныч» ДБУ тарафыннан ТР Министрлар Кабинетының ЗАГС Идарәсе һәм НКО инициативасы белән тәкъдим ителгән гаиләгә ярдәм итүнең партнерлык программасын гамәлгә ашыру тәҗрибәсе игътибарга лаек. Әлеге программада җәмәгать судьялары хезмәте аша аерылышу процедурасын узган якларга ЗАГС аша медиация процедурасын үткәрү мөмкинлеге турында хәбәр итү каралган. 2020 елда Казанның Идел буе, Киров районнары ЗАГСлары территориясендә «Ышаныч» үзәге хезмәткәрләре тарафыннан 160 кеше өчен 107 медиация һәм конфликтларны хәл итү буенча консультацияләр үткәрелгән. Бу практиканы дәвам итәргә һәм үстерергә кирәк, дип саныйбыз.

Вәзгыятьләр озак вакытлы суд процесслары белән катлаулана, аларга шулай ук балалар да җәлеп ителә.

Татарстан Республикасы Югары суды белешмәләренә караганда, 2020 елда гомуми юрисдикция судларында балаларны тәрбияләүгә бәйле 714 бәхәс каралган, шул исәптән балаларны тәрбияләүгә бәйле:

баланың яшәү урынын билгеләү мәсьәләсе буенча – 231 эш (2019 елда – 263 эш);

аерым яшәүче ата-ана һәм башка туганнар белән аралашу тәртибен билгеләү буенча – 355 эш (2019 елда – 474 эш).

Моннан тыш, суд тарафыннан билгеләнгән ата-аналар бурычларын башкару тәртибе һәрвакытта да ирекле тәртиптә үтәлми. Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белешмәләренә караганда, 2020 елда суд приставлары үтәтүендә:

балаларның яшәү урынын билгеләү турында суд карарларын мәҗбүри үтәтү мәсьәләсе буенча – 15 үтәтү эше; 2020 елда 9 үтәтү эше тәмамланган һәм туктатылган, шуларның 5есе – фактта үтәлү белән тәмамланган;

аерым яшәүче ата-ана һәм башка туганнар белән аралашу тәртибен билгеләү турында суд карарларын мәҗбүри үтәү мәсьәләсе буенча – 310 үтәтү эше, (2019 елда – 293), шулардан 2020 елда 199ы туктатылган, 152се фактта үтәлү белән тәмамланган.

Гаилә мөнәсәбәтләреннән (баланың яшәү урынын һәм баланың аерым яшәүче ата-ана хокукларын гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында; бала белән аралашу тәртибен үзгәртү турында; балигъ булмаган баланы тотуга алиментлар түләтү турында; ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турында, өйләнешеп торганда булдырган мөлкәтне бүлешү турында) барлыкка килә торган бәхәсләр медиация куллану өлкәсе булып тора.

Россия Федерациясе Граждан-процессуаль кодексының 150 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә суд тикшерүенә эшне әзерләгәндә судья яклар тарафыннан, шул исәптән федераль законда билгеләнгән тәртиптә уздыру нәтиҗәләре буенча, медиация процедурасын уздыру буенча чаралар күрә, аңа яклар суд тикшерүенең теләсә кайсы стадиясендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

«Арадашчы катнашында бәхәсләрне җайга салуның альтернатив процедурасы (медиация процедурасы) турында» 2010 елның 27 июлендәге 193-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 4 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, әгәр бәхәс суд яки арадашчы суд карамагына тапшырылган булса, яклар тиешле суд яки арадашчы суд тарафыннан бәхәс буенча карар кабул ителгәнче теләсә кайсы вакытта медиация процедурасын куллана алалар. Судта эшне карауны кичектерү процессуаль законнар белән билгеләнә.

Бу чакта Россия Федерациясе Граждан-процессуаль кодексының 169 статьясындагы 1 өлеше һәм «Бәхәсләрне арадашчы катнашында җайга салуның альтернатив процедурасы (медиация процедурасы) турында» 2010 елның 27 июлендәге 193-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләре нигезендә, медиация процедурасын үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, ике якның да үтенечнамәсе буенча суд эшне тикшерүне 60 көннән дә артмаган вакытка кичектерергә мөмкин. Аерым очракларда, рөхсәт ителә торган бәхәснең катлаулы булуы аркасында һәм медиатор ризалыгы белән суд тарафыннан эшне кичектерү медиация процедурасын үткәрү вакытына – 180 көнгә кадәр озайтылырга мөмкин.

Татарстан Республикасы территориясендә медиация хезмәтләре күрсәтүче һәм бәхәсләрне хәл иткәндә килештерү процедураларын кулланучы оешмаларга түбәндәгеләр керә:

– «Идел буе медиаторлары лигасы» коммерциячел булмаган партнерлык (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Островский ур., 67 йорт; Тел.: +7 (843) 245-23-28; e-mail:liga_mediatorov_povolghya@mail.ru сайт: www.mediators-tatarstan.ru);

– Идел буе хокукый килештерү (медиация) үзәге. В.Г.Тимирясов ис. Казан инновацион университеты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәскәү ур., 42 (корпус 2), Тел.: +7 (843) 231-92-90, 231-92-98, 231-92-85);

– «Идел буе медиаторы» АНО (Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ямашев пр., 10 йорт, 220А офис, Тел. +7 917 393-30-74).

– «Сезнең медиатор» коммерцияле булмаган партнерлык (Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Техник ур., 120а йорт, e-mail: vashmediator@mail.ru сайт: http://vashmediator.com);

– Россия Федерациясе Сәүдә-сәнәгать палатасы каршындагы Халыкара коммерциячел арбитраж суды бүлеге (Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Пушкин ур., 18 йорт, Тел.: +7 (843) 238-61-04, 236-06-27, e-mail: mkas.kazan@tpprf.ru lex@tpprf.ru);

– Мирсадыйкова Гөлия Рәмис кызы, «Паритет» профессиональ медиаторларың милли ассоциациясе әгъзасы (420087, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Даурия ур., 22 йорт, 105 офис; тел. +7 (916) 661-07-45, e-mail: lawyer@domino116.ru; инстаграм: @gulia_ramisovna).

Шул ук вакытта конфликтны хәл итүдә якларга ярдәм итәчәк оешманы сайлап алу хокукына һичшиксез бәхәстә катнашучылар үзләре ия була, алар Татарстан Республикасы территориясендә генә түгел, ә Россия Федерациясенең теләсә кайсы башка субъектында килештерү эшчәнлеген башкаручы затка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Шуңа бәйле рәвештә, ата-аналарга аларның медиация хезмәтләреннән файдалану мөмкинлекләре турында мәгълүмат җиткерелергә тиеш.

Гражданнарның суд карарларын үтәмәүгә бәйле мөрәҗәгатьләре ешайды. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау еш кына аларның барлыкка килгән вәзгыятьне хәл итүдә закон инструментларын белмәвен күрсәтә. Шул ук вакытта опека һәм попечительлек органнары вәзгыятьне хәл итүдә һәрвакыт ярдәм итәргә әзер булмыйлар.

Закон көченә кергән суд карары катгый рәвештә үтәлергә тиеш. Ихтыярый үтәүдән баш тарткан очракта, суд карары мәҗбүри үтәтелә.

Суд карарларын мәҗбүри үтәтү вәкаләтләре Федераль суд приставларының хезмәтенә һәм аның территориаль органнарына йөкләнгән.

Федераль суд приставлары хезмәте, аның территориаль бүлекчәләре федераль башкарма хакимият органы булып торалар һәм аның карарларына яки гамәлләренә (гамәл

кылмауларына) шикаятьләрне карау Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил компетенциясенә керми.

«Үтәтү эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге № 229-ФЗ Федераль закон нигезендә, суд приставының-үтәтүченең законлы таләпләре барлык дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, гражданнар һәм оешмалар өчен мәҗбүри һәм Россия Федерациясенең бөтен территориясендә катгый үтәлергә тиеш.

Бүгенге көндә гамәлдәге закон кысаларында суд карарын үтәргә мөмкинлек бирә торган билгеле бер механизм бар.

Суд приставының-үтәтүченең законлы таләпләрен үтәмәгән очракта, ул федераль законнарда каралган чараларны куллана. Суд приставының-үтәтүченең законлы таләпләрен үтәмәү, шулай ук суд актларын, башка органнар һәм вазыйфаи затлар актларын үтәү буенча функцияләрне суд приставы-үтәтүче тарафыннан гамәлгә ашыруга комачаулау административ һәм җинаять җаваплылыгына китерә.

Суд приставының-үтәтүченең үтәтү документын үтәү буенча гамәлләре (гамәл кылмаулары) гражданнар тарафыннан өлкән суд приставына буйсыну тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин яисә судка дәгъва белдерелергә мөмкин.

Моннан тыш, суд приставлары үз функцияләрен гамәлгә ашырганда закон үтәлешен «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» Федераль закон нигезендә прокуратура органнары күзәтеп торалар. Шуннан чыгып, граждан, суд приставлары гамәл кылмаган очракта, үтәтү эше алып бару урыны буенча район (шәһәр) прокурорына, югарырак прокурорга тиешле гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Суд карарын үтәү өчен суд приставы-үтәтүче үтәү гамәлләрен башкаруда катнашырга тиешле белгечне, шул исәптән педагогны, психологны, опека органы хезмәткәрен җәлеп итәргә мөмкин.

Суд карары буенча үтәтү документы нигезләмәләрен үтәү мөмкин булмаган очракта, әйтик, бала әнисе белән бергә яшәүдән катгый рәвештә баш тарткан очракта, әтисе белән калырга тели һәм хәтта әнисе янына килүдән баш тарткан очракта, бу фактны опека һәм попечительлек органнары, психолог катнашында, суд приставлары хезмәте терки.

Алга таба суд приставы-үтәтүче, яңа ачылган шартларны исәпкә алып, аны үтәү ысуллары һәм тәртибе турында гариза белән судка мөрәҗәгать итә.

Шул ук вакытта граждан яңадан ачылган шартлар буенча судка дәгъва бирә ала.

Шулай ук, суд эшчәнлегендә катнашучылар беренче һәм апелляция инстанцияләре судлары тарафыннан кабул ителгән суд актларының үтәлешен туктатып тору үтенече белән законнар нигезендә кассация инстанциясенә мөрәҗәгать итә алалар. Нәтиҗәдә, ата-аналарның берсе файдалана ала торган үтәтү гамәлләре туктатыла.

Шуңа бәйле рәвештә кассация инстанциясе суды суд актын үтәүне туктатып тору яки суд актын үтәүне туктатудан баш тарту турында билгеләмә чыгара. Суд актын үтәү нәтиҗәсендә, әгәр суд тарафыннан суд тарафыннан суд тарафыннан суд актын үтәүне туктатып торуның башка вакыты билгеләнмәгән булса, кассацион шикаятьне, күрсәтмәне карау нәтиҗәләре буенча суд тарафыннан карар кабул ителгәнчегә кадәр туктатыла.

Шуңа бәйле рәвештә, кассация инстанциясе суды суд актын үтәтүне туктатып тору яки суд актын үтәтүне туктатудан баш тарту турында билгеләмә чыгара. Суд актын үтәтү нәтиҗәсендә, әгәр суд тарафыннан суд актын үтәтүне туктатып торуның башка вакыты билгеләнмәгән булса, кассацион шикаятьне, күрсәтмәне карау нәтиҗәләре буенча суд тарафыннан карар кабул ителгәнчегә кадәр туктатыла.

***Балигъ булмаган балалар тәрбияләнә торган чит ил гражданнары белән никахларын өзү***, чит дәүләт территориясенә чыгарылган яки тотыла торган балаларны кире

кайтару, балигъ булмаганнарга карата тиз арада яклау чаралары күрү, чит ил судлары карарларын тану һәм үтәү мәсьәләләренә бәйле гражданнар мөрәҗәгатьләре аерым игътибар үзәгендә кала.

Әлеге мәсьәләләрне хокукый җайга салуның үзенчәлеге шунда, аларның хокукый регламенты Россия Федерациясенең милли законнары белән дә, түбәндәге халыкара хокук нормалары белән дә гамәлгә ашырыла:

1980 елның 25 октябрендәге Балаларны халыкара урлауның граждани-хокукый аспектлары турында конвенция;

1996 елның 19 октябрендәге ата-ана җаваплылыгына карата юрисдикция, кулланыла торган хокук, тану, үтәү, хезмәттәшлек һәм балаларны яклау чаралары турында конвенция һәм ире яки хатыны, йә баласы кайсы илнең гражданы булса, шул илнең милли законнары.

Һәр конкрет очракта илләрнең милли законнарының хокукый нормалары һәм халыкара хокук нормалары индивидуаль эшли. Конфликт барлыкка килгән очракта, хокукый җайга салуның катлаулылыгы катнаш илләр гражданнары белән өйләнешеп торучы ир белән хатынны һәм аларның балаларын авыр хәлгә куя.

2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә юридик консультацияләр һәм бәхәсле вәзгыятьләрне хәл итү буенча ярдәм сорап, Украина, Үзбәкстан, Төркия гражданнары мөрәҗәгать итте.

Баланы чит илгә чыгару срокларына бәйле мәсьәләләрне карау үзенчәлеген исәпкә алып, гражданнарга үз вакытында ярдәм күрсәтү һәм аларга консультация бирү максатыннан опека һәм попечительлек органнары адресына балалары чит ил территориясенә чыгарылган яки анда тотылып калган ата-аналарга ярдәм күрсәтү буенча белешмәлекләр җибәрелде.

Мәсьәләнең социаль әһәмиятен һәм проблеманың кискенлеген исәпкә алып, әлеге тематика буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау практикасын гомумиләштерүдән, шулай ук 2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашкан суд практикасыннан чыгып, түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк, дип саныйм:

Татарстан Республикасы Югары судына, район һәм җәмәгать судлары белән берлектә, гаилә мөнәсәбәтләреннән килеп чыккан бәхәсләрне караганда, суд эшчәнлегендә катнашучыларга медиация процедурасын үткәрү турында карарлар кабул итү мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү тәҗрибәсен киңәйтергә (баланың яшәү урынын һәм баланың аерым яшәүче ата-ана хокукларын гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында; бала белән аралашу тәртибен үзгәртү турында; балигъ булмаган баланы тотуга алиментлар түләтү турында; ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турында, өйләнешеп, бергә торган вакытта тупланган мөлкәтне бүлешү турында);

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика һәм муниципаль комиссияләргә:

баланы аерым яшәүче атасы йә анасы һәм якын туганнары белән аралашу хокукыннан мәхрүм иткән ата-аналарны Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләре нигезендә административ җаваплылыкка тарту практикасын дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

опека һәм попечительлек органнары хезмәткәрләренең балаларны тәрбияләү мәсьәләләре буенча ата-аналар бәхәсендә балалар мәнфәгатьләрендәге проблемалы вәзгыятьләрне хәл итүгә, ата-аналары аерым яшәгәндә балалар белән аралашу тәртибен билгеләүгә һәм балалары чит ил территориясенә чыгарылган йә анда тотылып калган

ата-аналарга ярдәм итү буенча эшләрне оештыруга бәйле мәсьәләләр буенча һөнәри компетенцияләрен арттырырга;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына:

Татарстан Республикасы НКО тарафыннан гамәлгә ашырыла торган партнерлык программаларын үстерү, норматив кризисны кичерүче һәм аның чишелешен аерылышу аша хәл итә торган гаиләләргә ярдәм итү эшен Татарстан Республикасы буенча ЗАГС Идарәсе белән берлектә дәвам итәргә;

опека һәм попечительлек органнарына:

ике якның да ризалыгы белән бала белән аралашу тәртибен билгеләү турындагы мәсьәләләрне балигъ булмаганнар мәнфәгатьләрендә караганда, медиация технологияләрен куллануны (медиация процедурасын үткәрүне) тәкъдим итәргә, ата-аналарга судка кадәр медиация процедурасын узу турында карарлар кабул итү мөмкинлеге турында мәгълүмат бирергә.

## 3.3. Социаль тәэмин итү хокукын үтәү

2021 елда балаларны социаль тәэмин итү мәсьәләләре Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына кергән мөрәҗәгатьләр саны буенча өченче урында тора. Әлеге тематика буенча 371 мөрәҗәгать керде, бу Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына кергән мөрәҗәгатьләрнең 21%ын тәшкил итә.

2019 ел белән чагыштырганда бу өлкәдәге мөрәҗәгатьләр саны 158гә яки 74%ка артты (2019 елда 213 мөрәҗәгать булган иде).

*Диаграмма*




Яңа короновирус инфекциясе буенча эпидемиологик вәзгыятьне, Россия Федерациясе территориясендә махсус эпидемиологик режимның гамәлдә булуын исәпкә алып, федераль һәм төбәк дәрәҗәләрендә балалы гаиләләргә ярдәм итү максатларында берничә норматив акт чыгарылды.

«Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2020 елның 20 мартындагы 199 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, 2020 елның 1 гыйнварыннан, балалы гаиләләрнең керемнәрен арттыру максатларында, Россия Феде-

рациясе субъектлары законнарында каралган тәртиптә һәм шартларда бирелә торган өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләнде.

Россия Федерациясе Президентының әлеге Указының 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасында билгеләнгән аерым таләпләр буенча балалы гаиләләр айлык түләү алу өчен ярдәмгә мохтаҗ дип таныла. Әлеге таләпләр «Өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 апрелендәге 267 номерлы карары белән расланды, аның нигезендә гаиләдә җан башына керем Татарстан Республикасында әлеге түләүне алу өчен мөрәҗәгать иткән ел алдындагы елның II кварталы өчен билгеләнгән җан башына яшәү минимумы күләменнән артмаган, шулай ук гаиләнең (гражданның) мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән дәрәҗәдән түбән булган гаиләләргә өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балалары өчен айлык акчалата түләү билгеләнде.

Күрсәтелгән түләүне билгеләгәндә гаиләләрнең мөлкәти тәэмин ителешенә карата таләпләр билгеләү хокукы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру тәртибенә төп таләпләрне, күрсәтелгән айлык түләүне билгеләү өчен кирәкле документларның (белешмәләрнең) якынча исемлеген һәм аны билгеләү турында гаризаның үрнәк формасын раслау турында» 2020 елның 31 мартындагы 384 номерлы карары белән дә билгеләнде.

Нәтиҗәдә, 2020 елда төрле социаль түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибе мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр саны артты.

Әлеге мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүчеләрдән 210 гариза керде, бу 2019 ел белән чагыштырганда ике тапкырга диярлек күбрәк (2019 елда – 114). 70 мөрәҗәгать арасында федераль, төбәк һәм муниципаль бюджетлар акчалары исәбенә бирелә торган социаль түләүләрне үз вакытында алу (күчерү) хокукларын үтәүгә бәйле иде:

32 мөрәҗәгать түләү тәртибен һәм кагыйдәләрен аңлатуны сорап язылган иде

6 мөрәҗәгать балалары аерым яшәүче ата-аналары тарафыннан пособие алу һәм аларны балигъ булмаган балалар мәнфәгатьләрендә тотмауга бәйле иде;

11 мөрәҗәгать балалы гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүнең яшь категориясен 16 яшьтән 18 яшькә кадәр биткерү мәсьәләсенә кагылышлы иде;

21 мөрәҗәгать, мөрәҗәгать итүчеләр фикеренчә, социаль яклау органнары тарафыннан пособиеләрне хаксыз рәвештә түләмәүгә бәйле иде.

***Мисал:*** *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына балигъ булмаган О.ның әнисе Чаллы шәһәренең халыкны социаль яклау бүлеге тарафыннан баласына махсус сөт ризыгы бирүгә каршылык күрсәтелүгә бәйле мөрәҗәгать керде, янәсе гаиләнең торак мәйданы 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән күләмнән артып китә.*

*Башка шундый ук мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып, балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүне яхшырту максатларында, Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин адресына өч яшькә кадәрге балаларга табиблар рецептлары буенча махсус туклану продуктлары һәм катнашмалары биргәндә гаиләнең мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсе турындагы нигезләмәне төшереп калдыру турындагы мәсьәләне карау хакында хат җибәрелде.*

*Әлеге инициативаны хуплау йөзеннән, Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин адресына Татарстан Республикасы Икътисад һәм социаль тикшеренүләр үзәгеннән һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгыннан уңай фикерләр алынды.*

Инвалид балаларны техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча 6 мөрәҗәгать керде, шифаханә-курортта дәвалануны тәэмин итү буенча – 4 мөрәҗәгать, бу гомуми мөрәҗәгатьләрнең 13%ын тәшкил итте (2019 елда – 16%).

Реабилитация чараларын гамәлгә ашыруга, реабилитацияләүнең техник чараларын сатып алуга һәм реабилитация чараларының федераль исемлегендә каралган хезмәт күрсәтүләргә федераль бюджет акчалары исәбеннән дәүләт гарантиясе «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы белән билгеләнә. Әлеге хокукны гамәлгә ашыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 7 апрелендәге 240 номерлы карары белән расланган Инвалидларны реабилитацияләүнең техник чаралары һәм ветераннар арасыннан булган аерым категория гражданнарны протезлар (теш протезларыннан тыш), протез-ортопед эшләнмәләре белән тәэмин итү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) белән регламентланган.

Реабилитацияләүнең техник чаралары составы 2005 елның 30 мартындагы 2347-р номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән билгеләнгән, шул ук карар белән инвалидка бирелә торган реабилитация чараларының, техник реабилитацияләү чараларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең федераль исемлеге дә расланган. Инвалид балаларны техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү федераль дәүләт медик-социаль экспертизалау учреждениеләре тарафыннан эшләнә торган һәм тиешле дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук барлык оештыру-хокукый һәм милек рәвешләрендәге оешмалар тарафыннан мәҗбүри гамәлгә ашырыла торган инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Кагыйдәләрнең 5 пунктында, инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны техник реабилитацияләү чаралары белән тәэмин итүгә вәкаләтле орган, техник реабилитация чарасы бирү турында гариза алынган көннән 15 көн эчендә инвалидка техник чара (эшләнмә) белән тәэмин итү буенча исәпкә куелуы турында хәбәр итә һәм бер үк вакытта техник чара (эшләнмә) алуга йә әзерләүгә сайлап алынган оешмаларга юллама (алга таба – юллама) җибәрә, дип билгеләнгән.

Шуның белән бергә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан мөрәҗәгатьләрне карау барышында балигъ булмаганнарның түбәндәге хокукларын бозу очраклары ачыкланды: инвалид баланың индивидуаль реабилитация (абилитация) программасында каралган кирәкле тернәкләндерү чарасы белән тәэмин ителмәве, индивидуаль реабилитация (абилитация) программаларына туры килми торган карап тоту чаралары белән тәэмин итү, техник реабилитацияләү чаралары һәм инвалидларны карау өчен кирәкле чаралар белән тәэмин итүченең үз йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәве.

***Мисал:*** *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына балигъ булмаган бала М.ның әнисеннән техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать килде. Әлеге мөрәҗәгатьне карау барышында инвалид бала М.ның башны һәм гәүдәне тоту өчен өстәмә фиксацияле, кул белән йөртелә торган кресло-коляска белән тәэмин итүгә, шул исәптән ДЦП белән авыручы баланы урамга һавага алып чыгу өчен җиңел коляска белән (утыргыч тирәнлеге – 40 см) тәэмин итүгә Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлегенең 9 нчы филиалында 2019 елның 21 октябрендәге 669.38.16/2019 номерлы ИПР нигезендә 2019 елның 27 ноябреннән бирле исәптә торуы билгеләнде.*

*Инвалид бала С.ның әнисе мөрәҗәгатен тикшерү барышында төзелгән дәүләт контракты кысаларында 2020 елда балага Ника-04 бүлмә моделендәге кресло-коляска тәкъдим ителүе ачыкланды. ИПР тарафыннан эшләнгән техник характеристикалар нигезендә, ДЦП белән*

*авыручылар өчен кресло-коляскалар утыргычның тирәнлеге 40 см булырга тиеш, контракт нәтиҗәләре буенча инвалид балага тәкъдим ителгән коляскада утыргыч тирәнлеге 290 – 350 мм диапазонда гына көйләнә.Нәтиҗәдә, тәкъдим ителгән кресло-коляска инвалид баланың законлы вәкилен канәгатьләндерми һәм ана кеше ул коляскадан баш тарткан.*
*Инвалид балага башка кресло-коляска тәкъдим ителмәгән.*

Калган өлештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итүчеләрнең һәр мөрәҗәгатендә инвалид балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылуның каралуын исәпкә алып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ФСС идарәчесе адресына балигъ булмаганнарның шәхси тернәкләндерү чаралары һәм аларга тәрбия бирү-карау чаралары белән тәэмин ителүгә хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында 2 бәяләмә җибәрде, аларда балигъ булмаганнарның индивидуаль реабилитацияләү программасында каралган таләпләргә туры килә торган техник реабилитацияләү чаралары һәм тәрбия бирү-карау чаралары белән тулы күләмдә тәэмин ителүен оештырырга кирәклеге турында һәм алга таба инвалид балаларны кирәкле техник тернәкләндерү чаралары һәм тәрбия бирү-карау чаралары белән тәэмин итүнең билгеләнгән тәртибен бозуга юл куймауга юнәлдерелгән чаралар күрелергә тиешлеге турында күрсәтмәләр бирелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына мөрәҗәгать итүчеләрнең барысын да реабилитацияләүнең техник чаралары белән тәэмин итү мәсьәләләре ахыргача хәл ителгәнче контрольдә кала.

Инвалид балаларны подгузниклар белән тәэмин итү мәсьәләсе дә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибар үзәнедә булды.

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Техник реабилитацияләү чараларын, протезларны һәм протез-ортопед эшләнмәләрне алыштыру срокларын раслау турында» 2018 елның 1 февралендәге 85н номерлы боерыгы (алга таба – Россия Хезмәт министрлыгының №85н боерыгы) белән техник реабилитацияләү чараларыннан, протезлардан һәм протез-ортопед эшләнмәләрдән аларны алыштырганчыга кадәр файдалану сроклары билгеләнгән.

Бу боерыкка 2020 елның 14 октябрендә кертелгән үзгәрешләр нигезендә, подгузниклардан файдалану вакыты 8 сәгатьтән дә артык була алмый (полиурия синдромы белән – 5 сәгатьтән артык түгел), шул исәптән 0 яшьтән алып 3 яшькә кадәрге балалар өчен – 8 сәгатьтән артык түгел, 4 яшьтән 7 яшькә кадәр – 6 сәгатьтән, 8 яшьтән 18 яшькә кадәр – 5 сәгатьтән артык түгел.

Шулай итеп, кертелгән үзгәрешләр белән инвалид балаларның ата-аналары тарафыннан белдерелгән проблемаларның бер өлеше хәл ителде.

Шуның белән бергә, 2020 елда мөрәҗәгать итүчеләр бирелә торган подгузникларның сыйфатына һәм үлчәмнәренә кагылышлы мәсьәләләрне күтәрәләр (каптырмаларының сыйфаты начар булу, сыеклыкны үткәрү сыйфатының начар булуы), шулай ук яшүсмер балалар өчен үлчәмнәр челтәрен киңәйтүне сорыйлар.

Әлеге проблема шуннан килеп чыга, боерык нигезендә балалар подгузникларының сыеклык үткәрүчәнлегенә таләпләр куелмый, ә үлчәмнәр рәте баланың авырлыгы буенча билгеләнә (подгузниклар 5 килога кадәр, 6 килога кадәр, 9 килога кадәр, 20 килога кадәр, 20 килодан артык авырлыкта булган балалар өчен чыгарыла). Сыеклык үткәрүчәнлеккә таләпләр куелмау алар белән тәэмин итүчеләргә сыеклыкны начар сеңдерә торган һәм начар тота торган (түбән абсорбцияле) подгузниклар таратырга мөмкинлек калдыра, нәтиҗәдә, бала мондый подгузникта үзен начар хис итә.

Россия Хезмәт министрлыгының № 85н боерыгы белән балалар өчен 5 төр подгузник каралган, подгузникларның соңгы үлчәме авырлыгы 20 килодан артык булган бала-

лар өчен каралган. Ә аннан соңгы төре – «Өлкәннәр өчен подгузниклар, үлчәме – «XS» (бил әйләнәсе/бот үлчәме 60 см-га кадәр)», нәтиҗәдә, яшүсмер-балалар үзләренә тиешле үлчәмдәге подгузниклар белән тәэмин ителмиләр, бу аларга шулай ук тискәре тәэсир итә.

Сыеклыкны сеңдерү өлешендәге вәзгыятьне анализлаудан күренгәнчә, сыелыкның начар үткәрүчәнлеге Техник җайга салу һәм метрология федераль агентлыгының 28.11.2011 елның 28 ноябрендәге № 625-с боерыгы белән расланган 2012 елның 1 мартындагы Р52557-2011 ГОСТы (алга таба – ГОСТ) буенча әзерләнмәгән подгузникларга хас булуы ачыкланды.

Россия Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 16 декабрендәге 913 номерлы боерыгы нигезендә инвалидларга күрсәтелә торган тернәкләндерү чараларының, реабилитацияләүнең техник чараларының һәм хезмәтләрнең федераль исемлеге кысаларында техник чараларны (эшләнмәләрне) классификацияләүне актуальләштерү буенча һәм инвалидларга күрсәтелә торган тернәкләндерү чараларының, реабилитацияләүнең техник чараларының һәм хезмәтләрнең федераль исемлеген киңәйтү турындагы тәкъдимнәрне карау буенча Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы комиссиясе төзелде (алга таба – Комиссия).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министры А.О. Котяковка Россия Хезмәт министрлыгының № 85н боерыгына инвалид балаларга бирелә торган подгузникларның югарыда күрсәтелгән ГОСТка туры китерү турындагы таләпләрне кертү һәм яшүсмер балалар өчен подгузникларның үлчәм челтәрен киңәйтү мәсьәләсен карау үтенече белән мөрәҗәгать итте.

Шуңа бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча идарәсе инвалид балаларның ата-аналары белән инвалид балаларны дәвалау һәм реабилитацияләү өчен яңа эшләнмәләре нигезендә кирәкле техник реабилитацияләү чаралары исемлеген булдыру эшен оештырырга тиеш, дип саныйм, аннары бу исемлекне техник чаралар классификациясен киңәйтү тәкъдимнәре белән күрсәтелгән Комиссиягә җибәрергә тәкъдим итәм.

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча идарәсе биргән белешмәләрдән күренгәнчә, 2020 елда техник реабилитацияләү чаралары белән тәэмин ителгән инвалид балалар саны 2021 елның 1 гыйнварына 1 837 иде, техник реабилитацияләү чаралары һәм тәрбия бирү-карау чаралары белән тәэмин итүгә мохтаҗ балалар саны 4 946 кеше иде. Техник реабилитацияләү чаралары өчен компенсация алу хокукыннан 2 081 кеше файдаланган. Шулай итеп, 2020 елда инвалид балаларны техник реабилитацияләү чаралары һәм тәрбия бирү-карау чаралары белән тәэмин итү 79% булган; 1 028 инвалид бала кирәкле техник чаралар белән тәэмин ителми калган.

Инвалид балаларны тернәкләндерүнең тагын бер кискен мәсьәләсе – аларны ***шифаханә-курортта дәвалануга юлламалар белән тәэмин итү***.

Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе биргән белешмәләрдән күренгәнчә, 2020 ел башына 3 976 инвалид бала шифаханә-курортта дәвалануга мохтаҗлар исәбендә булган. Ел ахырына мондый балалар саны 3 764 булган. Ел дәвамында нибары 428 юллама (2019 елда 1068 юллама) бирелгән.

Инвалид балаларны шифаханә-курортта дәвалау белән тәэмин итү «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль хезмәт күрсәтүләр җыелмасы кысаларында гамәлгә ашырыла һәм ул Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2004 елның 29 декабрендәге 328 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарның аерым

категорияләренә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе белән регламентланган. 2020 елда шифаханә-курортта дәвалануга юлламалар бирү буенча федераль вәкаләтләрне Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча идарәсе чыгымнар нормалары, дәүләт сатып алулары турындагы законнар нигезендә, федераль бюджеттан әлеге максатларга бүлеп бирелгән акчалар күләме кысаларында гамәлгә ашыра. Финанслау социаль хезмәт күрсәтүләре җыелмасы бәясеннән гамәлгә ашырыла.

Сыйфатлы шифаханә-курортта дәвалануны тәэмин итү проблемасы бүген дә саклanып кала. Кызганычка каршы, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә, федераль финанслауның җитәрлек булмавы аркасында, конкурслар процедуралары югары сыйфатка түгел, ә түбәнрәк бәяләр принцибына нигезләнә, бу исә бүген илнең иң яхшы һәм алдынгы шифаханә-курорт учреждениеләренә юлламалар сатып алырга мөмкинлек бирми.

Югарыда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, инвалид балаларга ел саен шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар бирү проблемасы кискен кала. Шуны истә тотып, Татарстанда булган балаларны ял иттерү һәм сәламәтләндерүнең республика программасын активрак кулланырга кирәк, дип саныйм. Бу уңайдан түбәндәгеләрне тәкъдим итәм:

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, инвалид балаларны профильле сменаларга кертү буенча инклюзив практиканы киңәйтергә;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына инвалид балаларның ата-аналарына «Ана һәм бала» юлламалары алу мөмкинлеге турында аңлату эшләре алып барырга.

### *3.4. Баланың торак, башка мөлкәти хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү*

2020 елда ***балаларның торак хокукларын*** тормышка ашыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрнең киму тенденциясе күзәтелә. 2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 282 мөрәҗәгать керде, бу барлык мөрәҗәгатьләрнең 16%ын тәшкил итә (2019 елда – 335 мөрәҗәгать, 17%).

*Диаграмма*

***2020 елда балаларның торак хокукларын яклау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрнең тематикасы структурасы***



Югарыда бирелгән күрсәткечләргә, аерым алганда, гаилә белән балалар мәнфәгатьләрендә торак сәясәтен гамәлгә ашыру буенча барлык дәүләт органнарының үзара хезмәттәшлеге барышында эшләнгән үтемле механизмнар нәтиҗәсендә ирешелде. Шундый механизмнарның берсе – торак белән тәэмин итү формасы – беренче һәм икенче бала туган өчен ана (гаилә) капиталы бирү; 2019 елның 1 гыйнварыннан соң һәм 2022 елның 31 декабренә кадәр өченче һәм аннан соңгы балалары туган гаиләләргә торак ипотекасы кредитын (заемын) каплау өчен федераль бюджеттан 450 мең сум күләмендә торак субсидиясе бирү.

Балаларның торак һәм башка мөлкәт хокукларын тәэмин итү вәзгыятенә анализ әлеге бүлектә балалы гаиләләрнең социаль якланмаган төп категорияләре буенча бирелде:

ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын үтәү;

күп балалы гаиләләрнең торак хокукларын үтәү;

инвалид балалары булган гаиләләрнең торак хокукларын үтәү;

балигъ булмаган балаларга карата алимент йөкләмәләрен үтәтү.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән гражданнарның балаларның торак хокукларын гамәлгә ашыруга кагылышлы мәсьәләләре күбесенчә консультация алу характерында иде.

### *3.4.1. Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын үтәү*

Ятим балаларның торак хокукларын яклау Россия Федерациясе дәүләт социаль сәясәтенең мөһим юнәлешләренең берсе булып тора.

«Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» Федераль законның 8 статьясы нигезендә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итүгә өстәмә гарантияләр Россия Федерациясе субъектының чыгым йөкләмәләренә керә.

Республикада ятим балаларны торак белән тәэмин итү вәкаләтләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары өлешендә гамәлгә ашыруны ***финанслау күләме*** ел саен арта.

Шуны әйтергә кирәк, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан бу мәсьәләгә зур игътибар бирелә. 2020 елда ятим балалар өчен торак төзүгә бүлеп бирелгән акчалар күләме 794, 707,1 мең сум тәшкил итте, бу 2019 ел белән чагыштырганда 2,5 тапкыр күбрәк (328 501 мең сум).)

Ятим балалар өчен торак төзелешен федераль финанслау 2020 елда шулай ук артты һәм 46 000,9 мең сум тәшкил итте.

*13 нче таблица*

***2012 – 2020 елларда ятим балаларны торак белән тәэмин итү***

| Ел | ТР бюджеты акчалары күләме, мең сум | Федераль бюджет акчалары күләме, мең сум | Гомуми акчалар күләме, мең сум | Торак урыннары алган ятим балалар саны |
|---|---|---|---|---|
| **2012** | 112 996,0 | 50 529,3 | 163 525,3 | 179 |
| **2013** | 173 942,2 | 72 086,4 | 246 028,6 | 265 |
| **2014** | 233 730,0 | 83 410,0 | 317 140,0 | 309 |
| **2015** | 269 811,0 | 86 610,4 | 356 421,4 | 331 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **2016** | 288 697,8 | 50 485,0 | 339 182,8 | 311 |
| **2017** | 302 840,0 | 43 880,0 | 346 720,0 | 305 |
| **2018** | 314 957,8 | 40 328,4 | 355 286,2 | 297 |
| **2019** | 328 501,0 | 44 730,9 | 373 231,9 | 309 |
| **2020** | 794 707,1 | 46 000,9 | 840 708 | 600 |
| **Барысы** | **2 820 182,9** | **518 061,3** | **2 655 931,4** | **2 906** |

Шулай итеп, 2020 елда ятим балалар өчен торак төзелешенә бүлеп бирелгән акчаларның гомуми күләме 840 708 мең сум тәшкил итте.

Күрсәтелгән акчалар кысаларында 2020 елда 600 кеше торак белән тәэмин ителгән.

Татарстан Республикасында ятим балаларны исемлеккә кертү, аларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары белән тәэмин итү буенча күрелә торган чаралар социаль яктан аз якланган аерым гражданнар категориясен торак белән тәэмин итү өлешендәге проблеманың кискенлеген киметүгә юнәлдерелгән.

Шулай итеп, Татарстан Республикасында ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга һәм алар арасыннан чыккан 23 яшькә җиткән затларга торак урыннары бирү буенча, күрсәтелгән затлар категориясен торак белән тәэмин итүдә җыелган бурычны 2025 елга кадәр бетерүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 27 июлендәге 626 номерлы карары белән расланган чаралар (Ярдәмче программа – «Татарстан Республикасында ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак урыннары белән тәэмин итү») нигезендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру 2022 ел йомгаклары буенча түбәндәгеләрне эшләргә мөмкинлек бирәчәк:

Реализация мероприятий вышеуказанной подпрограммы позволит по итогам 2022 года:

1800 ятим баланы һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар категориясенә кергән һәм 23 яшькә җиткән затларны торак урыннар белән тәэмин итәргә;

ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган затларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган һәм махсус торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителгән 23 яшькә җиткән затларның гомуми мохтаҗлар арасындагы өлешен 100 процентка кадәр арттырырга.

Шуның белән бергә, барлыкка килгән вәзгыятькә һәм бәйле процессларның динамикасына анализдан күренгәнчә, күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын финанслау арта барган ихтыяждан калыша. Торак белән тәэмин итү хокукын гамәлгә ашыру вакыты җиткән ятим балаларның гомуми санын, шулай ук бер квадрат метрның уртача базар бәясе артып торуын исәпкә алганда, финанслауга бүгенге ихтыяҗ 1,2 млрд. сумнан

да ким түгел, шул ук вакытта әлеге исемлеккә кертелүче гражданнар саны тотрыклы рәвештә арта бара.

Халыкның иң социаль якланмаган катламнарының берсен торак белән вакытында тәэмин итмәү аларның конституциячел хокукларын кысрыклауга китерә, тормышка җайлашмау хисен тудыра, бу категория гражданнарда агрессия тудыра, социаль хезмәтләр күрсәтү процессында һәм башка социаль ярдәм алганда кыенлыклар барлыкка китерә.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү буенча республика чыгым йөкләмәләрен финанслауны арттыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә кирәк, дип саныйбыз.

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак урыннары белән тәэмин итү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 29 июлендәге 267-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә опека һәм попечительлек органнары ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны исемлеккә кертү буенча законлы вәкилләре тарафыннан вакытында гаризалар тапшыруны контрольдә тоталар һәм, *мондый гаризалар тапшырылмаган очракта, әлеге балаларны исемлеккә кертү буенча чаралар күрәләр.* Законда билгеләнгән тәртиптә мондый тану бала 14 яшькә җиткәч гамәлгә ашырыла.

Шул ук вакытта, ***ятим балаларны торак исәбенә вакытында кую*** проблемасы актуаль булып кала.

2020 елда ятим балаларның законлы вәкилләренең (тәрбиягә бала алган ата-аналар, опекуннарның) баланы торак белән тәэмин итүгә мохтаҗ дип тану турындагы документларны үз вакытында тапшырмау фактлары Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан берничә тапкыр ачыкланды.

Республиканың Нурлат, Югары Ослан, Теләче муниципаль районнарында опека һәм попечительлек органнары тарафыннан торак исәбенә вакытында куймау очраклары билгеләнде.

***Мәсәлән,*** *Нурлат муниципаль районында Ш.гаиләсендә тәрбиягә алынган 2003 елгы бала Ф. 2020 елның 26 февраленә махсуслаштырылган торак алу өчен чиратка куелмаган. Шундый ук хәл Татарстан Республикасының башка районнарында да күзәтелә.*

Алабуга муниципаль районында Колесниковлар гаиләсендә 2004 һәм 2005 елгы ике бала тәрбиягә алынган, махсус торак алу өчен чиратка куелмаганнар. Шевченко гаиләсендә тәрбиягә алынган 2005 елгы бала Ш. махсус торак алу өчен чиратка куелган.

Шулай ук беркетелгән торакның сакланышы һәм торак-коммуналь хезмәтләргә түләү бурычларын контрольдә тоту буенча тәрбиягә бала алган ата-аналар белән нәтиҗәле эш юк.

***Мәсәлән***, *Нурлат муниципаль районында тәрбиягә алган бала Х. гаиләсендә опекадагы 2003 елгы Р.га беркетелгән торакта ТКХ өчен түләү буенча 255 мең сум күләмендә бурыч җыелган.*

Барлык хокук бозу фактлары буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балигъ булмаганнарның торак-коммуналь хокукларын яклауга тәэсир итү буенча тиешле чаралар күрелде.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балигъ булмаган опекадагы балаларның милек хокукларын бозуларны кисәтү һәм алар карамагындагы мөлкәтнең сакланышын тәэмин итү максатыннан, Республикада Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

ятим балалар белән эшләү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы буларак, **Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына,** ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итүнең вакытында башкарылуын контрольдә тотуны көчәйтергә;

**опека һәм попечительлек органнарына** 14 яше тулган ятим балаларны үз вакытында торак исәбенә куюны тәэмин итәргә;

**опека һәм попечительлек органнарына** ятим балага беркетелгән торак урынының сакланышы, шул исәптән торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертүне системалы рәвештә тикшереп торырга һәм балада булган торакны саклау һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурыч булдырмау өчен вакытында тиешле чаралар күрергә.

### *3.4.2. Күпбалалы гаиләләрнең торак хокукларын үтәү*

2030 елга кадәр Россия гражданнарын арзан һәм уңайлы торак белән тәэмин итү өлешендә өстенлекле бурычлар халыкның торак алу мөмкинлеген арттырудан гыйбарәт.

Бигрәк тә күпбалалы гаиләләр арасында торакка мохтаҗлык сизелә, еш кына алар матди кыенлыклар аркасында торак сатып ала алмыйлар.

Татарстан Республикасында күпбалалаы гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуга өстәмә ярдәм күрсәтү Татарстан Республикасы Президентының «Күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшырту буенча өстәмә чаралар турында» 2001 елның 17 мартындагы ПУ-216 номерлы Указы нигезендә ата-анасы белән торучы, үз гаиләсен кормаган биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләргә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән ***торак урын сатып алу өчен субсидияләр бирү*** юлы белән башкарыла.

Торак урын сатып алу өчен субсидияләр алу хокукы сертификат белән таныклана, сертификатлар бирү һәм алардан файдалану «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү һәм алардан файдалану кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртибендә гамәлгә ашырыла.

2020 елда «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә 211 892,6 мең сум күләмендә акча юнәлдерелде. Бүлеп бирелгән акчалар кысаларында узган елда 46 сертификат бирелгән.

*Таблица*

***2016 – 2020 елларда биш һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрне торак сертификатлары белән тәэмин итү***

| Ел | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары күләме (мең сум) | Җыелма исемлек буенча гаиләләр саны | Балалар үз гаиләләрен булдыру сәбәпле сертификат алу хокукын югалткан гаиләләр саны | Сертификат–алган гаиләләр саны |
|---|---|---|---|---|
| **2016** | 137 068,2 | 793 | 3 | 42 |
| **2017** | 143 784,5 | 723 | 19 | 50 |
| **2018** | 149 380,8 | 597 | 1 | 46 |
| **2019** | 155 965,9 | 560 | 2 | 33 |
| **2020** | 211 892,6 | 600 | 0 | 46 |

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белешмәләренә караганда, 2020 елда торак сертификатын алу буенча җыелма исемлектә биш һәм аннан да күбрәк баласы булган 600 гаилә булган. Бүлеп бирелә торган финанслау күләме җыелма исемлектә торучы гаиләләрнең 8%ын гына торак сертификатлары белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирде. Мондый шартларда торак сертификатын алу чираты килеп җитүнең уртача чоры 9 -10 ел тәшкил итәчәк.

Кызганычка каршы, шундый озак көтү чорында күп кенә биш һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләр күпбалалы гаилә статусын югалталар, димәк, торак сертификатын алу хокукы юкка чыга. Торак сертификатын көтү чорында балаларның үз гаиләләре дә барлыкка килергә мөмкин һәм, нәтиҗәдә, балаларның үз гаиләләре барлыкка килү сәбәпле, гаиләне исемлектән төшереп калдыралар.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил моңа кадәр дә билгеләп үткән иде инде, мондый вәзгыять күпбалалы гаиләләргә лаеклы яшәү шартларын тәэмин итүгә, аларны социаль яклау дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән әлеге дәүләт ярдәме чарасының хокукый мәгънәсен юкка чыгара.

Күпбалалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең, шул исәптән торак шартларын яхшырту өчен каралган дәүләт ярдәменең тагын бер чарасы – ***түләүсез җир кишәрлекләре бирү.***

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белешмәләре буенча, 2020 елда күпбалалы гаиләләрне түләүсез җир кишәрлекләре алучылар исемлегенә кертү турында 60 583 карар кабул ителгән. Гомуми өлешле милеккә 38 523 җир кишәрлеге бирелгән, гомумән алганда, республикада исемлекләргә кертү турында кабул ителгән карарлар саныннан 64% тәшкил итә.

Күрсәтелгән белешмәләрне анализлаудан күренгәнчә, республикада буш җир кишәрлекләре җитмәү проблемасы бар, әлеге проблема бигрәк тә Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Зеленодольск шәһәрләрендә кискен тора. Узган ел исемлеккә кертелгән, әмма җир кишәрлекләре алалмаган күпбалалы гаиләләр саны арткан.

Кайбер районнарда җир кишәрлекләре бирү өстәмә җир кишәрлекләре эзләү һәм ызанлау процедурасы үткәрүгә бәйле рәвештә туктатылды.

Күпбалалы гаиләләр өчен өстәмә җир кишәрлекләре булдыру эшләрен финанслау мәсьәләсе дә катлаулы кала.

Муниципаль районнар белешмәләре буенча, программаны гамәлгә ашыру кысаларында кайбер аеруча актуаль проблемалар билгеләнде:

– булган җир кишәрлекләре чикләрен киңәйтү өчен кирәкле шартлар булмау (магистраль торбаүткәргечләрнең саклана торган зоналары, газүткәргечләр, электр линияләре һ. б.);

– күпбалалы гаиләләрнең бирелә торган җир кишәрлегеннән түбәндәге сәбәпләр аркасында баш тартуы:

урынын ошатмыйча, тәкъдим ителгән җир кишәрлекләре белән килешмәү;

инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктура булмау.

### *3.4.3. Инвалид балалары булган гаиләләрнең торак хокукларын үтәү*

Инвалид балалары булган гаиләләрнең торак шартларын яхшырту мәсьәләсе күп гаиләләр өчен актуаль булып тора.

Россия Федерациясе Торак кодексы белән гаиләдә бер фатирда бергә яшәгәндә куркыныч тудыра торган хроник авыруның авыр төре белән авыручыны торак урыннарына мохтаҗ буларак тану һәм исәпкә алу турындагы мәсьәлә җайга салынды. Әлеге затның

Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган аерым федераль исемлеккә кертелгән авыруы булу шундый хәл дип таныла. Шундый очракта, мөрәҗәгать итүче торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алына, шуннан соң социаль наем шартнамәсе буенча торак Россия Федерациясе Торак кодексының 57 статьясындагы 2 өлеше нигезендә чираттан тыш бирелә, әгәр Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясында билгеләнгән таләпләр (соцнайм шартнамәсе буенча башка торак урыны яисә милек хокукында торагы булмау һ.б.) мөрәҗәгать итүчегә карата үтәлгән булса.

Инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итүнең Россия Федерациясе Торак кодексында беркетелгән кагыйдәләре, әгәр инвалид баласы булган гаилә торак урыны алуга мохтаҗ буларак 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә куелган булса, кулланыла. Инвалид баласы булган гаилә торак урыны алуга мохтаҗ буларак 2005 елның 1 гыйнварына кадәр исәпкә куелган очракта, гаиләне торак белән тәэмин итү мәсьәләсе «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 28.2 статьясы нигезләмәләре нигезендә җайга салына.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль Законның 17 статьясы нигезендә Россия Федерациясе законнарында һәм Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган тәртиптә исәпкә куелалар һәм торак белән тәэмин ителәләр.

2005 елның 1 гыйнварына кадәр исәпкә куелган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ инвалидларны һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү федераль бюджет акчалары исәбеннән Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасында әлеге тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган һәм югарыда күрсәтелгән гражданнарга Федераль компенсацияләр фондыннан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак сатып алуга субсидияләр бирүне күздә тота.

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2020 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән торак шартларын яхшыртуга субсидияләр алучыларның (инвалидларның) җыелма исемлегенә инвалид балалары булган 9 гаилә кертелгән. Узган елда шушы категориядәге бер гаилә дә торак алуга федераль субсидия алу хокукын гамәлгә ашырмаган.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына еллык субвенцияләр күләме инвалид балалары булган гаиләләрнең Россия Федерациясе законнары белән гарантияләнгән дәүләт ярдәмен нәтиҗәле тәэмин итәргә мөмкинлек бирми.

Шулай ук Татарстан Республикасында 2014 елдан башлап, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 29.11.2012 ел, № 987н боерыгы белән расланган исемлектә социаль торак фондыннан яллау шартнамәсе буенча торак урыны алуга мохтаҗ дип күрсәтелгән һәм 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан гражданнар бергә бергә бер фатирда яшәү хәтәрлек тудыра торган хроник авыруларның авыр төрләре белән авыручы инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләргә торак урыны алу өчен ***төбәк торак субсидиясен бирү*** (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) турында норма кертелде («Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясы, алга таба – 63-ТРЗ номерлы Закон).

«2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы

нигезендә 63-ТРЗ номерлы Законның 8.2 статьясында билгеләнгән аерым категория гражданнарны торак белән тәэмин итүгә 2020 елда 50 000 мең сум күләмендә акча бүленде. 2021 һәм 2022 елларда да шундый ук сумма бирү күздә тотыла.

2020 ел дәвамында хроник авыруларның авыр төрләре белән авыручы инвалид балалары булган 12 гаиләгә 18 611,42 мең сум күләмендә торак субсидияләре (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр) бирелгән.

Суд карарлары нигезендә 2020 елда субсидия түләнмәгән.

### *3.4.4. Балигъ булмаганнарның башка мөлкәти хокукларын яклау*


2020 елда мөрәҗәгатьләр саны буенча бишенче урында лаеклы тормыш рәвешенә хокук белән бәйле мәсьәләләр булы – 159 мөрәҗәгать (9%). Мондый мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны узган ел белән чагыштырганда 28,2%ка арткан. Традицион рәвештә бу ата-аналарның балаларны карап тоту буенча бурычларын тиешенчә үтәмәүгә бәйле мәсьәләләр, шул исәптән алимент йөкләмәләрен үтәмәү, милек мәсьәләләрен хәл итү, ата-аналар үлеме нәтиҗәсендә балаларның мирас мәсьәләләре буенча шикаятьләр.

2020 елда гражданнардан алимент түләүдән качып йөрүче ата-аналарга һәм суд приставларына-башкаручыларга карата 95 шикаять килде (бу тема буенча кергән мөрәҗәгатьләрнең 60%ы), бу 2019 елдагыга караганда 20%ка кимрәк (2019 елда – 118 мөрәҗәгать).

2020 елда балигъ булмаган балаларны карап тоту өчен алиментлар түләтү турында суд карарлары үтәлмәү сәбәпле, 16 247 җинаять эше кузгатылган. Республика суд приставларының территориаль бүлекләрендә ел дәвамында мәҗбүри үтәлергә тиешле барлыгы 32 265 башкарма эш булды.

*59 нчы диаграмма*

***2016 – 2020 елларда балигъ булмаган балаларны тәрбияләүгә мәҗбүри рәвештә алиментлар түләтү буенча суд карарларын үтәүнең торышы***




Балаларны тәэмин итү өчен алиментлар түләтү турындагы суд карарлары үтәлмәвенең төп сәбәпләреннән берсе, барыннан да элек, аларның ата-аналарның үзләре тарафыннан үтәлмәвенә бәйле. Күп кенә «алиментчылар» балаларын тәэмин итүгә акча түләп тору гына түгел, хәтта яшәү һәм эшләү урыннарын да яшерәләр. Алимент йөкләмәләре буенча эзләү игълан ителгән бурычлылар саны 2020 елда 1843 кеше булды, бу 2019 елдагыга караганда 65%ка кимрәк.

Узган елда башкарма эшләр турындагы законнарны бозган өчен 2 770 бурычлы-«алиментчы» административ җаваплылыкка җәлеп ителгән, Россия Федерациясеннән чы-

гып китүне вакытлыча чикләү турында 18 714 карар, алимент түләргә тиешле бурычлының файдалану хокукын вакытлыча чикләү турында 709 карар кабул ителгән.

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тикшереүчеләре тарафыннан 2020 елда 898 җинаять эше кузгатылган.

Шуның белән бергә, балигъ булмаганнар файдасына алиментлар буенча бурычлар суммасы шактый кала һәм кызыксынган барлык ведомстволарга һәм учреждениеләргә бу түләүләрне түләттергәндә балигъ булмаганнарның хокукларын яклау эшен дәвам итәргә кирәк.

2018 елда ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган һәм республика гаиләләренә тәрбиягә алынган балаларга алимент түләтү мәсьәләсе Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым игътибарында булды.

Тәрбиягә бала алган ата-аналар тарафыннан балаларның алиментка хокукларын гамәлгә ашыру буенча бурычларын тиешенчә үтәмәвенә һәм опека һәм попечительлек органнары ягыннан мәсьәләнең торышын тикшереп торуны оештыруга Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан җентекле анализ ясалды. Эш визиты барышында Югары Ослан, Теләче муниципаль районнарында тәрбиягә бала алган балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен, шулай ук опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген тәэмин итүдә закон бозу очраклары ачыкланды, шуңа бәйле рәвештә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан тиешле тәэсир итү чаралары күрелде.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен балалар йортларында һәм интернат-мәктәпләрдә тәрбияләнүчеләр арасында алимент алучылар буенча квартал саен мониторинг оештырылды. 2011 елдан алимент алучылар буенча башкарма документларның керүенә Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсенең территориаль бүлекчәләре тарафыннан 2011 елдан башлап квартал саен тикшерү үткәрелә.

Муниципаль районнардан бирелгән мәгълүмат мониторингы алиментлар алучылар буенча күрсәткечнең кайсы районнарда югары, уртача һәм түбән булуын ачыкларга ярдәм итте:

югары дәрәҗә (75%тан артык) – 7 районда (Апас, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Сарман, Спас, Бөгелмә);

уртача дәрәҗә (36% – 74%) – 23 районда ( Әгерҗе, Аксубай, Алексеевск, Актаныш, Арча, Әлмәт, Баулы, Балтач, Буа, Алабуга, Зәй, Лениногорск, Кайбыч, Кукмара, Лаеш, Мамадыш, Минзәлә, Яңа Чишмә, Нурлат, Балык Бистәсе, Саба, Тукай, Чистай);

түбән дәрәҗә (0% – 35 %) – 15 районда (Азнакай, Әлки, Әтнә, Зеленодольск, Кама Тамагы, Менделеевск, Мөслим, Түбән Кама, Питрәч, Тәтеш, Теләче, Чирмешән, Ютазы, Чаллы, Казан).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне тәкъдим итүне максатка ярашлы дип саный:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәге чараларны дәвам итәргә:

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен балалар йортларында һәм мәктәп-интернатларда тәрбияләнүчеләр арасында алимент алучылар буенча квартал саен, Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе белән берлектә, мониторинг оештыру буенча;

гаиләгә һәм балаларга социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт учреждениеләре тарафыннан балигъ булмаган балаларга алиментларны рәсмиләштерү һәм вакытында түләтү мәсьәләләрендә социаль хезмәт күрсәтүләрне алучыларга ярдәм күрсәтергә;

опека һәм попечительлек органнарына:

тәрбиягә бала алган ата-аналарның (опекуннарның) балигъ булмаган балаларның мөлкәтен саклау, куллану һәм мондый мөлкәт белән идарә итү турындагы хисапларын кабул иткәндә опекага алынган балаларның ата-аналарыннан алимент алу хокукларын үтәүне тәэмин итүгә аерым игътибар бирергә,

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсенең территориаль бүлекчәләре белән берлектә, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар арасында алимент алучылар буенча башкарма документларның керүен тикшерергә.

## 3.5. Баланың сәламәтлеген саклауга һәм сәламәт үсешкә хокукын үтәү

Баланың сәламәтлеге – аның тормышы һәрьяктан камил булуның төп нигезе. Үсеп килүче буынның сәламәтлеген саклауга, аның сәламәт үсешенә сәламәтлек саклау өлкәсендәге, шул исәптән балаларга күрсәтелә торган медицина хезмәтләренең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итүне, аның сыйфатын күтәрүне һәм төрләрен киңәйтүне, балаларга медицина ярдәме күрсәтүнең заманча тәртипләре һәм стандартлары нигезендә нәтиҗәле оештыруны һәм медицина технологияләрен гамәлгә кертүне, балаларны дару препаратлары, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары, медицина эшләнмәләре белән тәэмин итүне, балигъ булмаган балаларга хезмәт күрсәтүче наркология хезмәтен үстерүне, балаларны сыйфатлы ризык белән тәэмин итү системасын камилләштерүне, балалар һәм яшүсмерләрнең җәйге ял итү һәм сәламәтләндерү системасын үстерүне, мәгариф учреждениеләренең балаларның сәламәтлеген саклау эшчәнлеген үстерүне күздә торган ***заманча технологияләр ярдәмгә килә.***

### *3.5.1. Балалар сәламәтлеге торышына гомуми анализ*


Һичшиксез, балаларның сәламәтлеген саклауга хокукларын тәэмин итү торышын характерлый торган мөһим күрсәткечләрнең берсе – ***балалар үлеме*** дәрәҗәсе.

Әлеге бүлектә тәкъдим ителгән анализлау нигезен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының башлангыч белешмәләре тәшкил итә.

Татарстан Республикасында 2020 елда балалар арасында үлүчеләр саны 1 000 кешегә 0,35 тәшкил итте. 2020 елда 292 бала вафат булды, бу 2019 елга караганда 78 балага кимрәк.

*46 нчы диаграмма*


***2009–2020 елларда Татарстан Республикасында балалар үлеме (кеше)***




Балалар үлеме структурасы түбәндәге диаграммада бирелә.

*47 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда балалар үлеменең яшь буенча бүленеше (кеше)***





Әлеге диаграмма анализыннан күренгәнчә, соңгы дүрт елда республикада сабыйлар үлеме (1 яшькә кадәрге балалар) санының кимүе күзәтелә. Сабыйлар үлеменең кимүендә, бигрәк тә туганнан соң беренче атналарда, бала тудыруга ярдәм итү хезмәтләре эшчәнлеген камилләштерү һәм аларны кадрлар белән тәэмин итү мөһим роль уйный.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, бала тудыруга ярдәм итү хезмәтләре эшчәнлеген камилләштерү буенча, сәламәтлек саклау учреждениеләрен яңа туган балаларны реанимацияләү ятаклары һәм кирәкле белгечләр белән тәэмин итү дәрәҗәсен норматив таләпләргә туры китерү буенча эшне дәвам итәргә кирәк, дип саныйбыз.

Ел саен үткәрелә торган ***профилактик тикшерүләрнең*** нәтиҗәләре балалар сәламәтлеге торышының билгеле бер индикаторы булып тора. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, мондый тикшерүләрнең нәтиҗәләре балаларның сәламәтлеге торышын сәламәтлек төркемнәре буенча бүлүне түбәндәгечә башкарырга мөмкинлек бирде.

*48 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда сәламәтлек төркемнәре буенча балигъ булмаганнарның сәламәтлек торышы***




Балалар сәламәтлеген характерлый торган мөһим критерийларның берсе -***балалар авырулары***. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм Татарстан Республикасы буенча Медик-социаль экспертиза Баш бюросының (алга таба – МСЭ) опе-

ратив күрсәткечләре буенча соңгы биш елда динамикада беренче тапкыр ачыкланган балалар авыруларына анализ түбәндәге таблицада күрсәтелде.

*27 нче таблица*

***2016 –2020 елларда беренче мәртәбә ачыкланган балалар авырулары***

| 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2019 елга карата % | Беренче мәртәбә ачыкланган авырулар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 100447 | 100937 | 105697 | 114508 | 97024 | -15,3% | Имгәнүләр, агуланулар һәм тышкы сәбәпләрдән килгән кайбер башка зыяннар |
| 25865 | 24065 | 24128 | 26111 | 25554 | -2,1% | Нерв системасы авырулары |
| 3012 | 2 802 | 2 279 | 2439 | 2012 | -17,5% | Психик авырулар |
| 107 | 128 | 113 | 112 | 99 | -11,6% | Шешләр (яман шеш авырулары) |
| 26 | 34 | 46 | 94 | 42 | -55,3% | Сирәк очрый торган (орфан) авырулар |
| 7 | 9 | 4 | 3 | 5 | +66,6% | Менингокок инфекциясе |
| 13 | 18 | 19 | 10 | 14 | +40% | Гонококок инфекциясе |
| 44 | 26 | 24 | 17 | 16 | -5,8% | Трихомоноз |
| 11 | 8 | 8 | 8 | 1 | -87,5% | Сифилис (барлык рәвешләре) |
| 12 | 10 | 12 | 11 | 8 | -27,2% | ВИЧ (барлык рәвешләре) |
| 75 | 46 | 40 | 29 | 31 | +6,9% | Вируслы гепатит |
| 67 | 41 | 33 | 37 | 33 | -10,8% | Туберкулез (актив рәвеше) |
| 255 | 210 | 163 | 198 | 187 | -5,5% | Корчаңгы |
| 1207 | 901 | 1063 | 1178 | 776 | -34,1% | Педикулез (бетләнү) |
| 34 | 17 | 6 | 19 | 4 | -78,9% | Бактериаль дизентерия |

Соңгы дүрт елда имгәнүләр, агуланулар һәм башка кайбер тышкы сәбәпләр аркасында балаларның авыру очраклары ачыклану белән бергә, 2020 елда бу 2019 елдагыдан 17 484 очракка кимегән.

Нерв системасы авырулары белән авыручылар саны шулай ук аз гына кимегән һәм ул 25 554 очрак тәшкил итте.

Балалар арасында психик авырулар белән авыручылар саны бераз кимегән (427 очракка). Шулай да, вәзгыять, элеккечә үк, киеренке кала: 2 012 авыру очрагы ачыкланды.

Яман шеш авырулары белән авыручылар саны да бераз кимегән – 13 кешегә, 2019 елда 112 булган, 2020 елда – 99 кеше.

2020 елда 42 балада сирәк (орфан) авыруы ачыкланган.

Узган чорда социаль әһәмияткә ия авырулар өлкәсендә түбәндәге үзгәрешләр булды: корчаңгы белән беренче тапкыр чирләүчеләр саны (35 кешегә) артты, туберкулезның актив рәвеше (4 кешегә) артты, трихомоноз белән беренче тапкыр авыручылар кимеде (7 кешегә), гонокококк инфекциясе белән – (9 кешегә), ВИЧ белән (1 кешегә) авыручылар саны кимеде.

Балаларның ***наркоманиягә һәм алкогольгә бәйлелеге*** даими контрольдә булырга һәм игътибар үзәгендә калырга тиеш.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләренә караганда, наркологик ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ балалар санының кимүе күзәтелә. 2020 елда ул 189 кеше булды, бу 2019 елга караганда 67 кешегә кимрәк. Наркология ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ балалар проценты бер ел эчендә элеккеге дәрәҗәдә калган һәм ул 71% тәшкил итә.

*28 нче таблица*


***2015 – 2019 елларда балигъ булмаганнарга наркология ярдәме күрсәтүнең торышы***

| Күрсәткеч | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Наркология ярдәменә мохтаж балалар саны | 437 | 359 | 288 | 256 | 189 |
| Наркология ярдәме күрсәтелә торган балалар саны | 301 | 247 | 201 | 180 | 136 |
| Балигъ булмаганнарга наркология ярдәме күрсәтү оештырылган медицина оешмалары саны, шул исәптән: | 34 | 32 | 30 | 30 | 30 |
| амбулатор | 34 | 32 | 30 | 30 | 30 |
| стационар | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Балалар наркологлары (кеше /% тәэмин ителеш) | 21/46% | 32/68% | 32/65% | 31/65% | 32/68% |

Балалар сәламәтлеге торышын бәяләү критерийларыннан берсе – ***балалар инвалидлыгы дәрәҗәсе.***

*49 нчы диаграмма*

***2016 – 2020 елларда Татарстан Республикасында инвалид балаларның гомуми саны***





Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге дәүләт учреждениесе белешмәләренә караганда, республикада инвалид балаларның гомуми саны 2021 елның 1 гыйнварына 15 915 бала тәшкил иттте, ягъни балалар халкының гомуми санынннан 1,88%, бу элеккеге дәрәҗәдә диярлек калган булуын күрсәтә.

МСЭның Баш бюросы белешмәләренә караганда, 2020 елда инвалидлыкны билгеләү өчен таныкланган балигъ булмаганнар саны арткан: 5 519 балигъ булмаган бала тикшерелгән, бу 2019 ел белән чагыштырганда 8% ка яисә 406 кешегә күбрәк (2019 елда – 5113 бала). Шуларның 5412есе инвалид дип танылган, ягъни инвалидлык билгеләү өчен тикшерелгән балаларның 98 проценты.

*50 нче диаграмма*


***2016 – 2020 елларда балаларга инвалидлык билгеләү (билгеләүне кире кагу) турында белешмәләр***




Инвалидлык бирү кире кагылган 107 очракның 29 очрагы шул мәсьәлә буенча кабат мөрәҗәгать иткәндә «инвалид бала» тулы реабилитация узган булуга бәйле булган (2015 елда – 770, 2016 елда – 540, 2017 елда – 235, 2018 елда – 237, 2019 елда – 214). 2020 елда мондый кире кагулар өлеше барлык кире кагуларның гомуми санынннан 27% тәшкил иткән.

*51 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда балаларга инвалидлык билгеләүне кире кагу турында белешмәләр***





Инвалидлык билгеләүне кире кагу турындагы 107 карарның 39ы (37%) югары инстанцияләргә – МСЭның Баш бюросына яки «Федераль медик-социаль экспертиза бюросы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә шикаять бирелгән. 30 очракта (28%) карарлар үзгәрешсез калдырылган.

Инвалид дип танылган балаларның гомуми санынннан 1 689 балага (31%) «инвалид бала» категориясе – беренче тапкыр, 3 723 балага (68%) кабат таныклау уздырылган. Беренчел тикшерү вакытында инвалид дип танылган балалар саны 2019 ел белән чагыштырганда 126га (7%) кимегән.

*52 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда балалар инвалидлыгы күрсәткечләре***




2020 елда балалар арасында беренчел инвалидлык дәрәҗәсе 1,7%ка артты һәм 10 000 балага 20,0 очрак булды. 2020 елда кабат инвалидлык дәрәҗәсе дә артты һәм 10 000 балага 44,1 очрак булды.


2020 елда инвалидлыкны билгеләү өчен таныкланган балалар санының артуы күзәтелә. Шул ук вакытта беренчел инвалидлык (31 %) һәм баланы кабат (68%) инвалид дип тануның, шулай ук шикаять белдерелгән һәм инвалидлык билгеләүне кире кагу турындагы карарларның үзгәрешсез калдырылуы 2019 ел дәрәҗәсендә диярлек калган (2019 елда шикаять белдерү – 40% һәм кире кагу – 60%).

Беренче мәртәбә инвалид булып танылган вәзгыять аерым анализлауны таләп итә.

Республиканың муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча беренче мәртәбә бирелгән инвалидлык торышы диаграммада күрсәтелде.

*53 нче диаграмма*

***2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча балаларның беренче тапкыр инвалид дип танылу дәрәҗәсе (10000 балага)***



Бу күрсәткеч Югары Ослан (28,5), Лаеш (28,5), Әгерҗе (26,0), Кукмара (25,6), Тукай (25,3), Биектау (24,9), Чистай (24,0) муниципаль районнарында республика күрсәткечләреннән югары.

2020 елда балалар арасында беренче мәртәбә инвалидлык бирелү югары дәрәҗәдә булу (Татарстан Республикасы буенча уртача статистик күрсәткечтән шактый артып киткән) Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль районнарында күзәтелә:

Мөслим районында – 35,6 (2019 елда – 42,3; 2018 елда – 24,1);

Кама Тамагы районында – 35,1 (2019 елда – 49,5; 2018 елда – 37,2);

Әтнә районында – 34,3 (2019 елда – 16,9; 2018 елда – 25,6);


Спас районында – 31,2 (2019 елда – 24,4; 2018 елда – 18,4);

Яңа Чишмә районында – 30,1 (2019 елда – 18,2; 2018 елда – 21,3).

Беренче мәртәбә инвалид дип танылган балаларның яшь структурасы түбәндәгечә бирелде:

*54 нче диаграмма*

***2016–2020 елларда балаларны яшь категорияләре буенча беренче мәртәбә таныклау белешмәләре***





Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән күренгәнчә, беренче мәртәбә инвалидлык билгеләүнең күп өлешен иң кече яшьтәге – 0 яшьтән 3 яшькә кадәрге балалар тәшкил итә.

2020 елда балаларга беренче мәртәбә инвалидлык бирү өчен сәбәп булган авырулар структурасына анализ түбәндәге диаграммада күрсәтелде.

*55 нче диаграмма*

***2020 елда балаларгаа беренче мәртәбә инвалидлык бирүнең авыру төрләре структурасы***




2016 – 2020 елларда балаларга авырулар төрләре буенча беренче мәртәбә инвалидлык бирү динамикасы түбәндәге таблицада бирелде.

*29 нчы таблица*

***2016 – 2020 елларда балаларга авырулар төрләре буенча беренче мәртәбә инвалидлык бирү сәбәпләренең структурасы (кеше)***

| Сәбәпләр | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Психик тайпылышлар һәм үз-үзләрен тотудагы үзгәрешләр | 471 | 439 | 550 | 580 | 519 |
| Нерв системасы авырулары | 312 | 324 | 316 | 289 | 280 |
| Тумыштан килгән аномалияләр (үсештәге кимчелекләр), деформацияләр һәм хромосомаларның бозылуы | 198 | 276 | 267 | 296 | 249 |
| Эндокрин система авырулары, туклану һәм матдәләр алмашы бозылу | 167 | 146 | 201 | 195 | 187 |
| Сөяк-мускул һәм тоташтыргыч тукымалар авырулары | 53 | 82 | 86 | 95 | 100 |
| Яман шешләр | 83 | 94 | 97 | 97 | 93 |
| Колак-ишетү авырулары | 69 | 65 | 69 | 51 | 54 |
| Күз һәм күрү аппараты авырулары | 71 | 71 | 78 | 47 | 38 |
| Имгәнүләр, агуланулар һәм тышкы башка сәбәпләр | 25 | 20 | 18 | 16 | 22 |
| Ашказаны органнары авырулары | 12 | 18 | 25 | 27 | 18 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Кан әйләнеше системасы авырулары | 15 | 17 | 27 | 20 | 18 |
| Сидек юллары системаы авырулары | 26 | 13 | 21 | 18 | 19 |
| Перинаталь чорда барлыкка килә торган халәт | 16 | 29 | 33 | 14 | 17 |
| Сулыш органнары авырулары | 8 | 6 | 9 | 6 | 7 |
| Туберкулез | 2 | 0 | 0 | 1 | 2 |
| ВИЧ | | | 0 | 5 | 3 |
| Башка авырулар | 39 | 42 | 53 | 58 | 63 |
| **Барысы** | **1567** | **1642** | **1 850** | **1 815** | **1689** |

Балаларга беренче мәртәбә инвалидлык куюга китерә торган сәбәпләрнең иң еш очрый торганы – балалардагы психик тайпылышлар һәм үз-үзләрен тотудагы үзгәрешләр. Беренче мәртәбә инвалидлык бирү буенча гомуми структурада аларның өлеше югары дәрәҗәдә кала. Узган чорда ул 31% яки 519 кеше булган иде, бу 2019 ел белән чагыштырганда 61 кешегә кимрәк.

Икенче урында нерв системасы авырулары тора, аларның беренчел гомуми инвалидлык структурасындагы өлеше 17% тәшкил итә. Әлеге класс буенча инвалид дип танылган балалар саны – 280, бу 2019 ел белән чагыштырганда 9 кешегә кимрәк.

2020 елда өченче урында тумыштан булган аномалияләр (үсештәге кимчелекләре), деформацияләр һәм хромосомнарның бозылу очраклары тора. Беренчел инвалидлыкның гомуми структурасында аларның өлеше 15 % (249 кеше) тәшкил итә.

Дүртенче урында – эндокрин система авырулары, туклануның бозылуы һәм матдәләр алмашы бозылу (187 кеше, 11%).

Төп авыруларның кимеп барганда, беренчел инвалидлыкка китергән сөяк-мускул системасы һәм тукыма авыруларының артуы күзәтелә.

2020 елда балалар авыруларына һәм балалар инвалидлыгына бәйле вәзгыятьне анализлау бүгенге көндә республикада түбәндәге мәсьәләләрнең актуаль булуын күрсәтә:

балалар һәм яшүсмерләр арасында, шул исәптән гомуми белем бирү оешмалары шартларында, медицина белән тәэмин итүнең, авыруларны һәм инвалидлыкны профилактикалауның нәтиҗәлелеген арттыру;

балалар инвалидлыгын профилактикалау, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны, инвалид балаларны комплекслы реабилитацияләү һәм абилитацияләү, шул исәптән балалар инвалидлыгы куркынычын булдырмый торган нәтиҗәле механизмнарны эшләү һәм гамәлгә кертү;

төп кыйммәт буларак, гаилә сәламәтлегенең культурасын булдыру, шул исәптән авыруларны профилактикалау, үз-үзеңне тоту стереотипларына төзәтмәләр кертү, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен булдыру мәсьәләләре буенча ата-аналарны (законлы вәкилләрне) агарту.

### *3.5.2. Балаларның сәламәтлеккә хокукларын тәэмин итүнең проблемалы аерым мәсьәләләре*

2020 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына ***инвалид балаларны дарулар белән тәэмин итү*** мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр килү дәвам итте.

Мөрәҗәгатьләрнең күпчелек өлеше ***гомер озынлыгына тәэсир итә торган яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авыруларыннан интегүче балаларны дарулар белән тиешенчә тәэмин итмәүгә кагылышлы*** мәсьәләләр буенча иде.

Мөрәҗәгатьләрнең иң күбесе арка-мускул атрофиясе (СМА) кебек сирәк орфан чиреннән интегүче балаларның ата-аналарыннан килде, аларда Татарстан Нусинерсен (Спинраза) дару препараты белән тәэмин итү буенча Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләнгән суд карарларының үтәлмәве турында язылган.

«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 44 статьясы нигезендә арка-мускул атрофиясе (СМА) авыруы сирәк (орфан) авыруларга керә һәм 2019 елның 9 сентябренә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән.

«Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге № 178-ФЗ Федераль закон белән социаль хезмәтләр җыелмасын алу хокукы бирелгән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 12 октябрендәге №2406-р күрсәтмәсе белән расланган исемлек кысаларында табиб рецептлары буенча кирәкле дарулар белән өстәмә тәэмин итү гарантияләнгән гражданнар категорияләре билгеләнде (2 нче кушымта).

Спинраз (Нусинерсен) дару препараты әлеге исемлеккә кертелмәгән. Бер үк вакытта дару препаратының бәясе якынча 7 850 мең сум тәшкил итә. Спинраз препаратының бер флаконының бәясе якынча 7 850 сум тора. Бер баланы дәвалауның еллык курсы якынча 47,6 млн. сумга төшә.

Медицинада куллану өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 26 апрелендәге 403 номерлы карары белән расланган тормыш өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратлары исемлегенә һәм әлеге дару препаратының ташламалы исемлегенә кертелмәгән. Бу препарат шулай ук арка-мускул атрофиясен дәвалау буенча медицина ярдәме стандартына керми. СМАны дәвалау буенча расланган клиник тәкъдимнәр юк.

2020 елда республикада сирәк (орфан) авыруларыннан интегүче балаларны дару белән тәэмин итү йөкләмәләрен үтәү республикада урнашкан җайга салу кысаларында дәвам итте. Шулай итеп, «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына моңа мохтаҗ гражданнарны кирәкле дару чаралары белән тәэмин итүгә бәйле оештыру-идарә вәкаләтләре бирелү белән бергә, бюджет-финанс йөкләмәләре дә йөкләнде. Шул ук вакытта, сирәк (орфан) авырулар (фенилкетонурия, арка-мускул атрофиясе, ретро синдромы, Леннокс синдромы-Гасто) белән авыручы затларны дару препаратлары белән тәэмин итүне оештыру федераль үзәккә йөкләнгән.

Сирәк (орфан) авыруларны дәвалау өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән үзәкләштерелгән рәвештә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан сатып алына торган дару препаратлары исемлегенә 2020 елда тагын өч авыру өстәлде, болар: апластик анемия, нәселдән килә торган II (фибриноген), VII (лабиль), X (Стюарт-Прауэр) факторлары дефициты.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, сирәк (орфан) авырулардан интегүче затларны дару препаратлары белән тәэмин итү буенча Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына финанс йөкләнеше шактый зур. Шулай итеп, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләренә караганда, 2020 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 131 бала дару чаралары белән, 87 бала махсус туклану белән тәэмин ителгән. Шуның белән бергә, 2020 елда сирәк авырулардан интегүче балаларны дару белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре суммасы 2019 ел белән чагыштырганда (83,6 млн.сум) 4,5 млн. сумга кимегән һәм 79,1 млн. сум тәшкил иткән. Дарулар белән тәэмин итү бәясенең югары булуы һәм бюджет ассигнованиеләре күләмен кимету фонында республикада дарулар белән тәэмин итү проблемасы кискен кала.

Югарыда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, кеше гомеренә куркыныч тудыра торган һәм хроник авырулы балаларга ярдәм итү максаты белән Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы «Игелек даирәсе» фондын гамәлгә куйды. Фонд эшчәнлегенең төп максаты – кеше гомеренә куркыныч тудыра торган һәм хроник авырулы балаларга, шул исәптән сирәк (орфан) авырулары булган балаларга медицина ярдәмен күрсәтүне (кирәк чакта, Россия Федерациясеннән читтә дә), шулай ук мондый балаларны дару препаратлары һәм медицина әйберләре, шул исәптән Россия Федерациясендә теркәлмәгән медицина әйберләре, шулай ук техник реабилитацияләү чараларының, инвалидка күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтүнең федераль исемлегенә кертелмәгән техник реабилитацияләү чаралары тәэмин итүне оештыруның һәм финанс белән тәэмин итүнең өстәмә механизмын тормышка ашыру,

2021 ел башыннан Фонд арка-мускул атрофиясеннән интегүче балалар өчен дару препаратларын сатып ала башлаячак, бу исә югары керемле физик затларның НДФЛ ставкасын арттырудан алына торган акчалар исәбенә сирәк авырулар белән авыручы пациентларны кыйммәтле препаратлар белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, үзенә килгән мөрәҗәгатьне караганнан соң, 2020 елда «Үт кислоталары синтезы бозылу» дигән сирәк авыруны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 26 апрелендәге 403 номерлы карары белән расланган Гражданнарның гомер озынлыгын кыскартуга яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк очрый торган һәм хроник прогрессив (орфан) авырулар исемлегенә кертү мәсьәләсен күтәрде. Татарстан Республикасында әлеге авыру белән нибары 1 бала теркәлгән. «Үт кислоталары синтезының тумыштан бозылуы» авыруы югарыда күрсәтелгән исемлеккә кертелмәгән. Исемлектә бу авыруның булмавы баланы кыйммәтле препарат белән тәэмин итүдә шактый проблема тудыра.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе сәламәтлек саклау министры адресына «Үт кислоталары синтезының тумыштан бозылуы» авыруын әлеге исемлеккә кертү мәсьәләсен карау турында мөрәҗәгать җибәрде.

Балаларның сәламәтлеген саклау күзлегеннән караганда, балаларга ***профилактик вакцина һәм туберкулез диагностикасы*** уздыру вәзгыятен анализлау мөһим булып тора.

Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе белешмәләре буенча, 2020 ел нәтиҗәләре буенча ата-аналар тарафыннан профилактик вакцинадан баш тартуның 53 767 очрагы теркәлгән (2019 елда – 55 043 очрак).

*30 нчы таблица*

***2020 елда балаларга профилактик вакцина ясаудан баш тарту статистикасы***

| **Профилактик вакцина** | | **Баш тартулар саны** | **Кабат карау** |
|---|---|---|---|
| Профилактик вакцина, шул исәптән: | Бума ютәл | 5412 | 1860 |
| | Полиомиелит | 9240 | 2636 |
| | Кызамык | 10382 | 2982 |
| | Эпидемиологик паротит | 10110 | 2936 |
| | В гепатиты вирусы | 9889 | 2645 |
| **Барысы** | | **45033** | **13059** |

Аларның 27,7 %ы, ягъни 14 873е кире кагылды.


Туберкулез иң куркыныч йогышлы авыруларның берсе булып тора. Туберкулездан профилактикалау вакцинасы һәм диагностикалау мәсьәләләре югары игътибар үзәгендә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләренә караганда, 2020 елда республикада балалар арасында беренче тапкыр актив формадагы туберкулез белән авыручыларның 33 очрагы ачыкланды (2019 елда – 37 очрак).

Шулардан 27,7 % яки 14 873 баш тарту очрагы кабат каралды.

*56 нчы диаграмма*

***2016 – 2020 елларда балалар арасында туберкулез авыруы беренче тапкыр табылган очраклар (кеше)***




Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләренә караганда, 2020 ел нәтиҗәләре буенча ата-аналарның туберкулезны профилактикалау вакцинасыннан баш тартуының 848 очрагы теркәлгән, бу 2019 ел белән чагыштырганда 29,3%ка кимрәк (2019 елда – 1 096 очрак).

2020 елда туберкулез белән территориаль авыручылар саны 2019 ел белән чагыштырганда 18,8%ка кимегән һәм 100 000 кешегә 23,4 кеше тәшкил иткән (2019 елда – 28,8; 2018 елда – 29,6). Республикада туберкулез белән авыручылар саны Россия Федерациясендәгегә караганда 30,1%ка кимрәк (41,2) һәм Идел буе Федераль округындагыга караганда 28,5%ка кимрәк (40,3). 2020 елда туберкулездан үлүчеләр саны, 2009 ел белән чагыштырганда, 7,4%ка кимегән һәм 100 000 кешегә 2,5% тәшкил иткән (2009 елда – 2,7; 2018 елда – 2,9%).

Шуның белән бергә, туберкулез диагностикасын үткәрү һәм туберкулез диагностикасын узмаган балаларның белем бирү оешмаларына йөрүен вакытлыча читләштерү мәсьәләсе буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләрнең күп булуын исәпкә алып, түбәндәгеләрне аңлатып китәргә кирәк, дип саныйбыз.

Россия Федерациясе Конституциясенең 41, 42 статьялары нигезендә һәр граждан үз сәламәтлеген саклауга һәм уңай әйләнә-тирә мохитенә хокуклы. Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге өлкәсендәге мөнәсәбәтләр «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы № 52-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 52-ФЗ Федераль закон), башка федераль законнар, шулай ук алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив-хокукый актлары белән җайга салына. № 52-ФЗ Федераль законның 39 статьясы нигезендә Россия Федерациясе территориясендә федераль дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелеген гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган федераль санитар кагыйдәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә гамәл була,

дип билгеләнгән. Санитар кагыйдәләр шәхси эшкуарлар һәм юридик затлар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш.

52-ФЗ номерлы Федераль законның 29 ст. нигезендә йогышлы авырулар һәм йогышлы булмаган массакүләм авырулар (агуланулар) барлыкка килүне һәм таралуны кисәтү максатларында Россия Федерациясенең санитария кагыйдәләре һәм башка норматив-хокукый актларында каралган санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар, шул исәптән Россия Федерациясе территориясен санитар саклауны гамәлгә ашыру, чикләү чараларын (карантинны) кертү, җитештерү контролен, йогышлы авырулар белән авыручыларга карата чараларны гамәлгә ашыру чаралары, санитар кагыйдәләр һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актларында каралган башка чаралар, шул исәптән, медицина тикшерүләре, профилактик прививкалар ясау, гигиена тәрбиясе һәм гражданнарны укыту вакытында һәм тулы күләмдә башкарылырга тиеш.

2018 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законның 50 статьясындагы 2 өлеше нигезендә «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» санитария законнарын бозу очракларын ачыклаганда, шулай ук йогышлы авырулар һәм йогышлы булмаган массакүләм авырулар (агуланулар) барлыкка килү һәм таралу куркынычы янаганда, федераль дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар гражданнарга һәм юридик затларга ачыкланган санитар-эпидемиологик таләпләрне бозуларны бетерү турында, өстәмә санитар-эпидемияләргә каршы (профилактик) чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр бирергә хокуклы.

Законның 10 статьясы белән халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның бурычлары билгеләнгән, аерым алганда, гражданнар түбәндәгеләрне үтәргә тиеш: санитар законнар таләпләрен, шулай ук федераль дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның карарларын, күрсәтмәләрен; үз балаларының сәламәтлеге, гигиеник тәрбиясе һәм укуы турында кайгыртырга; башка гражданнарның сәламәтлеген саклауга һәм уңай яшәү тирәлегенә хокукларын бозуга китерә торган гамәлләр кылмаска.

«Россия Федерациясендә туберкулезның таралуын кисәтү турында» 2001 елның 18 июнендәге 77-ФЗ номерлы федераль закон гражданнар сәламәтлеген саклау һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү максатларында Россия Федерациясендә туберкулезның таралуын кисәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның хокукый нигезләрен билгели.

Әлеге закон белән, туберкулезга каршы ярдәм итү чаралары буларак, түбәндәгеләргә юнәлтелгән социаль, медицина, санитар-гигиена һәм эпидемиягә каршы чаралар җыелмасы билгеләнә: туберкулез белән авыручыларны ачыклауга, тикшерүгә һәм дәвалауга, шул исәптән мәҗбүри тикшерүгә һәм дәвалауга, диспансер күзәтүенә һәм медицина реабилитациясенә юнәлдерелгән һәм әлеге Федераль законда, башка федераль законнарда һәм башка норматив-хокукый актларда, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары законнарында һәм башка норматив-хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә амбулатор яки стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүгә. Туберкулезны профилактикалау дигәндә, туберкулезның барлыкка килүен, таралуын кисәтүгә, шулай ук аны иртәрәк ачыклауга юнәлдерелгән чаралар комплексы, дип аңларга кирәк.

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2013 елның 22 октябрендәге 60 номерлы карары белән «Туберкулезны профилактикалау» СП 3.1.2.3114-13 санитария-эпидемиология кагыйдәләре расланды.

Кагыйдәләрнең 5.1, 5.2, 6.2 пунктлары нигезендә 12 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларга һәм яшүсмерләргә туберкулез диагностикасы (иммунодиагностика) – елга

1 тапкыр, ә хәтшрлек югары булган төркемнәрдә (сулыш органнарының, ашказаны-эчәк трактының, шикәр диабетының хроник авырулары, ВИЧ-инфекцияле һәм туберкулезга каршы вакцинацияләнмәгән балаларга) елга 2 тапкыр үткәрелә.

Туберкулез диагностикасы нәтиҗәләре буенча туберкулез йоктыру яки туберкулез белән авыру шиге булган балалар ачыкланганда, алар фтизиатрда өстәмә тикшерү узарга тиеш.

Туберкулез диагностикасы узмаган балаларга, Кагыйдәләрнең 5.7 пунктында каралганча, бары тик авыру булмау турында табиб-фтизиатр бәяләмәсе булганда гына балалар оешмасында булуга рөхсәт ителә .

Кагыйдәләрнең 5.7 пунктында каралган, бары тик авыру булмау турында табиб-фтизиатр бәяләмәсе булганда гына балалар оешмасында булуга рөхсәт бирүне күздә тота торган таләп балалар оешмасына туберкулез керүен һәм таралуын булдырмауга, шулай ук башка гражданнарның сәламәтлеген саклауга һәм уңайлы яшәү мохитенә хокукларын үтәүгә юнәлдерелгән һәм әлеге нигезләмә 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон белән гарантияләнгән Россия Федерациясендә белем алу хокукларын чикләми.

Идарәнең әлеге позициясе түбәндәге суд практикасы белән раслана:

1. Татарстан Республикасы Югары судының 2017 елның 21 сентябрендәге 33-15401/2017 номерлы апелляция билгеләмәсе;

2. Татарстан Республикасы Югары суды 2015 елның 17 февралендәге АКПИ14-1454 номерлы эш буенча карары;

3. Мәскәү шәһәре Бутыр район судының 2015 елның 3 июнендәге 2-2459/2015 номерлы эш буенча карары.

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2013 елның 22 октябрендәге 60 номерлы карары белән расланган «Туберкулезны профилактикалау» С П3.1.2.3114-13 санитария-эпидемиология кагыйдәләре нигезләмәләре барлык юридик һәм физик затлар тарафыннан катгый үтәлергә тиеш һәм алар беркемнең дә хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен киметми.

«Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» Федераль законның 15 статьясындагы 1, 2 һәм 3 өлешләренең нигезләмәләре кулланылмый торган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларының һәм норматив хокукый актлар төркемнәренең, федераль башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларының һәм норматив хокукый актлар төркемнәренең, РСФСР һәм ССР Союзы башкарма һәм боеру дәүләт хакимияте органнары хокукый актларының, хокукый актларының аерым нигезләмәләренең, хокукый актлары төркемнәренең, Радиоешлыклар буенча дәүләт комиссиясе карарларының исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 31 декабрендәге 2467 номерлы карары нигезендә Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Туберкулезны профилактикалау» С П3.1.2.3114-13 санитария-эпидемиология кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 22 октябрендәге 60 номерлы карары 2021 елның 1 мартына кадәр гамәлдә була.

Балалар учреждениесе үз балаларының сәламәтлеген, гигиеник тәрбиясен һәм аларны укытуны кайгыртырга һәм башка гражданнарның сәламәтлеген саклауга һәм уңайлы яшәү тирәлегенә хокукларын бозуга китерә торган гамәлләр кылмаска тиеш.

Шулай итеп, туберкулез авыруы булмау турында табиб-фтизиатр белешмәсен таләп итү ата-ананың (законлы вәкилнең) һәм аның балигъ булмаган баласының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозмый һәм гамәлдәге законнарга каршы килми.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, сәламәтлек саклау, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсе, мәгариф органнары белән берлектә, балигъ булма-

ганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә профилактикалау вакцинасының һәм туберкулезны диагностикалауның максатчанлыгы һәм зарурлыгы турында даими һәм системалы рәвештә аңлату эшләре алып бару мәсьәләсе актуаль булып кала.

Укучыларның сәламәтлеген саклау буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру кысаларында ***укучыларның туклануын тиешенчә оештыру*** аерым әһәмияткә ия.

Укучыларны туклandыруны оештыру мәсьәләсе Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибар үзәгендә. «Мәктәп туклануы» дигәндә, балаларыбызның сәламәтлеге күздә тотыла. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә эш визитларын оештырганда һәм үткәргәндә мәктәптә туклану мәсьәләләре муниципаль берәмлекләр башлыклары белән фикер алышу предметы булып тора.

2020 елның 1 сентябреннән башлап Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч сыйныф укучылары өчен түләүсез кайнар ризык белән туклandыру оештырылды. 2020 елда башлангыч сыйныфларның бер укучысына көнгә түләүсез туклану бәясе 51 сум 85 тиен иде, 2021 елның гыйнварыннан 53 сум 41 тиен булды.

2020 елда 1– 4 сыйныф укучыларын түләүсез туклandыруга чыгымнар 859 962,2 млн. сум тәшкил итте, шулардан:

федераль бюджеттан – 498 778,1 млн. сум (58%);

республика бюджетыннан – 361 184,1 млн. сум (42%).

Татарстан Республикасында 1403 гомуми белем бирү оешмасы эшли. 2020 елда кайнар ризык белән 436 136 укучы (укучыларның гомуми саныннан 98%) тәэмин ителде, шул исәптән 209 650 кеше 1 – 4 сыйныф укучылары (әлеге категория укучыларының 100%).

Укучыларның аерым категорияләре Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары карары буенча туклану өчен түләүдән азат ителәләр. Республиканың күпчелек муниципаль берәмлекләрендә күпбалалы гаиләләр (4 һәм аннан да күбрәк балалары булган), аз керемле гаиләләр өчен ташламалы туклану оештырылган. Мәсәлән, Казан шәһәрендә ташламалы туклану җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбәнрәк булган аз керемле гаиләләрдәге балаларга, шулай ук социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балаларга бирелә. Чаллы шәһәрендә – 5 – 11 сыйныф укучылары һәм балигъ булмаган 4 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күпбалалы гаиләләр, Әлмәт шәһәрендә – ятим балалар, опекага алынган балалар, инвалидлар, аз керемле гаиләләрдәге балалар, шулай ук гаиләнең бер әгъзасына уртача айлык керем Татарстан Республикасында билгеләнгән минималь яшәү дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган күпбалалы гаиләләрнең балалары ташламалы туклану белән тәэмин ителә.

Чүпрәле, Мөслим һәм Питрәч муниципаль районнарында мәктәп укучыларын ташламалы туклandыру каралмаган.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил әлеге районнар башлыклары адресына район балалары өчен ташламалы бушлай туклану оештыру буенча чаралар күрү турында хатлар юллады.

Балаларны туклandыру мәктәпләр тарафыннан да (мәктәпләрнең 85%ы), шулай ук чит оешмалар (мәктәпләрнең 15%ы) тарафыннан да оештырыла.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга айлык акчалата һәм башка төр

түләүләр турында» 2009 елның 28 августындагы 724 номерлы карары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучы укучылар туклануга субсидияләр рәвешендә тәэмин ителү хокукына ия. Айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының тиешле карары ел саен кабул ителә. 2020 елда субсидия уку чорында көн саен 7,70 сум тәшкил итте, 2021 елга субсидия көн саен 8,0 сум тәшкил итә.

Яңа коронавирус инфекциясе буенча эпидемиологик вәзгыятькә бәйле рәвештә, гражданнардан үз-үзеңне изоляцияләү режимы чорында килгән мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил республиканың муниципаль берәмлекләрендә укучыларның әлеге хокукын тәэмин итүне оештыруга мониторинг үткәрде.

Нәтиҗәләр буенча, Казанда әлеге чорда, ташламалы категориягә керүгә дәйсез рәвештә, барлык укучыларның да әлеге хокукларын билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыру тәэмин ителмәгән булуы билгеләнде. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Казанда балаларны туклandыруны тәэмин итүнең билгеләнгән тәртибе ташламалы категорияләргә керүче гаиләләрдәге балалар өчен ташламалы туклануны оештыруны күздә тота. 2020 елда барлык укучыларның да көн саен 7,70 сумга туклануын тәэмин итүгә хокукын тормышка ашыруны оештыру каралмаган.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан чаралар күрелде. Кабул ителгән чаралар нәтиҗәләре буенча мәсьәлә балалар мәнфәгатьләрендә үз чишелешен тапты.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, 2020 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләр, 2019 ел белән чагыштырганда, 37%ка ким булды.

2020 елның 27 ноябрендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гомуми белем бирү оешмаларында туклануны оештыру мәсьәләләре буенча «кайнар линия» телефоны эшен оештырды, аның буенча гражданнардан 24 мөрәҗәгать керде.

Санитар закон таләпләрен бозу мәсьәләләре буенча тиешле эш башкарылды: 15 гомуми белем бирү оешмасы җитәкчеләренә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләренә, кабул ителгән чаралар турында мәгълүмат белән, санитария законнарын бозуларны бетерү буенча кичекмәстән чаралар күрү һәм күрелгән чаралар турында мәгълүмат бирү турында хатлар җибәрелде.

Хәзерге вакытта күпчелек ата-аналар туклану сыйфатыннан канәгать, шуның белән бергә, туклануны оештыру буенча түбәндәгеләргә карата шикаятьләр бар әле:

ризыкларның температура режимы сакланмау турында;

1 – 4 сыйныфлар өчен бушлай туклану менюсында беренче ризык – аш булмау турында;

кайбер мәктәпләрдә буфет продукциясе, камыр ризыклары булмау турында;

төшке һәм иртәнге ашка вакыт җитмәү турында;

ит ризыклары һәм ярымфабрикатлар әзерләү сыйфатының канәгатьләнкерлек булмавы турында;

аерым ризыклар белән туклануга ихтыяҗ булган балаларны туклandыру өчен ризыкларның булмавы турында.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, бу уңайдан мәктәпнең өч кешедән торган бракераж комиссиясенең көн саен аш-су сыйфатын бәяләвенә дә аерым игътибар бирелергә тиеш: медицина хезмәткәре, азык-төлек блогы хезмәткәре һәм мәгариф учреждениесе

администрациясе вәкиле органолептик күрсәткечләр буенча (ягъни тәме буенча) пробаларны әзерләнә торган савытлардан ук алалар. Шуннан соң гына балаларга әзер ризыкны бирү рөхсәт ителә, ми, бракераж нәтиҗәсе «Әзер кулинария продукциясе бракеражы» журналында теркәлә, ә ризык әзерләү технологиясе бозылганда, шулай ук ризык әзер булмаган очракта, ризык, ачыкланган кулинар җитешсезлекләр бетерелгәнче, куллануга бирелми.

Республика мәктәпләрендә туклану сыйфатын яхшырту өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте дәрәҗәсендә кайбер чаралар күрелә:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча Идарәсе белән берлектә, «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларның тукрануын оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.4.5.2409-08 нигезендә 1 – 4 сыйныф укучыларының туклануын оештыру өчен якынча ике атналык меню эшләнде һәм расланды.

2. Гомуми белем бирү оешмаларында сыйфатлы азык-төлек продуктларын кабул итү максатында Сатып алулар буенча дәүләт комитеты тарафыннан, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча Идарәсе белән берлектә, Азык-төлек продуктларын кабул итү регламенты эшләнде.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) даими рәвештә киңәшмәләр, шул исәптән видео-конференцэлемтә форматында, мәгариф идарәсе муниципаль органнары, дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм җаваплы белгечләре өчен Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсе вәкилләре катнашында киңәшмәләр уздыра.

4. Яңа 2020/2021 уку елы башыннан Министрлык тарафыннан ата-аналар берләшмәсенә, педагоглар һәм мәгариф идарәсе органнарына муниципаль һәм дәүләт гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч сыйныф укучылары өчен бушлай кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру буенча консультацияләр бирү өчен «кайнар линия» ачылды.

5. Мәктәп азык-төлек блокларын модернизацияләү буенча Юл картасы эшләнә.

6. Мәктәпләрдә яшүсмерләрнең сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыруга, туклану культурасына һәм аны оештыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрелә.

7. Муниципалитетларның гомуми белем бирү оешмалары базасында ата-аналар комиссияләре төзелде, алар туклану сыйфатын бәялиләр һәм учреждение администрациясенә оператив карарлар кабул итү һәм җитешсезлекләрне бетерү өчен кара-каршы элемтәдә торалар.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Татарстан Республикасында мәктәптә балаларны туклandыруны оештыру мәсьәләләренә игътибар бирә торган ата-аналар берләшмәсе бик актив һәм аларның потенциалын туклану сыйфатын контрольдә тоту һәм яхшырту өчен куллану бик мөһим. Биредә ата-аналар җәмәгатьчелегенең бурычы – объектив һәм актив булу.

Шул ук вакытта, белем бирү оешмаларында авыру балаларны (шикәр чире, целиакия) туклandыруны оештыру, мондый балалар өчен махсус меню эшләү актуаль булып кала.

Өй шартларында шөгыльләнүче 1 – 4 нче сыйныф укучыларын, кагыйдә буларак, инвалид балаларны һәм мөмкинлекләре чикле балаларны туклandыруны оештыру мәсьәләсе хәл ителмәгән булып кала.

Гомуми белем бирү оешмаларындагы азык-төлек блогы хезмәткәрләренең түбән хезмәт хакы да борчу тудыра.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына мәктәп азык-төлек блоклары хезмәткәрләренең хезмәт хакы системасын үзгәртү һәм хезмәткәрләрнең әлеге категориясенә түләүне арттыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итү урынлы булыр, дип уйлыйм;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары белән берлектә, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану тәэмин ителә торган укучыларның ташламалы категорияләре билгеләнгәндә, бердәм алымнарны куллану мөмкинлеген анализларга һәм карарга.

### *3.5.3. Балаларның ялы һәм аларны савыктыру*

Дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе – тиешле дәрәҗәдә оештырылган ял һәм савыктыру системасы.

Татарстан Республикасында бу бурыч түбәндәге кысаларында үтәлә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 7 февралендәге 73 номерлы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру» ярдәмче программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ял оештыру һәм муниципаль берәмлекләргә субсидияләр бирү тәртибен регламентлый торган «Балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында» 2016 елның 31 мартындагы 191 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләренең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2018 елның 4 сентябрендәге 748 нномерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2015 елның 3 мартындагы 130 номерлы карары белән расланган балаларның һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 3 мартындагы 130 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Хөкүмәте карары белән расланган стационар җәйге савыктыру лагерьларына ел саен капиталь ремонт ясау программалары.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, балалар лагерьлары инфраструктурасын үстерү, балаларның җәйге ялын оештыру максатыннан, Татарстан Президенты Р.Н.Миңнеханов тарафыннан махсус карар кабул ителде, һәм 2019 елдан республикада «ҖӘЙ – БАЛАЛАРГА» лагерьларын капиталь ремонтлау, реконструкцияләү һәм төзү буенча комплекслы программа старт алды, аның нигезендә лагерьларны капиталь ремонтлау өчен 7 млрд. сум акча бүлеп бирелде. Әлеге программага 94 дәүләт һәм муниципаль лагерь керә.

2019 – 2020 елларда 23 балалар савыктыру лагере капиталь ремонтланды, реконструкцияләнде һәм төзелде, шуларга 2,3 млрд.сум акча тотылды. Ремонт барышында төзелеш эшләре дә, корылмаларны, инженерлык челтәрләрен реконструкцияләү дә алып барылды. Иминлеккә аерым игътибар бирелә – контроль-үткәрү пунктларын комплектлау, территорияне киртәләү, видеокүзәтү системасын урнаштыру һ. б.

2020 елда 9 муниципаль берәмлектә 12 балалар савыктыру лагерена керү юллары ремонтланды һәм төзелде


Республикада коронавирус инфекциясенә бәйле вәзгыятькә бәйле рәвештә, җәйге савыктыру кампаниясен, төбәктә санитар-эпидемиологик хәлне исәпкә алып, 2020 елның 1 июленнән башлау турында карар кабул ителде. Палатка тибындагы лагерьларның эшчәнлеге туктатылды. Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибы А.Ю. Попованың «СП 3.1/2.4 3598-20 (СОУЮ-19) санитар-эпидемиологик кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 30 июнендәге 16 номерлы карары нигезендә, көндезге ял һәм хезмәт лагерьлары буенча җәйге күләмнәр 2020 елның көзге-кышкы чорына күчерелде. Җәйге савыктыру кампаниясе 32 муниципаль оешма территориясендә 45771 бала өчен 102 ял оешмасында өч сменада уздырылды, шул исәптән 12 шифаханә тибындагы лагерьда.

Татарстан Республикасында балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары санын киметмәү өчен, төп чаралардан тыш, икътисадый характердагы өстәмә ярдәм чаралары эшләнде, алар үз эченә түбәндәгеләрне ала: авыр тормыш хәлендә булган балалар өчен (8,5 мең бала), «кызыл зона» медицина хезмәткәрләре балалары өчен (450 бала), сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен, инвалид балалар өчен (157 бала), лагерьларның матди-техник базасын ныгыту өчен, шулай ук балаларны савыктыру лагерьларын төзү, ремонтлау, модернизацияләү («ҖӘЙ-БАЛАЛАРГА» программасы) өчен республика һәм муниципаль бюджетлардан субсидияләр бирү.

Татарстан Республикасында 2020 елгы җәйге савыктыру кампаниясенә план күрсәткечләре (46 меңгә якын бала) һәм җәйге каникулларга балалар һәм яшьләрнең ял итү һәм савыктыру программасын финанслау күләме (1,521 млрд. сум) җәйге чорда балалар өчен күпчелек савыктыру оешмаларының (милек рәвешләренә бәйсез рәвештә) 2-3 сменада эшләвен оештырырга мөмкинлек бирде. Шулай ук COVID-19 инфекциясе таралуны булдырмау профилактикасы буенча өстәмә чараларга (дезинфекциянең өстәмә чараларын сатып алуга, персоналга тест үткәрүгә һ. б.) балалар савыктыру оешмаларының (милек рәвешләренә бәйсез рәвештә) финанс ихтыяҗларын тәэмин итүгә 110 млн. сум акча бүлеп бирергә килешенде.


*57 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда балалар өчен ял һәм савыктыру учреждениеләре челтәре структурасы (оешма рәвеше буенча)***



*58 нче диаграмма*

***2016–2020 елларда елларда Татарстан Республикасында балалар өчен шәһәр яны ял һәм савыктыру учреждениеләре челтәре структурасы (милек төрләр буенча)***




2020 елгы савыктыру кампаниясе чорында яңа короновирус инфекциясенә бәйле эпидиомиологик имин булмаган хәлләр шартларында 139449 кешегә ял оештырылган.

2020 елда балаларны һәм яшьләрне савыктыру кампаниясен финанслауның гомуми күләме 1 094,2 млн. сум тәшкил итте, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1 037,9 млн.сум, предприятиеләр акчаларыннан һәм ата-аналар исәбеннән – 56 мең сум.

Җәйге чорда 139 449 кеше ял иткән, бу 2019 елгы җәйге кампаниягә караганда 39 577 кешегә кимрәк.

*59 нчы диаграмма*

***2020 елда елда төрле рәвештә ял иткән балалар саны***




Җәйге савыктыру кампаниясенә әзерлек һәм аны уздыру чорында балалар ялын һәм савыктыруны оештыру күп кенә контроль-күзәтчелек органнарының һәм ведомстволарның тикшерү эшчәнлегендә өстенлекле юнәлеш булып тора.

Балалар лагерьларының балаларны кабул итүгә әзерлеген анализлау, куркынычсызлык таләпләрен үтәү максатыннан, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Нармонка» БСЛда (ДОЛ), Казан шәһәре яшьләр сәясәте МБУнең «Татарстан пионериясе» БСЛда, Лаеш районы территориясендә урнашкан «Ял» балаларны һәм яшьләрне савыктыруны, ял иттерүне, аларның мәшгульлеген оештыру буенча шәһәр үзәге»ндә булды. Әлеге тикшерү барышында лагерь эшен оештырганда балаларны ял иттерү һәм савыктыру буен-

ча стационар оешмаларны урнаштыруга, тотуга һәм аларның эшлдәрен оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләрне бозу очраклары ачыкланды, шуңа бәйле рәвештә, гамәлгә куючы (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты) адресына таләпләрне бозу һәм аларны бетерү буенча чаралар күрү турында бәяләмә җибәрелде. Җитешсезлекләр бетерелде.

2020 елгы җәйге савыктыру кампаниясе нәтиҗәләре буенча балаларны савыктыру лагерьлары территориясеннән һәм күпләп ял итү урыннарыннан балигъ булмаганнарның рөхсәтсез китү очраклары теркәлмәгән. Балигъ булмаганнарның рөхсәтсез китү очраклары булмауда Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан республиканың савыктыру лагерьлары территориясендә көн саен хокук тәртибе мониторингын алып бару ярдәм итә.

Гомумән алганда, 2020 елгы савыктыру кампаниясен COVID-19 авыруы белән авырган, ризык белән агуланган, имгәнгән һәм авыр нәтиҗәләргә китерә торган башка очракларсыз уздыру Яшьләр эшләре, Мәгариф һәм фән, Сәламәтлек саклау, Мәдәният, Гадәттән тыш хәлләр министрлыклары, Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең көйле эш нәтиҗәсе дип атарга мөмкин.

***Балаларны туклandыруны оештыру*** лагерьлар җитәкчеләре ягыннан катгый рәвештә даими һәм системалы игътибар үзәгендә һәм контролендә булырга тиеш.

Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хезмәтенең контроль эшчәнлеге нәтиҗәләре ел саен санитар-эпидемиологик иминлек өлкәсендә закон бозу очракларын ачыклый, аларның күбесе агымдагы характерда һәм күп очракта җитәкчеләр һәм җаваплы хезмәткәрләрнең компетентсызлыгы аркасында була. Тикшерүләр барышында Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча Идарәсе тарафыннан 1374 шундый тәртип бозу очрагы (2019 елда – 1 889) ачыкланды. Тәртип бозуларның күбесе туклануны оештыруга бәйле – шундый 695 очрак. Ачыкланган бозулар буенча 154 вазыйфаи зат һәм 11 юридик зат җаваплылыкка тартылды.

Гомумән алганда, административ җаваплылыкка җәлеп итү чараларын куллану өчен түбәндәгеләр нигез булды: гомуми файдаланудагы урыннарны, торак биналарны карап тоту режимнарын үтәмәү, кухня инвентарен эшкәртү, азык-төлек продукциясен саклау шартларын бозу, азык-төлек продуктларын йөртү документларының яки чималның тәңгәллеген күрсәтә торган маркировканың булмавы, азык-төлек блогы биналарында санитар-дезинфекция режимын үтәмәү, су челтәреннән килә торган суны, әзер ризыкларны санитар-химик һәм микробиологик күрсәткечләре буенча лаборатор тикшерү нәтиҗәләре канәгатьләнерлек булмау һ.б.лар.

Җәйге ялны балалар тарафыннан бәяләү индикаторларының берсе – барыннан да элек, лагерьларда булган чорда программаларның «кызыклы» булуы. Шуңа күрә биредә төп бурыч – эчтәлекле, танып белү программаларын эшләүне һәм гамәлгә ашыруны да кертеп, профессиональ ***тәрбияләү эшен оештыру***.

2020 елда җәйге савыктыру учреждениеләрендә булган балаларның сәламәтлек нәтиҗәлелеген бәяләүдән күренгәнчә, балаларның 98,8%ында савыктыру эффекты югары дәрәҗәдә, 1,2%ында савыктыру эффекты түбәнрәк булган, бер дә эффект алмаган балалар юк.

***Авыр тормыш хәлендә калган балалар***, социаль-тернәкләндерү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр белән эшләүне оештыру аерым игътибар таләп итә. Алар өчен ял оешмаларында шәхси тернәкләндерү программаларын, авыр тормыш хәленнән чыгуда психологик һәм башка ярдәм күрсәтүне дәвам итү мөһим.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2019 ел докладында бәян ителгән тәкъдимнәрен исәпкә алып, 2020 елда Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан авыр тормыш хәлендә калган гаиләләрдәге 6 665 бала, шулай ук мөмкинлекләре чикле гаиләләрдәге 157 бала юллама белән тәэмин ителде, алар арасында начар ишетә һәм күрә торган, шикәр диабеты белән авыручы, ДЦП һәм сөйләм үсеше бозылган балалар да бар.

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының Балалар һәм яшүсмерләр туризмы федераль үзәге мониторингы белешмәләре буенча, ЛОК-2020 нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы сезонлы һәм ел әйләнәсе ял иттерү һәм савыктыру оешмаларында ял иткән балалар саны буенча Россия Федерациясендә беренче урында тора.

Шул ук вакытта, ишетүе һәм күрүе, интеллекты, аутизм спектры бозылган, шикәр диабеты белән авыручы балалар өчен, мөмкинлекләре чикле балалар өчен махсус сменалар белән ял оештыру мәсьәләсе актуаль булып кала. Бөгелмә шәһәрендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен махсуслаштырылган балалар лагерен гамәлгә кертү әлеге проблемаларны хәл итәргә ярдәм итәчәк, хәзер анда реконструкция эшләре бара.

## 3.6. Баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклануга һәм иминлеккә хокукын тәэмин итү

Гражданнар мөрәҗәгатьләре саны буенча җиденче урында баланы барлык ***төр көч кулланудан һәм рәхимсезлектән яклауга*** бәйле мөрәҗәгатьләр тора. Бу тематика буенча мөрәҗәгатьләр саны соңгы елларда бер дәрәҗәдә кала: әлеге тема буенча 2020 елда – 53 мөрәҗәгать, барлык мөрәҗәгатьләрнең 3%ын тәшкил итте (2019 елда – 3%, яисә 54 мөрәҗәгать, 2018 елда – 55 мөрәҗәгать, яисә 3%). Элеккеге кебек үк, гражданнар мөрәҗәгатьләре өчен төп сәбәпләр түбәндәгеләр: кылган гамәлләргә карата җинаять эше кузгатмау, хокук саклау органнары эшчәнлегеннән канәгать булмау, аларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү, гаиләдә көч куллану, ата-аналар (туганнары, өйдәшләре) ягыннан балаларга карата рәхимсезлеклек күрсәтү мәсьәләләре.

Баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклануга һәм иминлеккә хокукын тәэмин итү хокукын үтәү торышын анализлау нигезенә статистика белешмәләре һәм республикада күреләә торган «баланы барлык рәвешле физик һәм психологик көч кулланудан, хурлаудан, кайгыртучанлык күрсәтмәүдән яисә саксызлык күрсәтүдән яклау максатында барлык кирәкле закон, административ, социаль һәм агарту чараларын...» өйрәнү нәтиҗәләре салынган.

### *3.6.1. Балаларның тышкы сәбәпләрдән үлүен анализлау*

Баланың яшәешен максималь дәрәҗәдә саклап калу гарантиясен тәэмин итү бурычының дәүләт тарафыннан үтәлүен бәяләү күзлегеннән караганда, балаларның тышкы сәбәпләрдән – бәхетсезлек очракларыннан, үз-үзенә кул салудан, балаларга карата кылынган җинаятьләрдән үлү очраклары аеруча игътибар үзәгенә алына. Бу өлкәдәге вәзгыятьне анализлау, сәбәпләрне, вакыйгаларны ачыклау, профилактика органнарының – субъектларының ведомствоара хезмәттәшлеге, массакүләм мәгълүмат чараларының, балалар һәм ата-аналар җәмәгатьчелегенең мондый фаҗигаләрне булдырмауга игътибарын

җәлеп итү балаларны үлемнән яклап калуга гына түгел, ә бүген яшәүче һәм яңа туган балалар арасында инвалидлык һәм авырулар санын киметүгә, ягъни милләтнең иҗтимагый сәламәтлеген ныгытуга да ярдәм итә ала.

Гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә балалар үлеменә бәйле вәзгыять Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым контролендә тора. Иминлекне тәэмин итү күзлегеннән караганда игътибар итүгә аеруча мохтаҗ юнәлешләр буенча балигъ булмаганнарның түбәндәгеләр аркасында үлеме һәм имгәнүе турындагы мәгълүматларны даими режимда мониторинглау гамәлгә ашырыла:

– җинаятьләр нәтиҗәсендә;

– янгын һәм юл-транспорт һәлакәтләре, суга батулар нәтиҗәсендә;

– төзелеш һәм спорт (балалар) мәйданчыкларында, коммуналь инфраструктура объектларында имгәнү нәтиҗәсендә;

– суицидлар аркасында;


– башка гадәттән тыш хәлләр аркасында.

Балалар белән булган гадәттән тыш хәлләрне системалы мониторинглау күрсәткәнчә, республика территориясендә балаларның тышкы сәбәпләрдән үлү статистикасы борчу тудыра. Бу фаҗигаләрнең күбесен булдырмый калырга да мөмкин булыр иде.

Татарстан Республикасы буенча Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белешмәләренә караганда, 2020 елда 12 балигъ булмаган бала төрле ***су объектларында батып үлгән.***

*76 нчы диаграмма*


***2016 – 2020 елларда сулыкларда батып үлгән балалар саны (кеше)***




Су объектларында һәлак булган балалар арасында өч бала – 6 яшькә кадәр, өчесе – 7 яшьтән 13 яшькә кадәр, алты балигъ булмаган бала 14 яшьтән 17 яшькә кадәр булган.

*77 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда су объектларында батып үлгән балалар саны (яшьләре буенча) (кеше)***




Узган ел Казан, Чаллы шәһәрләрендә, республиканың Актаныш, Буа, Зеленодольск, Мамадыш, Нурлат, Түбән Кама, Питрәч, Балык Бистәсе муниципаль районнарында елгаларда һәм күлләрдә балаларның һәлак булу очраклары теркәлгән.

Сулыкларда үлүнең төп сәбәпләре – балаларны караучысыз калдыру һәм су объектларында куркынычсызлык кагыйдәләрен бозу, аерым алганда, махсус көйләнмәгән урыннарда коену, йөзә белмәү.


Су объектларында кешеләр һәлакәтенә һәм үлеменә юл куймау максатларында, коену өчен санкцияләнмәгән урыннарны ачыклауны дәвам итәргә, махсус көйләнмәгән урыннарда, шулай ук балалар һәлак булган урыннарда коенуны тыю билгеләре һәм аншлаглар куярга кирәк.

2020 елда Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белешмәләре буенча, Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар катнашында 21 ***янгын*** очрагы булган, аларда 3 бала һәлак булган һәм 20 бала зыян күргән. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, янгыннарда үлү очракларының 3 тапкырдан артыграк кимүе күзәтелә. 2020 елда республиканың Алексеевск, Зәй, Балык Бистәсе муниципаль районнарында балалар үлеме белән тәмамланган барлыгы 3 янгын булган.

***Мисал:***
*Фаҗига 2020 елның декабрендә Спас районының Танкеевка авылында була. Мәрхүмнең әнисе сүзләренә караганда, мунча көндез үк ягыла, җылысын тоту өчен мичкә өстән торганнар. Җиде яшьлек бала юынырга үзе генә кереп киткән. 15 минуттан соң аны мунчада аңсыз табып алалар, бала үлеменең сәбәбе – угар газыннан агулану.*

*78 нче диаграмма*


***2016 – 2020 елларда янгыннарда һәлак булган балалар саны (кеше)***




Вәзгыятьне анализлаудан күренгәнчә, аеруча хәтәр төркем балалары -мәктәпкәчә яшьтәге балалар. Бу аларның кече яшьтә булуына, хәлне дөрес бәяли һәм дөрес карар кабул итә белмәүләренә бәйле. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның хәрәкәт итүләре активлаша, бу баланың физик мөмкинлекләре арту белән билгеләнә, алар бар нәрсә белән кызыксына башлыйлар, мөстәкыйль булырга омтылалар, менә шулар еш кына балалар гомере һәм сәламәтлеге өчен хәтәр булган хәлләргә китерә дә инде. Һәлак булган балаларның өчесе дә 6 яшькә кадәргеләр.

*79 нчы диаграмма*

***2016 – 2020 елларда янгыннарда һәлак булган балалар саны (яшьләре буенча, кеше)***



Үлем белән тәмамланган янгыннар килеп чыгуга китергән хәлләрне анализлау аларның сәбәпләренең берсенең дә гаиләнең имин булмавына бәйле түгеллеген күрсәтте.

Шул ук вакытта янгыннарда балаларның һәлак булу яки имгәнүенең төп сәбәпләреннән берсе – ата-аналарның гаебе һәм аларның үз балаларына тиешенчә игътибар бирмәве.

Янгыннарны тикшерү нәтиҗәләре буенча, муниципаль районнарда балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре исеменә Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре тарафыннан 18 ата-ананы (аларның законлы вәкилләрен) Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә (ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен) административ җаваплылыкка тарту турында материаллар җибәрелгән. Янгыннар очраклары турында муниципаль комиссияләргә материаллар җибәрү янгыннарда балаларның фаҗигале һәлак булуына китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны карау һәм өйрәнү кебек мөһим бурычны башкаруга ярдәм итә. Бүтән яктан – бу ата-аналарга аларның балаларны тәрбияләү җаваплылыгын арттыру максатында тәэсир итү дә.

Имин булмаган гаиләләрдә янгыннардан иң нәтиҗәле профилактик чара булып яшәү урыннарын янгын чыгуны алдан белү һәм хәбәр итү чаралары белән җиһазлау тора.

Әйтергә кирәк, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе белешмәләренә караганда, 2020 елда «Торак» профилактик операциясе кысаларында профилактик төркемнәр 17 966 мәртәбә күпфатирлы йортларга чыктылар, 265 500 тапкыр – шәхси йортларга, шул исәптән 30 296ы – күпбалалы гаиләләр яши торган урыннар. Биредә яшәүчеләр белән янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәү буенча әңгәмә үткәрелде, белешмәлекләр тапшырылды.

Янгынның башлангыч стадиясендә ук яшәүчеләрне янган йорттан (фатирдан) эвакуацияләү өчен янгын турында хәбәр итү максатында, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Идарәсе 2016 – 2020 елларда аерым категория гражданнарны янгын башлануы турында автоном хәбәр бирү җайланмалар белән тәэмин итү буенча хәйрия акциясен үткәрү инициативасы белән чыкты.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов ярдәме белән, 2016 елдан башлап, гражданнарның торак йортларында янгынның башлангыч стадиясендә яшәүчеләргә куркыныч янау турында автоном хәбәр бирү җайланмалары урнаштыру буенча эш алып барыла, шундый җайланмалар түбәндәге йортларда куелды:

балигъ булмаган балалары булган имин булмаган гаиләләр тора торган 2 079 йортта (фатирда) (7 060 хәбәр бирү җайланмасы);

социаль куркыныч хәлдә булмаган күпбалалы (4 һәм аннан күбрәк бала) гаиләләр тора торган 450 йортта (фатирда) (14 125 хәбәр бирү җайланмасы).

Узган ел акциянең 6нчы этабы кысаларында инвалид балалары булган һәм керемнәре яшәү минимумыннан түбән булган күпбалалы гаиләләр яши торган 21 216 йортта 84 904 хәбәр бирү җайланмасы урнаштырылган.

Янгын турында хәбәр бирү җайланмасы булу нәтиҗәсендә йортларда яшәүчеләр вакытында янгын турында хәбәр ала алдылар, бу 78 кешене, шул исәптән 35 баланы бәладан коткарып калды.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә башкарма хакимият һәм җирле үзидарә органнарына янгынга каршы чараларны тулы күләмендә үтәүгә, шулай ук объектларны янгыннан саклауга юнәлдерелгән даими регламент чараларын башкаруга, шул исәптән янгыннан саклау системаларына хезмәт күрсәтүгә юнәлдерелгән вакытлы регламент чараларына максатчан финанслауны күздә тотарга тәкъдим ителә.

Күрсәтелгән чараларны үтәү янгын чыгу куркынычын киметергә, балаларның һәлак булуын һәм җәрәхәтләнүен булдырмый калырга, шулай ук янгын чыгуны иртә стадиядә белү нәтиҗәсендә зыянны киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Һәлак булган балаларның яше – 8 – 17 яшь, барлык балалар – мәктәп укучылары, шуннан чыгып, белем бирү оешмаларында урта һәм өлкән сыйныф укучылары һәм аларның эти-әниләре арасында профилактик эшне көчәйтергә кирәк.

Һичшиксез, суда һәм янгыннардан бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә балалар үлемен (имгәнүен) кисәтү мәсьәләләрендә системалы ведомствоара профилактика, шул исәптән башкарма хакимият органнарының гына түгел, ә бу өлкәдә эшләүче иҗтимагый берләшмәләрнең агарту эшчәнлеге, шулай ук бу процесска балаларның үзләрен актив җәлеп итү дә мөһим роль уйный.

Шул уңайдан 2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Лучшая памятка» («Иң яхшы белешмәлек») республика конкурсын үткәрү планлаштырыла.

Шуның белән бергә, бу юнәлеш буенча урыннарда җитди агарту һәм профилактик эш алып барудан тыш, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль һәм дәүләт программаларында авыр тормыш хәлендә булган гаиләләргә ярдәм итү, төзек булмаган мич һәм электротехник җиһазларны ремонтлау буенча чараларны финанслауны арттыру да мөһим булыр иде.

*19 нчы таблица*

***2020 елдагы янгыннарның сәбәпләре***


| *Янгыннарның сәбәпләре* | *Һәлак булучылар* | *Имгәнүчеләр* |
|---|---|---|
| *Ут белән саксыз эш итү* | ***0*** | ***9*** |
| *Балаларның ут белән шаяруы* | ***1*** | ***7*** |
| *Электр җиһазларын урнаштыру һәм эшләтү кагыйдәләрен бозу* | ***1*** | ***3*** |
| *Көнкүреш газларыннан, керосинда, бензинда эшләүче җайланмалардан файдалану кагыйдәләрен бозу* | ***0*** | ***0*** |
| *Мич җайланмасыннан файдалану кагыйдәләрен бозу* | ***0*** | ***1*** |
| *Шартлау* | ***1*** | ***0*** |

Бәхетсезлек очраклары аркасында балаларның үлеменә китергән сәбәпләр структурасында ***юл-транспорт һәлакәтләрендә*** җәрәхәтләр алу аерым урын алып тора. 2020 елда юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы юлларында үлем һәм имгәнүләр белән бәйле хәл катлаулы булып кала, шул ук вакытта күрсәткечләрнең кимүе күзәтелә, бу процессларның уңай динамикасын чагылдыра.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе (алга таба – ТР буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе) белешмәләре буенча, 2020 елда балигъ булмаганнар катнашында 583 юл-транспорт һәлакәте (ЮТҺ) теркәлгән, аларда 11 бала һәлак булган һәм 631 бала җәрәхәт алган.

*80 нче диаграмма*

***2017 – 2020 елларда Татарстан Республикасында балалар катнашында юл-транспорт һәлакәтләре саны (кеше)***




Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда балигъ булмаганнар катнашында юл-транспорт һәлакәтләре саны 8,7%ка кимегән (2019 елда 671 очрактан 2020 елда 583 очракка кадәр).

ЮТҺ нәтиҗәсендә җәрәхәтләнгән балалар саны, алдагы күрсәткечләр белән чагыштырганда, 8,9%ка кимегән (2019 елда 711дән 2020 елда 631гә кадәр). Һәлак булган балалар саны 11гә кадәр кимегән (2019 елда – 24 бала).

*81 нче диаграмма*


***2016 – 2020 елларда юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган һәм җәрәхәтләнгән балалар саны (кеше)***




Зыян күрүчеләрнең һәм һәлак булган балаларның яшь составын анализлау «Хәтәр төркеме» балалары турында аерым нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирми. Әмма 7 яшьтән алып 13 яшькә кадәрге балалар арасында җәрәхәт алган балаларның шактый күп булуы мөстәкыйль рәвештә, өлкәннәрдән башка юлда йөри башлаган балаларга карата аеруча игътибарлы булырга кирәклекне күрсәтә.


*82 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган балалар саны (яшь буенча) (кеше)***



*83 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда юл-транспорт һәлакәтләрендә имгәнгән балалар саны (яшь буенча) (кеше)***




Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә үлүчеләр саны кимү күрсәткече Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең берсе булуын исәпкә алып, республиканың муниципаль берәмлекләре киселешендә балаларның юл-транспорт һәлакәтендә имгәнүләрен анализлау мөһим булып тора.

«2013 – 2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасын һәм «Юл хәрәкәте иминлеге» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында «Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проектын тормышка ашыру, шулай ук юлда йөрүчеләрнең хокукый аңын арттыру һәм тәртип бозмыйча йөрүләрен кисәтү максатларында, Татарстан Республикасында юлда йөрүчеләрнең төрле категорияләре өчен социаль әһәмиятле чаралар үткәрелә. Аларны үткәрүгә дәүләт хакимияте органнары, иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре актив җәлеп ителә, социаль реклама киң кулланыла.

Республиканың барлык муниципаль берәмлекләренә эре автомобиль юллары янында урнашкан торак пунктларда аларны тарату өчен 17 000 күчмә ут чыганагы (фонарь) сатып алынды һәм таратылды.

Шулай ук Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе, җирле үзидарә органнары белән берлектә, «ЮХИДИ ветераннарының Татарстан Республика берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы ярдәме белән РКБның перинаталь үзәге базасында Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов катнашында балалар өчен прокатка автокреслолар (автолюлкалар) бирү пункты ачылды. Хастаханәдән чыгарганда яшь ата-аналарга яңа туган баланы имин йөртү өчен автолюлькалар тәкъдим ителә. Беренче ай куллану бушлай. Беренче ай узгач, ата-аналар автолюлканы кире кайтара яки билгеләнгән аренда түләве нигезендә файдалана ала, шулай ук сатып алу мөмкинлеге дә бар.

*20 нче таблица*

***2019 – 2020 елларда һәлак булган һәм җәрәхәтләнгән балалар саны (районнар буенча) (кеше)***

| ***Муниципаль берәмлек (шәһәр округы) исеме*** | ***2019 ел*** | | ***2020 ел*** | |
|---|---|---|---|---|
| | *погибло* | *травмировано* | *погибло* | *травмировано* |
| *Казан шәһәре* | *3* | *217* | *1* | *201* |
| *Чаллы шәһәре* | *1* | *108* | *0* | *111* |
| *Әгерҗе* | *0* | *4* | *0* | *1* |
| *Азнакай* | *1* | *8* | *0* | *11* |
| *Аксубай* | *0* | *1* | *0* | *1* |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| *Актаныш* | *0* | *1* | *0* | *1* |
| *Алексеевск* | *1* | *4* | *0* | *6* |
| *Әлки* | *0* | *1* | *0* | *2* |
| *Әлмәт* | *0* | *32* | *1* | *31* |
| *Апас* | *0* | *3* | *0* | *1* |
| *Арча* | *0* | *8* | *0* | *5* |
| *Әтнә* | *0* | *5* | *0* | *1* |
| *Бауклы* | *0* | *4* | *0* | *2* |
| *Балтач* | *0* | *3* | *0* | *1* |
| *Бөгелмә* | *1* | *20* | *0* | *12* |
| *Буа* | *3* | *8* | *1* | *6* |
| *Югары Ослан* | *1* | *6* | *0* | *3* |
| *Биектау* | *0* | *9* | *0* | *6* |
| *Чүпрәле* | *1* | *3* | *1* | *0* |
| *Алабуга* | *1* | *25* | *0* | *25* |
| *Зәй* | *0* | *8* | *0* | *11* |
| *Зеленодольск* | *1* | *25* | *0* | *21* |
| *Кайбыч* | *0* | *0* | *0* | *2* |
| *Кама Тамагы* | *0* | *2* | *0* | *0* |
| *Кукмара* | *0* | *3* | *0* | *1* |
| *Лаеш* | *2* | *14* | *1* | *12* |
| *Лениногорск* | *1* | *11* | *0* | *10* |
| *Мамадыш* | *0* | *8* | *0* | *4* |
| *Менделеевск* | *2* | *5* | *0* | *2* |
| *Минзәлә* | *0* | *13* | *0* | *7* |
| *Мөслим* | *0* | *1* | *1* | *1* |
| *Түбән Кама* | *1* | *85* | *3* | *55* |
| *Яңа Чишмә* | *1* | *2* | *0* | *1* |
| *Нурлат* | *0* | *6* | *0* | *7* |
| *Питрәч* | *1* | *4* | *1* | *7* |
| *Балык Бистәсе* | *1* | *4* | *0* | *5* |
| *Саба* | *0* | *1* | *0* | *2* |
| *Сарман* | *1* | *3* | *0* | *9* |
| *Спас* | *0* | *2* | *0* | *1* |
| *Тәтеш* | *0* | *2* | *0* | *2* |
| *Тукай* | *0* | *21* | *0* | *16* |
| *Теләче* | *0* | *5* | *0* | *1* |
| *Чирмешән* | *0* | *2* | *0* | *1* |
| *Чистай* | *0* | *12* | *1* | *26* |
| *Ютазы* | *0* | *2* | *0* | *0* |

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе белешмәләренә караганда, 2020 елда 172 юл-транспорт һәлакәте балаларның саксызлыгы аркасында килеп чыккан, бу балигъ булмаганнар катнашында булган юл-транспорт һәлакәтләренең 30%ын тәшкил итә. 2019 елда әлеге күрсәткеч 26% иде.

Балалар гаебе белән килеп чыккан юл-транспорт һәлакәтләренең төп сәбәпләре велосипедчылар, скутерчылар, мотоциклчылар тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу (42 очрак), күренми торган урыннан кинәт килеп чыгу аркасында (39 очрак), транспорт алдыннан тиешле булмаган урында чыгу (37 очрак), светофорның тыелган сигналына чыгу (19 очрак), балалар тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу (44 очрак) булды.

*21 нче таблица*

***2015-2020 елларда балалар гаебе белән юл-транспорт һәлакәтләренең сәбәпләре***

| *ЮТҺнең сәбәпләре* | *2016 ел* | *2017 ел* | *2018 ел* | *2019 ел* | *2020 ел* |
|---|---|---|---|---|---|
| *Велосипедчылар, скутерчылар, мотоциклчылар тарафыннан юл хәрәкәтен бозу* | *29* | *33* | *33* | *65* | *42* |
| *Күренми торган урыннан кинәт килеп чыгу* | *38* | *31* | *44* | *49* | *39* |
| *Транспорт алдыннан тиешле булмаган урында чыгу* | *66* | *18* | *21* | *25* | *37* |
| *Светофорның тыелган сигналына чыгу* | *8* | *15* | *16* | *17* | *9* |
| *Балаларның машиналар юлында уйнавы* | *5* | *0* | *1* | *1* | *1* |
| *Балалар тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен башкача бозу* | *5* | *50* | *59* | *15* | *44* |
| ***Барысы*** | ***153*** | ***149*** | ***177*** | ***172*** | ***172*** |


ЮТҺ китергән шартларны караганнан соң, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район (шәһәр) комиссияләре исеменә Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе хезмәткәрләре тарафыннан 171 ата-ананы (аларның законлы вәкилләрен) (2019 елда – 237) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә (ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен) административ җаваплылыкка тарту турында материаллар җибәрелгән.

Балалар өчен юл-транспорт имгәнүләрен киметү буенча иң нәтиҗәле чараларга балалар автомобиль креслоларын һәм куркынычсызлык каешларын (шул исәптән автомобильнең арткы утыргычларында да) куллануны, торак пунктларда тизлекне чикләү, тәүлекнең караңгы вакытында яктылык кайтаручы элементларны куллануны кертергә кирәк.

2020 елда 3 бала ***егылып төшү*** аркасында үлгән, бу очраклар суицидка бәйле түгел. Болар – мәктәпкәчә яшьтәге балалар.

*84 нче диаграмма*

***2016 – 2020 елларда тәрәзәдән егылып төшеп үлгән балалар саны (кеше)***




Бүлмәне җилләтү теләге ел саен Россиядә йөзләгән гаиләне бәхетсез итә. Балаларны – караучысыз калдыралар.

Тәрәзәдән төшү очраклары Казан шәһәрендә – 2, Әлмәт муниципаль районында – 1. Әлмәт муниципаль районында соңгы ике ел дәвамында тәрәзәдән балалар төшеп үлү игътибарны җәлеп итә.

*22 нче таблица*

***2018 – 2020 елларда тәрәзәдән егылып төшеп үлгән балалар саны (районнар буенча, кеше)***

| *Муниципаль район, шәһәр исеме* | *2018 ел* | *2019 ел* | *2020 ел* |
|---|---|---|---|
| *Түбән Кама* | *1* | *1* | - |
| *Зәй* | - | *1* | - |
| *Чаллы шәһәре* | - | *1* | - |
| *Казан шәһәре* | *1* | - | *2* |
| *Бөгелмә* | - | - | - |
| *Әлмәт* | - | - | *1* |
| ***Барысы*** | ***2*** | ***3*** | ***3*** |

Шул ук вакытта, балаларның, тәрәзәдән егылып төшеп, җәрәхәт алган очраклары да бар.

***Мисал:***

*Черкидән саклану челтәре Әлмәттә өч яшьлек кызның үлүенә сәбәп булган. Ул тугызынчы каттан егылып төшә.*

*Түбән Камада кыз бала, бишенче каттан егылып төшеп, нинди дер могҗиза белән генә исән кала – ул шулай ук тәрәзәгә куелган челтәргә таянган.*

Балаларның тәрәзәдән егылып төшүе өлкәннәрнең игътибарсызлыгына бәйле. Тагын фатирда ачык тәрәзәләрнең берни белән дә якланмавы турында да әйтергә кирәк.

Бу уңайдан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты рәисе Тыгин А.В., Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Айзатуллин М.М. адресларына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Илкүләм стандартлар һәм кагыйдәләр җыелмасы исемлеген (мондый стандартларның һәм кагыйдәләрнең бер өлешен) раслау турында» 2020 елның 4 июлендәге 985 номерлы карары белән регламентланган кагыйдәләрнең тиешле җыелмасына (аларны куллану нәтиҗәсендә «Биналарның һәм корылмаларның иминлеге турында техник регламент» Федераль закон таләпләрен үтәү мәҗбүри нигездә тәэмин ителә) балалар иминлеге һәм тәрәзәдән егылып төшү очракларын булдырмас өчен конструкцияләр турындагы таләпләрне кертү өлешендә үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану инициативасы белән чыгарга дигән мөрәҗәгать юллады.

2020 елда 3 балигъ булмаган бала суицидаль мотивларга бәйле булмаган сәбәпләр аркасында (караватта очраклы буылу, ризык белән тыгылу) нәтиҗәсендә ***буылып үлгән***. Бер бала ***термик пешү*** аркасында үлгән.

***Мисал:***

*Фаҗигаләрнең берсе 2020 елның 18 гыйнварында Ютазы авылында булган. Иртән әти-әнисе төрле урыннарда тәне пешкән 4 айлык улларын үлгән килеш күрәләр. Тикшерү версиясе буенча, кичтән әнисе малайны үзе янына диванга йокларга салган. Күпмедер вакыттан бала диваннан батарея ягына тәгәрәп китә, нәтиҗәдә, аның кызулыгыннан пешеп үлә. Мәетне иртән өенә кайткан әтисе табып ала.*

Гомумән алганда, 2020 елда республикада 28 баланың гомере ата-аналарының җиңел уйлавы яки ваемсызлыгы аркасында кылынган гамәлләре (гамәл кылмаулары) нәтиҗәсендә өзелгән һәм бу Россия Федерациясе Җинаять кодексының 109 статьясы буенча квалификацияләнә.

Тышкы сәбәпләр аркасында булган балалар күрсәткечләрен анализлаудан күренгәнчә, болар берсе дә медицина характерындагы фактор түгел, аларны булдырмый калырга да мөмкин иде. Өлкән кешеләр, балаларын озак вакытка үзләрен генә калдырып, аларның гомерен куркыныч астына куялар, дип уйламыйлар да.

Сәбәп-нәтиҗә элемтәләрен анализлау бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә балалар үлеменә китерергә мөмкин булган түбәндәге төп сәбәпләрне ачыклады::

– вакыт җитмәү – балаларга игътибар җитмәүнең төп сәбәбе;

– өлкәннәрнең төрле нәрсәгә бәйлелеге;

– социаль куркыныч, авыр тормыш хәлендә калган гаиләләр белән профилактик эшнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы;

– гаиләнең имин булмавын иртәрәк ачыклау буенча эшнең җитәрлек булмавы;

– ата-аналарның җавапсызлыгы;

– гаилә тәрбиясе буенча уңай тәҗрибә булмау;

– педагогика һәм гаилә тормышы психологиясе, гаилә тәрбиясе, балаларның физиологик һәм психологик үзенчәлекләре нигезләрен белү дәрәҗәсе түбән булу.

Еш кына балалар, бигрәк тә кечкенәләр, өлкәннәрнең битарафлыгы аркасында еш кына җәрәхәт алалар. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балаларнеың бәхетсезлек очракларын кисәтү, барыннан да элек, ата-аналарның җаваплылыгыннан башланырга тиеш, дип басым ясады. Җаваплы ата-ана – ул, барыннан да элек, тәрбияләүнең барлык якларының балансլыгы, шул исәптән баланың сәламәтлеген саклау, ныгыту да ул, бу хәзерге Россия җәмгыяте шартларында бик актуаль һәм балага гаилә, культура, сәламәтлек кебек тормыш кыйммәтләренең башлангыч нигезләрен сеңдерү тулысынча ата-аналар җилкәсенә төшә.

Өлкәннәр өчен бик мөһим нәрсә – балаларга имин яшәү рәвешен күрсәтеп, барлык хәлләрдә үзеңне дөрес тоту. Бала өчен олы кешедән үрнәк алу – ул йогышлы!

Бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә балаларның үлемен һәм имгәнүен кисәтү максатында, республикада бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә балалар үлемен кисәтү һәм профилактикалау буенча өстәмә чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру эшен дәвам итәргә кирәк, дип саныйбыз, шул исәптән:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

җирле үзидарә органнары, мәгариф оешмалары белән берлектә:

ата-аналар берләшмәсе белән эшне түбәндәгеләр буенча дәвам итәргә:

балалар имгәнүен профилактикалау буенча түбәндәге ике төп юнәлеш буенча:

– имгәнү куркынычы булган хәлләрне бетерү;

– балаларга имгәнүне профилактикалау нигезләрен аңларга өйрәтү;

балаларда кеше гомеренә һәм сәламәтлегенә карата кыйммәтләр булдыру, имин булу күнекмәләренә өйрәтү, бу катлаулы эштә ата-аналарга «Мин-әти яки әни» интернет-сайты ресурслары файдалы булачак https://www.ya-roditel.ru/otvetstvennoe-roditelstvo;

балигъ булмаганнарда үзләрен куркыныч астына куймау күнекмәләрен булдыру буенча эшне дәвам итәргә;

тәүлекнең караңгы вакытында җәяүле балалар тарафыннан яктылык кайтаручы элементлар куллануны тәэмин итү буенча;

белем бирү оешмалары укучылары куллана торган тимер юлларга якынлашканда барлык музыкаль һәм видео контентны блокировкалаучы «Safetrain» гаджетлары өчен махсус эшләнгән кушымтадан файдалану турында «Россия тимер юллары» («РТЮ») җитәкчелегенең тәкъдимен эшләп бетерергә;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә медицина хезмәткәрләре катнашында медик-профилактик темаларга, шул исәптән балалар имгәнүләрен профилактикалауның проблемалы мәсьәләләре һәм баланың өйдә, урамда, белем бирү учреждениесендә имин булу мохитен булдыру буенча ата-аналар җыелышлары уздырырга;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә мәгариф оешмаларында балаларның юлда имгәнүләрен профилактикалауның инновацион рәвешләрен һәм ысулларын гамәлгә кертү эшен дәвам итәргә;

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы Баш идарәсенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән берлектә, балалары белән гаиләләр җыела торган төрле объектларда балаларны янгын куркынычсызлыгына өйрәтү буенча профилактик эшне дәвам итәргә һәм тематик ата-аналар җыелышлары үткәрергә;

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә, балигъ булмаганнарның тышкы сәбәпләрдән имгәнүен һәм үлүен булдырмау максатыннан, ата-аналарның һәм аларның балаларының сәламәт яшәү рәвеше куркынычсызлыгын пропагандалауга юнәлтелгән массакүләм мәгълүмат чараларында чыгышларны оештырырга;

янгыннарны кисәтү һәм кешеләрнең үлеменә юл куймау максатларында балалар белән гаиләләрдә янгын турында хәбәр итү җайланмаларын куюны пропагандалау;

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр рәисләренә, муниципаль мәгариф идарәсе органнары белән берлектә, балигъ булмаганнарның имгәнүенә китергән сәбәпләрне һәм шартларны өйрәнергә, алга таба шундый ук очракларны кисәтү һәм булдырмау буенча чаралар күрергә.

Тышкы сәбәпләр аркасында балалар үлеменең тагын бер сәбәбе – үз-үзләренә кул салу (***суицид)***.

Һәр суицид – ул гаиләләргә, дусларга, җәмгыятькә кайгы китерә торган һәм югалтуны кичергән кешеләрнең күңелләренә озак вакытка яра сала торган фаҗига.

Соңгы елларда балигъ булмаганнарның үз-үзләренә кул салу күрсәткечләренең кимүе күзәтелә – 2018 елдагы 17 очрактан 2020 елда 11гә калдв (2019 елда – 13).

Иң күп очраклар Казан шәһәрендә – 5, Зәй районында – 2, Чаллы, Әлмәт, Зеленодольск шәһәрләрендә – 1 очрак теркәлгән. Алар арасында: ир балалар – 6, кызлар – 5. Яшь составы буенча: 15 – 17 яшьлекләр – 9; 10 – 13 яшьлекләр -2. Мәктәп укучылары – 10, көллият, техникумнар – 1.

Идел буе федераль округы (алга таба – ПФО) субъектлары буенча балигъ булмаганнар арасында суицидаль картина мониторингы Татарстан Республикасын чагыштырмача тыныч төбәк буларак күрсәтә. Әмма бу өлкәдәге иминлек турында бары тик нульле күрсәткечләр булганда гына сөйләргә була.

*23 нче таблица*

***2020 елда Идел буе федераль округы субъектлары буенча балигъ булмаганнар арасында суицидлар саны***

| ПФО субъектының атамасы | Балалар саны | Балигъ булмаганнар арасында суицидлар саны (кеше) | | | 10 мең балага суицидлар саны чагыштырмасы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 | 2019 | 2020 | 2018 | 2019 | 2020 |
| Удмуртия Республикасы | 330 000 | 13 | 8 | 15 | 0,38 | 0,23 | 0,45 |
| Самара өлкәсе | 615 832 | 10 | 23 | 18 | 0,17 | 0,38 | 0,29 |
| Киров өлкәсе | 254 613 | 4 | 9 | 7 | 0,16 | 0,35 | 0,27 |
| Чувашия Республикасы | 269 770 | 8 | 5 | 7 | 0,31 | 0,19 | 0,26 |
| Башкортостан Республикасы | 912 337 | 31 | 30 | 22 | 0,34 | 0,33 | 0,24 |
| Түбән Новгород өлкәсе | 604 100 | 13 | 15 | 14 | 0,22 | 0,25 | 0,23 |
| Ульяновск өлкәсе | 227 134 | 5 | 8 | 5 | 0,22 | 0,35 | 0,22 |
| Пермь крае | 587 785 | 23 | 17 | 12 | 0,39 | 0,29 | 0,20 |
| Саратов өлкәсе | 451 172 | 10 | 10 | 9 | 0,22 | 0,22 | 0,20 |
| Оренбург өлкәсе | 434 354 | 15 | 17 | 8 | 0,33 | 0,38 | 0,18 |
| Мордовия Республикасы | 134 400 | 1 | 1 | 2 | 0,07 | 0,07 | 0,15 |
| Марий Эл Республикасы | 148 171 | 8 | 5 | 2 | 0,54 | 0,34 | 0,13 |
| Пенза өлкәсе | 231 817 | 5 | 8 | 3 | 0,21 | 0,34 | 0,13 |
| Татарстан Республикасы | 843 709 | 17 | 13 | 11 | 0,21 | 0,16 | 0,13 |

Суицидент балаларның социаль портретын анализлау шуны күрсәтә: яшь буенча балигъ булмаганнарның күпчелеге (11дән 9ы) 15-17 яшьлек яшүсмерләр, иң кече балага 10 яшь булган.

Узган ел суицид кылган 11 баланың җенси билгеләре буенча 6сы – малайлар, 5есе – кызлар.

Суицидент балаларның яшәү урынынына килгәндә (шәһәр, авыл), шунысын билгеләп үтәргә кирәк, 2020 ел нәтиҗәләре буенча 11 суицидның 8е (77%) – шәһәрдә яшәүчеләр балалар , 3есе (23%) – авыл балалары.

Кагыйдә буларак, суицидның сәбәпләре яшүсмер өчен бөтенләй хәл ителми торган проблемалар кебек тоела. Үсмер чагында аңа үзенең социаль элементә системасы, барыннан да бигрәк, гаиләсе көчле йогынты ясау факторы булып санала. Гаиләдәге мөнәсәбәтләр депрессив хәлләрдән яклануга да, аларның артуына да сәбәп булырга мөмкин. Шуның белән бергә, нәкъ менә яшүсмерләр өчен яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләр зуррк әһәмияткә ия.

Шул ук вакытта, суицидны профилактикалауда яшүсмерләр һәм өлкәннәр арасында ышаныч дәрәҗәсе хәлиткеч роль уйный. Шуны ассызыклап үтәргә кирәк, синең тормышың, бәлки, еш кына якын кешеләреңнен сиңа булган мөнәсәбәтенә, аларның куркынычны вакытында күрә белүләренә, гамәлләренә, кешегә ихластан ярдәм итәргә

теләүләренә бәйле булырга мөмкин. Балигъ булмаганнарның үз-үзенә кул салуларының төп сәбәпләре – җавапсыз мәхәббәт, ата-аналар һәм яшьтәшләре белән конфликтлар, мәктәп проблемалары, ялгызлык.

Балаларның мәшгульлеген анализлаудан күренгәчә, үлүчеләр арасында барлык балалар да диярлек укучылар: 10 бала мәктәптә укыган, 1 яшүсмер һөнәри белем бирү оешмасында укыган.

Үз-үзләренә кул салган балалар тәрбияләнгән гаиләләрнең имин булмавын бәяләү мәсьәләсе аерым игътибар итүне сорый. Суицид кылуның конкрет шартларын өйрәнгәндә, 11 баланың берсе генә тиешле хезмәтләрнең – балалар иминлеген профилактикалау субъектларының игътибар зонасында булган, психик яктан кимчелекләре булган һәм тиешле исәпто торган, дигән нәтиҗә ясарга була.

Яшүсмерләрнең суицид очракларының барысы да баланың үз-үзен фаҗигале тотышы сәбәпләрен ачыклау өчен житди тикшерелде. Һәр яшүсмер йә гаиләдә, йә мәхәббәттә конкрет кичерешләр уздырган. Күпләр өчен яшүсмер чак – яңа мөмкинлекләр булдыру һәм мөстәкыйльлек алу гына түгел, ә укуда уңышларга ирешү, кешеләр белән аралашу һәм алдагы тормыш турында уйлану, борчылу чоры да ул.

Алты очракта аларның бу дөньядан ихтыярый рәвештә китү сәбәпләре ачыкланмаган. Иң аянычы шунда, һәр конкрет очракта бала үзенең «балалык борчулары» белән бер ялгызы калган һәм янәшәдә аңа ярдәм итәрлек кеше табылмаган. Иң беренче чиратта, сүз якын кешеләренең, гаиләсенең, ата-аналарының ярдәме турында бара.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, алдагы еллардагы кебек үк, суицид очракларының берсе дә «Интернет» челтәренең тискәре контенты йогынтысында башкарылмаган.

Шулай итеп, соңгы елларда суицид кылучы балигъ булмаган балаларның социаль портретын анализлау шуны күрсәтә, үз-үзенә кул салучы балаларның «хәтәр төркем»гә карамаганы ачык күренә, шуңа күрә бу юнәлештә профилактик эш балаларның һәм яшүсмерләрнең мөмкин кадәр киңрәк даирәсенә карата үткәрелергә тиеш.

Балаларның суицидаль тотышына юл куймау һәм аларны минимальләштерү максатларында һәр суицидаль омтылыш очрагын җентекләп тикшерү сорала.

2020 елда суицид омтылышлар белән үзү-үзенә кул салуга бәйле медицина оешмаларына мөрәҗәгать иткән балигъ булмаганнар саны 57дән 36га кадәр кимегән (2018 елда – 64, 2019 елда – 57, 2020 – 36).

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының оператив белешмәләреннән күренгәнчә, суицидаль омтылышлы, балигъ булмаганнарны суицидка өндәүче социаль челтәр кулланучылары (үлем төркеме) буенча 15 факт ачыкланган.

2020 елда Татарстан Республикасы балаларына һәм яшьләренә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәкләренең суицидаль тәртипне профилактикалауга юнәлтелгән эше белән 2 454 кеше колачланган, нигездә (2 120 кеше) Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Минзәлә, Түбән Кама, Яңа Чишмә һәм Чистай муниципаль районнарында:

– 318 кеше – Казан («Ышаныч» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге» МБУ) һәм Чаллы («Ышаныч» яшьләр телефоны» балалар һәм яшьләр өчен ашыгыч психологик ярдәм үзәге» МБУ) шәһәрләрендә суицид проблемасы буенча ашыгыч психологик ярдәм сорап мөрәҗәгать иттеләр;

– 16 кеше – Казан («Ышаныч» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге» МБУ), Чаллы («Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-психологик ярдәм үзәге» МБУ) һәм Түбән Кама («Эйдос» балаларга һәм яшьләргә психологик-

психологик ярдәм үзәге» МБУ) шәһәрләрендә суицидаль тематика буенча индивидуаль психологик консультацияләр алды.

Татарстан Республикасында балалар өчен ышаныч телефонына 26 771 шалтырату килгән, шул исәптән суицид проблемалары буенча – 127 шалтырату. Шуларның 72се – балалар һәм яшүсмерләрдән, 16сы – әти-әниләрдән, 39ы – башка гражданнардан. Мөрәҗәгатьләрнең тематикасы: суицидаль уйлар, ниятләр, хәл итү, агымдагы суицид, суицидка омтылыштан соңгы хисләр, суицид темасы буенча башка мәсьәләләр.

2020 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (112 чакыру хезмәте), Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы инициативасы буенча суицидка кылуга омтылган 12 балигъ булмаган бала ведомствоара исәпкә куелган.

«Сердәш 129» хезмәте 1 157 балигъ булмаган балага психологик ярдәм күрсәтте, аларның 317сендә үз-үзенә кул салу куркынычы зур булуын билгеләп үтте: 594 балигъ булмаган бала – амбулаториядә, 544 – ышаныч телефоны буенча, 19 – чат буенча ярдәм алды.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, соңгы елларда республикада, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең күрсәтмәләрен истә тотып, тәмамланмаган суицидлар фактларын тикшерү буенча системалы ведомствоара эш оештырылды. Сәламәтлек саклау органнарының һәм башка органнарның – профилактика субъектларының проблемалы балалар арасында кабат суицидлар булмасын өчен чаралар күрү буенча үз вакытында һәм төгәл үзара эшчәнлек алып баруы мөһим профилактика чарасы булып тора. Төп бурыч – кабат суицид омтылышларны булдырмау, конкрет балага авыр тормыш хәленнән чыгарга ярдәм итү һәм гомумиләштерелгән практика нигезендә профилактик характердагы чаралар эшләү.

Шуны аңлап эш итәргә кирәк, суицидны профилактикалауда һәркем үзенең җаваплылык дәрәҗәсендә үз ролен уйный ала.

Балигъ булмаганнар арасында суицидаль омтылышны кисәтү максатында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне эшләргә тәкъдим итә:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына җирле үзидарә органнары, мәгариф оешмалары җитәкчеләре белән берлектә, Ресурс үзәге потенциалын кулланып, системалы рәвештә түбәндәгеләрне үткәрергә:

укучыларның психологик сәламәтлеген һәм иминлеген ныгытуга юнәлдерелгән чаралар;

балаларда стресс хәлләрдән котылырга ярдәм итә торган когнитив, эмоциональ һәм социаль күнекмәләр булдыру буенча курслар, лекторийлар, тематик сәгатьләр;

мәктәп укучыларында стресс халәтне, суицидаль тотыш билгеләрен ачыклау, тану һәм чаралар күрер өчен персоналы укытырга;

мәктәп укучыларында психологик сәламәтлеккә бәйле проблемалар барлыкка килгәндә ярдәм сорап мөрәҗәгать итүне хуплый торган күмәк җайланмалар булдыру эшен дәвам итәргә;

педагогик персоналның психологик сәламәтлеген ныгытуга ярдәм итә торган чаралары;

укучыларга, ата-аналарга һәм персоналга квалификацияле медицина хезмәтләре күрсәтү белгечләреннән һәм ярдәмче хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеге турында киң мәгълүмат бирү буенча чаралар.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгына, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына Татарстан Республикасында балалар өчен «ышаныч телефоны» һәм суицидология хезмәте телефоны турында мәгълүмат-реклама кампаниясен дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, муниципаль мәгариф һәм яшьләр эшләре органнары белән берлектә, өстәмә белем бирүнең төрле рәвешләренә җәлеп итү һәм балигъ булмаган балаларның ялын оештыру эшен дәвам итәргә.

Профилактика эшен оештырганда түбәндәгеләрне эшләргә кирәк, дип саныйбыз:

мәктәп һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларның ата-аналар берләшмәләренең социаль мессенджерлардагы (Ватцап, Вайбер һ.б.) мөмкинлекләрен балаларның һәм яшүсмерләрнең укуы, аларның тәртибе турында, мәктәп проблемалары турында актуаль мәгълүмат җиткерү өчен генә түгел, ә төрле профилактик һәм тәрбия юнәлешләре буенча ата-аналар өчен актуаль булган практик материаллар урнаштыру урыны буларак та актив файдаланырга кирәк (бу файдалы статьяларга, сайтларга, белешмә материалларга, онлайн киңәшләргә, видео-роликларга сылтамалар һәм ата-аналар компетенцияләрен арттыру буенча башка мәгълүмат булырга мөмкин);

профилактик эшчәнлек кысаларында әлеге юнәлеш буенча нәтиҗәле эш алып бару өчен төбәкнең алдынгы фәнни җәмәгатьчелеге белгечләрен, югары уку йортлары вәкилләрен җәлеп итәргә, аларның потенциалын ата-аналар белән бергә эшләүне тәэмин итү өчен, педагогик һәм медицина хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү системасында файдаланырга.

Шуны әйтергә кирәк, массакүләм мәгълүмат чараларындагы хәбәрләр суицидларны кисәтү буенча тырышлыкны ныгытырга да, йомшартырга да мөмкин. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, мондый хәлләр турында медиа-репортажлар суицид куркынычын арттыра ала, әмма суицид проблемасын җаваплы яктырту җәмәгатьчелекнең үзен үзе үтерү һәм аларны кисәтү ысуллары турында хәбәрдарлыгын арттырырга, хәвефкә дучар булган кешеләргә өмет тудырырга, стигматизацияне киметергә, ачык һәм уңай диалогка этәрергә мөмкин.

Шуңа бәйле рәвештә, массакүләм мәгълүмат чараларына суицидлар проблемасын яктыртуга, уйланылган формулировкалардан файдаланырга, барыннан да элек, ата-аналар берләшмәләренә, яшүсмерләр-яшьләр аудиториясенә стрессның тормышта булган факторларын ничек җиңәргә яки суицидаль фикерләрдән ничек арынырга мөмкин булуы турында мәгълүмат бирергә һәм ярдәмнең кайдан һәм ничек алу мөмкинлеге турында белешмәләр җиткерергә тәкъдим итүне максатка ярашлы дип саныйм.

Балалар үлеменең табигый булмаган сәбәпләренең берсе – ***аларга карата башкарылган җинаятьләр аркасында балаларның үлүе.*** Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белешмәләренә караганда, 2020 елда 8 бала үтерелгән (2019 елда – 6 бала) (Россия Федерациясе Җинаять кодексының 105 статьясы (алга таба – РФ ҖК). Саксызлык аркасында (РФ ҖК 109 ст.) 28 балигъ булмаган бала үлгән (2018 елда – 26). 2020 елда да, 2019 елдагы кебек үк, үз әниләренең корбаннарына әверелгән яңа туган балалар юк, узган ел шундый бер җинаять (РФ ҖК 106 ст.) кылынган, әмма бала исән калган.

### 3.6.2. Рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклану хокукын тәэмин итү

Күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау системасының барлык субъектлары тарафыннан гаиләдә хәтәрлекләрне булдырмау буенча күрелгән чараларга да карамастан, балигъ булмаганнарга карата җинаятьләр кылу шактый күп. Балаларга карата 2 363 җинаять кылынган (РФ Җинаять кодексының 157 статьясында күрсәтелгән җинаятьләрдән тыш), җинаять өлкәсендә теркәлгән җинаятьләрнең гомуми санынннан (53 856) 4,4% тәшкил итә.

Түбәндәге таблицада балигъ булмаган балалар зыян күргән дип табылган җинаятьләр китерелгән.

*24 нче таблица*

***2019 – 2020 елларда җинаять эшләре буенча зыян күргән дип танылган балигъ булмаганнар саны***

| ***Җинаять төрләре*** | ***Зыян күрүчеләр дип танылган балалар саны (кеше)*** | |
|---|---|---|
| | ***2019 ел*** | ***2020 ел*** |
| РФ ЖК ст. 105 («Үтерү») | 14 | 8 |
| РФ ЖК ст.106 («Ананың яңа туган баласын үтерүе») | 1 | - |
| РФ ЖК ст.109 («Саксызлык аркасында үлемгә китерү») | 26 | 28 |
| РФ ЖК ст. 110 («Үз-үзен үтерүгә җиткерү») | 4 | 8 |
| РФ ЖК ст. 111 («Аңлы рәвештә сәламәтлеккә зур зыян китерү») | 3 | 8 |
| РФ ЖК ст. 112 («Аңлы рәвештә сәламәтлеккә уртача авырлыктагы зыян китерү») | 25 | 23 |
| РФ ЖК ст. 115 («Аңлы рәвештә сәламәтлеккә җиңелчә зыян китерү») | 32 | 23 |
| РФ ЖК ст. 116 («Кыйнаулар») | 23 | 17 |
| РФ ЖК ст. 117 («Җәфалау») | 47 | 41 |
| РФ ЖК ст. 119 («Үтерү белән янау») | 67 | 55 |
| РФ ЖК ст. 125 («Куркыныч астында калдыру») | 9 | 2 |
| РФ ЖК ст. 127 («Законсыз рәвештә иректән мәхрүм итү») | 2 | 3 |
| РФ ЖК ст. 131 («Көчләү») | 13 | 132 |
| РФ ЖК ст. 132 («Сексуаль характердагы көч куллану гамәлләре») | 61 | 768 |
| РФ ЖК ст. 133 («Сексуаль характердагы гамәлләр кылуга мәҗбүр итү») | 8 | 4 |
| РФ ЖК ст. 134 («16 яше тулмаган зат белән җенси мөнәсәбәткә керү») | 59 | 325 |
| РФ ЖК ст. 135 («Бозыклык гамәлләре кылу») | 41 | 78 |
| РФ ЖК ст. 156 («Балаларга карата рәхимсезлек кылып, ата-ана бурычларын үтәүдән баш тарткан өчен җинаятьләр») | 65 | 65 |
| РФ ЖК ст. 150, 151, 151.1 («Балигъ булмаган затны җинаять кылуга, җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итүгә бәйле җинаятьләр») | 10 | 99 |
| РФ ЖК ст. 240-242 («Фәхишәлек белән шөгыльләнүне, порнография материалларын яисә предметларын законсыз эшләү һәм таратуны оештыру һәм шуңа җәлеп итүгә бәйле җинаятьләр») | 27 | 11 |

| | | |
|---|---|---|
| РФ ҖК ст.158, 159, 161-163 («Милеккә каршы җинаятьләр (караклык, мошенниклык, талау, юлбасарлык, куркытып алу») | 595 | 475 |

Җинаятьләрнең гомуми санынннан ***балаларга карата көч куллану гамәлләренә бәйле җинаятьләр*** аеруча борчу тудыра. Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ белешмәләренә караганда, Татарстан Республикасы территориясендә 2020 елда шундый 1768 җинаять теркәлгән.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белешмәләренә караганда, җинаятьләрнең чиреге диярлек (37%) гаиләдә җенси кагылгысызлыкка каршы кылынган. Мондый җинаятьләрнең гомуми саны 490 булды, шул исәптән:

15 җинаять ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан кылынган;

3 – әниләренең өйдәш ирләре тарафыннан;

472 – гаиләнең башка әгъзалары тарафыннан.

Балигъ булмаганнарга карата гаилә әгъзалары тарафыннан кылынган җинаятьләр турында мәгълүматны анализлаудан күренгәнчә, элегрәк хөкем ителгән булган һәм хөкем ителүе юкка чыгарылган затларның, элегрәк иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үтүче һәм шартлы рәвештә вакытыннан алда азат ителгән затларның хокук саклау органнары тарафыннан игътибарсыз һәм контрольсез калганнар, нәкъ менә шундый затлар югарыда күрсәтелгән гаиләләрдә гаиләнең иң якланмаган әгъзаларының – балаларның гомеренә һәм сәламәтлегенә каршы авыр җинаятьләр кылганнар.

Көч куллана торган гаиләләрдә нәтиҗәле эшнең булмавы аркасында балалар, ата-аналарыннан, хокук саклау органнарыннан һәм башка профилактикалау субъектларыннан ярдәм алмыйча, үз гомерләрен һәм сәламәтлеген мөстәкыйль рәвештә якларга мәҗбүр булалар.

Шул ук вакытта, гаиләнең имин булмавы турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына кергән мөрәҗәгатьләрне, мәгълүматларны карау кысаларында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау системасы белгечләре эшендә кимчелекләр, аерым алганда, гаиләнең имин булмавын иртә ачыклауда проблемалар булуы, мондый гаиләләр һәм балалар белән тиешле эшләрнең алып барылмавы ачыклана, болар балаларга һәм яшүсмерләргә карата законсыз гамәлләр кылуга китерә.

Шулай ук белгечләр тарафыннан гаиләнең имин булмавының сәбәпләре һәм шартлары тулысынча ачыкланмый, хәлне үзгәртү максатыннан эшләр башкарылганда гаиләнең мөмкинлекләре һәм потенциалы исәпкә алынмый. Шәхси – профилактик чаралар тулы күләмдә үткәрелми, алар гаиләдәге һәлакәтләрнең, фаҗигаләрнең кимүенә йогынты ясый алыр иде.

Кызганычка каршы, «өй тираннары»ннан законлы нигезләрдә котылып булмый, алар тарафыннан даими рәвештә үзләренә карата көч кулланыла торган гаилә әгъзаларыннан аларны әз генә вакытка булса да чикләү мөмкинлеге юк. Иң яхшы очракта, полиция хезмәткәрләре өйдәге ирләрнең хатыннары, бергә яши торган кешеләре гаризасы буенча, «дебошир»ны полиция бүлегенә алып килеп, иң күбе өч сәгать тотып, яңадан кайтарып җибәрәләр, ә шуннан соң, өйгә кайткач, «тираннар» конфликтлар чыгаруны янәдән дәвам итәләр. Исерек кеше өч сәгать эчендә генә айный алмый, ә полиция бүлегенә якыннарының гариза язуы «дебоширлар»ның ачуын тагын да арттыра. «Өй тираннары»на карата административ кулга алу һәм махсус бүлекләргә урнаштыру кебк җәза чараларын кулланып булмый, чөнки алар хокукка каршы гамәлләрен гаилә әгъзалары гына шаһит булган үз фатирларында башкаралар. «Өй тираны»н аерым бер вакытка изоляцияләү һәм барлык

профилактикалау субъектларын күрсәтелгән затлар белән профилактик эшләүгә җәлеп итү, «дебоширлар»ны аерым катгый контрольгә кую гаиләдә авыр җинаятьләр санын кисәтергә һәм киметергә мөмкинлек бирер иде.

Актив уртак эш нәтиҗәсендә генә көч куллану очракларын булдырмый калырга мөмкин.

Балалар белән булган соңгы фаҗигаләрне анализлау шуны күрсәтә, балаларны көч кулланмыйча тәрбияләү буенча ата-аналарның күнекмәләрен үстерү, мәсәлән, өйгә килеп йөрү аша, һәм позитив ата-ана программасын булдыру мөһим.

Балаларга карата көч куллану, шулай ук көч куллануның билгеләре һәм аның тискәре нәтиҗәләре турында белгечләрнең һәм халыкның хәбәрдар булуын арттыру мәсьәләсе, тагын гаиләдә көч куллану очраклары турында хокук саклау органнарына 120-ФЗ федераль Закон таләпләре нигезендә даими рәвештә мәгълүмат җиткерүне булдыру мәсьәләсе мөһим булып кала.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенә, Татарстан Республикасы Прокуратурасына түбәндәгеләрне тәкъдим итү максатка ярашлы булыр, дип саныйм:

балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләр буенча тикшерү чараларын башкарганда тиешле органнарның – балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау субъектларының балалар проблемаларын профилактикалау буенча үз вазыйфаи бурычларын тиешенчә башкару мәсьләсе буенча гамәлләренә (гамәл кылмауларына) хокукый бәя бирергә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика һәм муниципаль комиссияләренә һәм башка органнарга – балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектларына:

баланың имин булмаганлыгы турында теләсә нинди хәбәр һәм мәгълүмат кергән очракта, Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар турында Татарстан Республикасы Бердәм мәгълүмат банкын формалаштыру тәртибендә каралган сигнал карталарын катгый рәвештә булдыруны тәэмин итәргә;

имин булмаган гаиләләрдә, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә (опекуннарда) яшәүче, административ күзәтчелек астында торучы гаиләләрдә бергә яшәүче, үги аталары һәм аналарының өйдәшләре белән бергә яшәүче балаларга аерым игътибар биреп, җинаять кылу ихтималы күзлегеннән чыгып, «хәтәр төркем» балаларын ачыклауны оештыру буенча килештерелгән чаралар үткәрүне дәвам итәргә,

көч куллану корбаннарына квалификацияле ярдәм күрсәтүне һәм балаларны реабилитацияләүне тәэмин итәргә;

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, профилактика системасы органнары – субъектлары белән берлектә, республикада балалар белән рәхимсез мөгамәләгә каршы тору, көч куллануның рөхсәт ителмәвен халыкка аңлату, балага карата көч куллану һәм аңа карата рәхимсезсезлек күрсәткән өчен җаваплылык турында, балаларга һәм гаиләләргә ярдәм күрсәтүче төрле социаль хезмәтләр һәм учреждениеләр эшчәнлеге турында даими нигездә мәгълүмат кампанияләрен үткәрүне тәэмин итәргә.

## 3.7. Балалар закон белән конфликтта

Балаларның иминлеген һәм аларга куркыныч янамауны тәэмин итү Россия Федерациясенең төп илкүләм өстенлекләренең берсе булып тора. Һәр баланың хокукларын яклау, балаларга карата кылынган хокук бозуларны һәм балаларның үзләренең хокук бозуларын профилактикалауның нәтиҗәле системасын булдыру буенча 2027 елга кадәр чорга Балачак унъеллыгы кысаларында үткәрелә торган төп чаралар планын тормышка ашыру кысаларында өстенлекле бурычлар билгеләнде.

«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 120-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 статьясы нигезендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау эшчәнлегенең төп бурычлары түбәндәгеләр була:

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләрен кисәтү, моңа ярдәм итә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү;

балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү;

социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны социаль-педагогик тернәкләндерү;

балигъ булмаганнарны җинаять кылуга, башка хокукка каршы һәм (яки) җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итү, шулай ук аларны суицидаль гамәлләргә тарту очракларын ачыклау һәм булдырмау.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 2020 елда барлык профилактика субъектлары тарафыннан күрелгән чаралар балигъ булмаганнар арасындагы җинаятьчелек торышын тотрыкландыруга ярдәм итте.

Татарстан Республикасы прокуратурасы белешмәләре буенча, 2020 елда түбәндәгеләр билгеләнеп үтелде:

балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләр саны 2,1%ка кимегән;

балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләр саны 3,9%тан 3,5% ка кадәр кимегән;

җинаять кылган балигъ булмаганнар саны 12,7%ка кимегән;

балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр саны кимегән.

Шул ук вакытта, балигъ булмаганнар тарафыннан усал ниятләр белән кылынган караклык, мошенниклык, урлау, талау, автомототранспорт чараларын урлап китү кебек җинаятьләр саны шактый әле.

Алкогольдән һәм наркотиктан исерек хәлдә кылынган наркотик чараларның законсыз әйләнешенә бәйле балигъ булмаганнарның җинаятьләре арту да борчымый калмый.

Чаллы, Бөгелмә, Алабуга, Зеленодольск, Лениногорск, Лаеш, Питрәч, Тукай, Минзәлә районнарында балигъ булмаганнар арасында җинаятьләрнең артуы борчу тудыра.

Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре эшен оештыру буенча 7 муниципаль районда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан территориягә эш визиты кысаларында җентекле анализ ясалды.

2020 елда ябык типтагы махсуслаштырылган учреждениеләрдә тәрбияләнүче һәм закон белән конфликтка кергән балигъ булмаганнарның белем алу процессын оештыру,

аларга медицина ярдәме күрсәтү дә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең күзәтүендә булды.

2020 ел дәвамында ул түбәндәге оешмаларда булды:

– «Җәза үтәтү буенча федераль хезмәтнең (УФСИН) Татарстан Республикасы буенча №1 тикшерү изоляторы» федераль казна учреждениесендә;

– «Ябык типтагы 1 нче Раифа махсус һөнәри училищесы» девиант холыклы балалар һәм яшүсмерләр өчен федераль дәүләт бюджет махсус укыту-тәрбия учреждениесендә;

– «Җәза үтәтү буенча федераль хезмәтнең (УФСИН) Удмуртия Республикасы буенча Ижевск тәрбия колониясе» (алга таба – Ижевск тәрбия колониясе) федераль казна учреждениесендә.

Ижевск тәрбия колониясендә тәрбияләнүчеләрне шәхси кабул итү, тәрбиячеләр белән аралашу барышында учреждениедә тернәкләндерү киңлеген, балалар өчен уңайлы социаль-психологик климат булдыруга, яшүсмерләрне төзәтү, укыту һәм тәрбияләү эшендә уңай нәтиҗәләргә ирешүгә ярдәм итә торган спорт-савыктыру инфраструктурасын үстерү буенча теләкләр әйтелде.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановка урам спорт җиһазлары һәм инвентарь сатып алу үтенече белән мөрәҗәгать итте. Мәсьәлә уңай хәл ителде.

Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге, гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү, министрлыкларның һәм ведомстволарның статистик мәгълүматын анализлау нәтиҗәләре буенча аерым районнарда, профилактика субъектлары органнарының һәм учреждениеләренең профилактика эшен оештыруда, шул исәптән үзара ведомствоара хезмәттәшлектә, проблемалы мәсьәләләр ачыкланды.

**Беренчедән.** ***Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә компетенцияләрне арттыру*** буенча муниципаль берәмлекләрдә системалы эш булмау, профилактика өлкәсендә норматив-хокукый базаны җитәрлек дәрәҗәдә белмәү.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эш визиты кысаларында субъектларның һәм учреждениеләрнең эшен оештыруны өйрәнү, гражданнарның аерым мөрәҗәгатьләренә, резонанс очракларга бәйле вәзгыятьне анализлау балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау өлкәсендә төп законның – 120-ФЗ номерлы Федераль законның төп нигезләмәләрен белүнең түбән дәрәҗәдә булуын күрсәтә, нәтиҗә буларак, опека һәм попечительлек органнары, мәгариф учреждениеләре, мәдәният учреждениеләре, балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияләр хезмәткәрләренең норматив-хокукый базаны белү дәрәҗәсен күтәрүгә, шулай ук кадрлар составын яңартуга бәйле системалы эш алып бару таләп ителә.

Гаиләнең имин булмавына бәйле хәлләрнең шактый булуы аларның социаль дезадаптацияләнүенә китерә, балада сыйныфташлары, яшьтәшләре арасында аның үзүзен тотышында, белем бирү оешмасында катнашучылар арасында тискәре эмоциональ-психологик халәт барлыкка китерә.

Социаль куркыныч халәтне күз алдында тотып, бу хәлгә күпме иртәрәк тыкшынсаң, балага шундый гаиләдә, яшьтәшләре коллективында ярдәм дә шул ук дәрәҗәдә вакытында булачак. Әгәр дә мәктәп проблеманы мөстәкыйль хәл итә алмаса (бала, ата-аналар белән профилактик әңгәмәләр үткәрү көтелгән нәтиҗә бирмәсә, администрация чакыруларына да игътибар итмичә, ата-аналар мәктәпкә озак вакыт килми торса), проблема турында читкә таралудан курыкмыйча, баланы кайгыртып, башка профилактика субъектларын да җәлеп итәргә мөмкин.

Шуңа бәйле рәвештә түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк: №120-ФЗ Федераль законның 9 статьясы нигезендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре үз компетенциясе чикләрендә балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне тәэмин итәргә, аларны дискриминацияләүнең, физик яки психик көч куллануның, хурлауның, тупаслык күрсәтүнең, сексуаль һәм башкача эксплуатациянең барлык рәвешләреннән яклауны гамәлгә ашырырга, социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне ачыкларга, шулай ук кичекмәстән түбәндәгеләргә хәбәр итәргә тиеш:

1) прокуратура органына – балигъ булмаганнарның хокуклары һәм ирекләре бозылу турында;

2) балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиягә – балигъ булмаганнарның белемгә, хезмәткә, ялга, торакка һәм башка хокуклары бозылу очраклары турында, шулай ук органнар һәм учреждениеләр эшчәнлегендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтүгә комачаулый торган җитешсезлекләр турында;

3) опека һәм попечительлек органына – ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балигъ булмаганнарны яки башка законлы вәкилләрне, аларның тормышына, сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган яисә аларны тәрбияләүгә комачаулый торган хәлләрне ачыклау турында;

4) халыкны социаль яклау буенча идарә органына – караучысызлыкка яки сукбайлыкка бәйле рәвештә дәүләт ярдәменә мохтаҗ балигъ булмаганнарны ачыклау турында, шулай ук социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне ачыклау турында;

5) эчке эшләр органына – балигъ булмаганнарның ата-аналарын яки аларның законлы вәкилләрен һәм балигъ булмаганнар белән рәхимсез мөгамәләдә булган һәм аларны җинаять кылуга, башка хокукка каршы һәм (яки) җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итүче йә аларны суицидаль гамәлләргә этәрүче яисә аларга карата башка хокукка каршы гамәлләр кылучы, шулай ук аларга карата хокукка каршы гамәлләр кылганзатлар яисә хокукка каршы гамәлләр кылган балигъ булмаганнар турында;

5.1) җинаять-башкарма инспекциясенә – җинаять-башкарма инспекцияләрендә исәптә торучы, социаль һәм психологик ярдәм күрсәтүгә, социаль адаптациягә, эшкә урнашуга мохтаҗ балигъ булмаганның хөкем ителүләре ачыклану турында, алар тарафыннан хокук бозулар яки җәмгыятькә каршы гамәлләр кылу очраклары, суд тарафыннан билгеләнгән тыюларны һәм (яки) чикләүләрне бозу очраклары ачыклану турында, наркомания белән авыручы дип танылган балигъ булмаган хөкем ителүче балигъ булмаганга карата җәзаның кичектерелми калуы турында, наркоманиядән дәвалану курсын үтүдән читләшүнең ачыклануы турында, шулай ук медицина реабилитациясе яисә социаль тернәкләндерү яисә балигъ булмаган хөкем ителүчеләрнең суд тарафыннан үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдән читләшүләре турында;

6) сәламәтлек саклау буенча идарә органына – алкогольле һәм спиртлы продукция, наркотик чаралар, психотроп яки аңгыралата торган матдәләр куллануга бәйле рәвештә тикшерүгә, күзәтүгә яки дәвалауга мохтаҗ балигъ булмаганнарны ачыклау турында;

7) мәгариф өлкәсенә идарә итүне гамәлгә ашыручы органга – ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалардан, белем бирүне гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларыннан яисә башка оешмалардан рөхсәтсез китүгә бәйле яисә белем бирү оешмаларында мөһим сәбәпләрсез дәресләр туктатылуга бәйле рәвештә дәүләт ярдәменә мохтаҗ балигъ булмаганнарны ачыклау турында;

8) яшьләр эшләре буенча органга – социаль куркыныч хәлдә калган һәм моңа бәйле рәвештә ял итүне, мәшгульлекне оештыруда ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ булган балигъ булмаганнарны ачыклау турында;

9) халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органына – социаль куркыныч хәлдә калган һәм моңа бәйле рәвештә эшкә урнашуда ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ балигъ булмаганнарны, шулай ук «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшкә урнашуда ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ булган балигъ булмаганнарны ачыклау турында.

Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының һәм учреждениеләренең вазыйфаи затлары һәм башка затлар балигъ булмаганнарның хокукларын бозган өчен, шулай ук аларны тәрбияләү, укыту һәм (яки) карау бурычларын Россия Федерациясе законнарында һәм Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән тәртиптә үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы булалар.

**Икенчедән.** «Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» ***мәгълүмат системасы*** **(алга таба – мәгълүмат системасы)** ***белән хезмәттәшлекнең түбән дәрәҗәдә булуы (эш итмәү).***

Кайбер муниципалитетларда укучы балалар гаиләләрендә имин булмаганлык ачыкланганда, мәгариф оешмалары администрациясе сигнал карталарын мәгълүмат системасында урнаштырмый, кагыйдә буларак, хокук саклау органнарына, социаль яклау органнарына телдән хәбәр итә. Мондый хәл аркасында баланың проблемаларын хәл итү һәм балигъ булмаганнар арасында караучысызлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалауның барлык субъектларын эшкә җәлеп итү шактый озакка сузыла яки нинди дә булса сәбәпләр аркасында мәгълүмат тиешле урынга барып та җитми.

Ачыкланган проблеманы, шулай ук педагогик коллективларның сменалы эшләвен исәпкә алып, гаиләдә иминлек булмауны иртә ачыклау эшенә төзәтмәләр кертү кирәклеге турында нәтиҗә ясалды.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында»1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, мәгълүмати система ресурсларыннан файдаланып, гаиләнең имин булмавын алдан ачыклау мәсьәләсен карауны планлаштыруны сорап мөрәҗәгать итте.

**Өченчедән.** Хәтәр төркемдәге балигъ булмаган балалар, аларның гаиләләре, шул исәптән төрле рәвешләрдә профилактик исәптә торучы гаиләләр белән эшләүдә ***системалы якын килүнең түбән дәрәҗәдә булуы*** һәм, барлык: икътисадый, хокукый, социаль, медицина, педагогик, психологик аспектларны исәпкә алып, аларга йогынты ясау; дәрестән тыш һәм каникул вакытларында балаларга өстәмә белем бирү системасында, яшүсмерләр клубларында ***балаларның һәм яшүсмерләрнең мәшгульлеген оештыру буенча эшнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы***.

2019 елда балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә мәгариф оешмалары эшчәнлеген системалаштыру һәм камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан «Балигъ булмаганнарның хокук бозуларын профилактикалау» дигән методик күрсәтмәләр (алга таба – методик күрсәтмәләр) эшләнде. Методик күрсәтмәләрдә хокук бозуларны профи-

лактикалау Советы эшен оештыруга, мәктәп эчендә исәпкә алып баруга һәм белем бирү оешмасының социаль паспортын алып баруга карата яңа алымнар тәкъдим ителде, социаль педагогларга, сыйныф җитәкчеләренә, яшь педагогларга һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасарларына белем бирү оешмасы шартларында хокук бозуларны профилактикалау эшен оештырырга мөмкинлек бирүче практик киңәшләр бирелде. Әмма белем бирү оешмаларында булу, хокук бозуларны профилактикалау субъектларының, шул исәптән мәгариф оешмаларының эшенә анализ ясау әлеге документларның муниципаль берәмлекләр дәрәҗәсендә тиешенчә эшләнеп бетмәвен күрсәтте.

**Дүртенчедән.** Белем бирү оешмаларының, балигъ булмаганнар эшләре комиссияләренең ***балалар һәм яшүсмерләр катнашындагы конфликтларны кисәтү һәм хәл итүнең, хокук бозуларга йогынты ясауның медиатив-торгызу алымнарын һәм механизмнарын гамәлгә кертүгә әзер булмаулары***.

Кызганычка каршы, бүген без балигъ булмаганнарны законсыз протест чараларына җәлеп итү, яшьләр даирәсендә яшьләрнең үз-үзен тотышын манипуляцияләүгә юнәлтелгән контент тарату кебек яңа проблемалар белән очрашабыз.

Әлеге проблема берничә сәбәп араксында кискенләшә:

– балаларның һәм ата-аналарның, гомумән халыкның хокукый культурасының түбән булуы;

– яшьләр белән эшләгәндә бүгенге яшүсмернең, бүгенге z-буынның үзенчәлекләре, аның кыйммәтләре, дөньяга карашы, шул буынга хас аерым таләпләр һәрвакытта да исәпкә алынмый;

– яшьләр сәясәтенең камил булмавы, төрле дәрәҗәдәге дәүләт хакимияте органнарының социаль челтәрләрдә яшүсмерләр-яшьләр мохитенә юнәлдерелгән материал белән җитәрлек булмавы;

– балаларның һәм яшүсмерләрнең социаль яктан әһәмиятле ялларга җәлеп ителүе, аларның буш вакытларында мәшгульлекләре югары дәрәҗәдә булмау, шул исәптән 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларны эшкә урнаштыруда кыенлыклар булу;

– белем бирү программаларында хәзерге җәмгыять таләпләренә туры килә торган уңышлы, социаль актив шәхес формалаштыру буенча фән булмау;

– гаиләләрдә буыннар каршылыгы булу, күп ата-аналарның ата-аналар һәм балалар арасында мөнәсәбәтләр урнаштыра белмәве, бу исә балаларны үз-үзләрен бәяләүне күтәрергә мөмкинлек бирә һәм аларны хуплый торган башка мохиткә этәрә;

– социаль челтәрләрдә тискәре контентның күп булуы һәм әлеге контентка йозак салуда тизлек җитмәү (мәсәлән, Тик-ток (АКШ эшләнмәсе) кулланучылар килешүендә бәхәсләрне инглиз телендә дәгъва белдерү юлы белән Сингапур арбитраж судында хәл итү турында күрсәтелгән, бу проблемалы контентка оператив тәэсир итү мөмкинлеген бирми);

– балигъ булмаганнарны санкцияләнмәгән митингларга җәлеп итү һәм массакүләм тәртипсезлекләрне оештыруга тарту өчен җаваплылык өлешендә законнарның камил булмавы.

Сәбәпләрне аңлап һәм анализлап, куелган проблемаларны хәл итәргә мөмкинлек бирә торган механизмнар һәм инструментлар турында сөйләргә мөмкин.

Хокукый культураны булдыру проблемасын хәл итү системалы характерда булырга тиеш, биредә төрле дәрәҗәдәге гавами хакимият, ата-аналар бергәлеге, белем бирү оешмалары, педагогик берләшмәләр, һәм, әлбәттә инде, профильле югары уку йортларының актив иҗтимагый эшчәнлек белән шөгыльләнүче студентлары белән бергә эшләү күздә тотыла.

Бүген без педагогик һәм ата-аналар бергәлегенең барлыкка килгән вәзгыятькә әзер булмавы белән очраштык.

2020 ел ахырында Россия Мәгариф министрлыгы кушуы буенча укучыларның ата-аналары һәм педагогларның Интернет челтәрендә таратыла торган тискәре характердагы мәгълүмат тәэсирендә балигъ булмаганнарның деструктив тотышын иртә ачыклау буенча гамәлләренең алгоритмнары эшләнде. Алгоритмнарда, деструктив тотыш билгеләре ачыкланганда, педагогның балалар һәм аларның ата-аналары белән эшләү этаплары һәм мондый тәртипне профилактикалау инструментлары ачыла.

Бу инструментарийның һәр мәктәптә, һәр сыйныфта җентекләп эшләнүе һәм кулланылуы мөһим.

Хәзерге заман (z буыны) балаларның үзенчәлекләрен исәпкә алу өлешендә шуны да билгеләп үтәргә кирәк, хәзерге яшүсмерләрнең олыгаюы, белем алуы, тәрбияләнүе һәм социальләшүе бүген Интернет шартларында бара, цифрлы технологияләр бу буынны балачактан әйләндереп ала, ә интернет – аларның ата-аналары тормышының аерылгысыз өлеше. Димәк, без хокукый культураны да әлеге киңлекне кулланып формалаштырырга тиеш булабыз.

Әлеге факторларны исәпкә алып, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан «Балалар хокук академиясе» ведомствоара проекты эшли башлады. Проект барлык профильле министрлыклар һәм ведомстволар тарафыннан хупланды һәм ике профильле югары уку йорты педагоглары һәм студентлары ресурсларын, интернет-технологияләрне кулланып тормышка ашырылачак.

Татарстан Яшьләр министрлыгы тарафыннан «Цифрлы гигиена» проекты эшли башлады, ул видеороликлар, аудио һәм видео подкастлар, шулай ук балигъ булмаганнар арасында критик фикерләүне һәм цифрлы грамоталылыкны формалаштыруга юнәлтелгән башка мәгълүмати материаллар булдыруны һәм тормышка ашыруны күздә тота. Әлеге проектның күп каралуы һәм аңа карата аудиториянең бәяләмәләре булу аның югары нәтиҗәлелеген күрсәтә.

Бүген без виртуаль дөньяда үзебез өчен реаль проблемалар, психик кимчелекләр һәм шәхескә карата, бигрәк тә балаларга, куркыныч тудырырга мөмкин булган өр-яңа күренешләргә тап булабыз.

Боларның барысына да каршы тору өчен гомуми белем бирү оешмаларында да, һөнәри белем бирү оешмаларында да яшүсмерләрнең системалы үсеше өчен нәтиҗәле коммуникатив тәрбия тирәлеге булдырырга кирәк, ул түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

– яшүсмернең мәнфәгатьләрен исәпкә алу (яшүсмерләр мәнфәгатьләре картасы тискәре позицияләрне дә үз эченә ала, ә без моны еш кына игътибарсыз калдырабыз, ә безгә яшүсмернең бу картасы белән эшләргә өйрәнергә кирәк);

– һәркемгә үзенең мөһимлеген тою мөмкинлеге бирү;

– хәзерге җәмгыять таләпләренә туры килә торган уңышлы, социаль актив шәхес формалаштыру буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыру;

– балага актуаль, файдалы һәм аны илһамландыра торган мәгълүмат бирү;

– «әхлак укыйбыз, ә мәнфәгатьләр фокусын берләштерәбез» принцибы буенча эшләп, «ишетәбез, тыңлыйбыз, сезнең телне беләбез, игътибар итәбез» принцибы буенча коммуникацияләр кору;

– көйле һәм акыллы остазлык системасы, даими кире элемтә булдыру;

– балаларның кылган гамәлләренең мотивларын «тирәнтен» аңлау өчен алар белән индивидуаль эшләү, аларның һәркайсыннан аерым интервью алуны тәэмин итү;

– яшүсмер өчен мөһим булган эшчәнлекне, аңа эшкә урнашуны, мәнфәгатьләр буенча берләшмәләргә, спорт секцияләренә, шул исәптән хәзерге заман спорт залларына йөрүне тәэмин итү, чөнки аларга күпләр абонемент бәясенең югары булуы аркасында әләгә алмый, ә ихтыяҗ зур булган спорт төрләре (яшьләр өчен популяр төрләр) әти-әниләрдән шактый чыгымнар таләп итә;

– әти-әниләргә балалар-ата-аналар мөнәсәбәтләрен корырга ярдәм итү, аларны яхшы ата-аналар булырга өйрәтү.

Законнарга үзгәрешләр кертү өлешендә, түбәндәге мәсьәләләрне карарга кирәк, дип саныйм:

балигъ булмаганнарны санкцияләнмәгән митингларга җәлеп иткән һәм массакүләм тәртипсезлекләрне оештыруга тарткан өчен җәзаны катгыйландыру турында;

социаль челтәрләрдә теркәлгәндә яшь цензын һәм балигъ булмаганнарның мондый теркәлүенә ата-аналарның рөхсәт бирүен кертү турында.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан әлеге тәкъдимнәр 2021 елның 3 февралендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасында «Балигъ булмаганнарны социаль челтәрләрдә хокукка каршы эшчәнлеккә җәлеп итүне профилактикалау» дигән темага җәмәгать тыңлауларында бирелде.

# ЙОМГАКЛАУ

***«Кешеләр турында кайгырту, яшәү өчен уңайлы мохит булдыру безнең эшебезнең төп өстенлекле юнәлеше булып тора. Үзебезнең республика программалары һәм илкүләм проектлар нәкъ менә шуңа юнәлдерелгән, һәм без бу киң кырлы эшне дәвам итәчәкбез».***

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2020 елның 24 сентябрендәге Юлламасыннан

2020 елда Россия Россия Федерациясе Конституциясендә (алга таба – Конституция) «балалар Россия Федерациясе дәүләт сәясәтенең иң мөһим өстенлеге» һәм «дәүләт, гаилә тәрбиясе өстенлеген тәэмин итеп, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга карата ата-ана бурычларын үз өстенә ала» дигән нигезләмәләрне игълан итте. Иминлекне аңлауда күп кенә илләрдән принципиаль аермалы буларак, Россия дәүләте, бала бары тик гаиләдә генә имин була ала, дип саный.

Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның 2017 елның 29 маендагы 240 номерлы Указы белән игълан ителгән Балачак унъеллыгының төп бурычларыннан берсе – илебезнең барлык яшь гражданнарының иминлеген тәэмин итү һәм аларның хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен яклау өчен барысы да эшләнәчәге турында һәр балага һәм ата-анага җиткерү. Эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә үз потенциалын ачу өчен бөтен мөмкинлекләре булган, үз Ватанын яратучы һәм аның киләчәге өчен җаваплылык алырга әзер торучы яшьләрнең олы тормышка аяк басуына җәмгыять ышана. Нәкъ менә шуңа күрә Конституциядә «дәүләт балаларның һәрьяклап рухи, әхлакый, интеллектуаль һәм физик үсешенә, аларда патриотизм, гражданлык хисе һәм өлкәннәргә карата хөрмәт тәрбияләүгә булыша торган шартлар тудыра», дип игълан ителә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарына әлеге еллык Докладны балалар мәнфәгатьләрендә төбәк сәясәтен гамәлгә ашыруны бәйсез бәяләү һәм контрольдә тоту механизмы буларак карарга тәкъдим итә.

2020 елда Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлешен анализлау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасында бала хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлеше вәзгыятен канәгатьләнерлек дип бәяли. Шул ук вакытта, ачыкланган проблемалы мәсьәләләрне балалар мәнфәгатьләрендә хәл итү буенча чаралар күрү таләп ителә. Докладта тиешле тәкъдимнәр бирелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, министрлыкларга һәм ведомстволарга, федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы Прокуратурасына, хокук саклау органнарына, республиканың җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, җәмәгать оешмаларына, ата-аналар бергәлегенә, республика гражданнарына, массакүләм мәгълүмат чараларына балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тагын да яхшырак тәэмин итү буенча мәсьәләләрне хәл итү барышында үзара хезмәттәшлек итүләре һәм ярдәм күрсәтүләре өчен ихластан рәхмәт белдерә.

Татарстан Республикасында
Бала хокуклары буенча
вәкаләтле вәкил — Волынец И.В.

*Февраль, 2021 ел*